2° 2014

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

КАЗАН

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, идарә рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы (Истанбул)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы (Уфа)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы (Мэдисон)
ЯКУБОВ Ф.Я., техник фәннәр докторы (Симферополь)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Мөдәррис Харис улы ВӘЛИЕВ

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), БӘДЕРТДИНОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты),
ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ Д.Р. (фәлсәфи фикер)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Г.Р. ХӘКИМОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА

► **РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:**

420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

## БУ САНДА:


**• ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*А.Ф. Йосыпов.* XIX гасыр татар поэзиясе телендә мөнәсәбәт белдерү алымнары ............ 5

*Н.В. Максимов. Әзер* һәм *хәзер* сүзе: эчтәлек һәм форма ............ 10

*И.И. Сабитова.* Татар теленең «кеше» сүзенә караган тематик төркеме лексикасының сүзьясалыш чылбырлары ............ 17

*Ю.Ф. Борһанова.* Татар теленең орфография ягыннан теркәлмәгән интерфиксларын эксперименталь анализ ярдәмендә тикшерү ............ 23

*Г.Р. Гайнетдинова.* «Сөрән сугу» календарь йоласының текстлары лексикасына тарихи-лингвистик анализ ............ 26

*Ә.К. Булатова.* Татар телендә эвфемизмнарның кулланылышы ............ 30

**• ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ**

*Л.Ш. Бәдертдинова.* Татар әдәбиятының фәнни өйрәнелешенә карата ............ 33

*Г.Н. Зәйниева.* Галимҗан Ибраһимов хикәяләрендә тәрбияви-әхлакый моментлар («Яз башы», «Көтүчеләр» мисалында) ............ 45

*Ф.Г. Фәйзуллина.* Г. Тукай төзегән хрестоматиянең тәрбияви әһәмияте ............ 48

*Р.Ф. Харрасова.* Рәдиф Гаташ иҗатында Тукай традицияләре ............ 52

*Л.Н. Йөзмөхәммәтова.* Постмодернистик татар прозасында уен алымы (М. Кәбиров, Р. Габделхакова иҗатлары мисалында) ............ 59

**• ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Ф.Ш. Хуҗин.* Хәзерге Татарстан җирләре һуннар һәм Төрки каганлыклары чорында: историографик күзәтү ............ 65

*А.Х. Мәхмүтова.* Казыя Мөхлисә Бубый ............ 76

*А.М. Ахунов.* 1936 елда Төркиягә «Милли байрак» газетасын кертмәү тарихыннан ............ 93

**• МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Л.И. Яруллина, Э.И. Яруллин.* Гомумбелем бирү мәктәпләрендә татар теле укыту (дәреслекләр, укыту методикасы һәм үсеш перспективалары): 2012—2013 еллар ............ 99

**• ТӨГӘЛ ФӘННӘР**

*Ә.Ф. Галимҗанов.* Беренче төр вакланма-интеграл тигезләмәләрне якынча чишү ысуллары ............ 105

## • ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*М.Г. Арсланов.* Татар театр сәнгатенең күпкырлы талант иясе: Хөсәен Уразиковның тууына 110 ел ..... 114

*Ш.Н. Асылгәрәев.* Шәехгаттар Иманаев — татар сөйләм авазларының ясалышын һәм яңгырашын төгәл фәннәр кануннарына нигезләп өйрәнгән галим ..... 120

## • ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Р.Р. Солтанова.* Төрки сәнгать белеменең көнүзәк мәсьәләләре (Казакъстан сәнгаткәрләре тәҗрибәсеннән) ..... 132

*Д.И. Әхмәтова.* Әстерхан өлкәсенең үзешчән рәссамнары (Әстерхан өлкәсенә экспедиция нәтиҗәләре буенча) ..... 138

## • ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Гали Рәхим.* «Отелло» (куелу мөнәсәбәте илә) ..... 142

*Галимҗан Шәрәф.* Уфада яңа татар имлясы ..... 146

## • 2014 ел: КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

*М.З. Зәкиев.* Төркиләрнең мәдәни башкаласы Искешәһәрдән Казанга күчте ..... 156

*Ф.С. Сәйфуллина.* Төрки дөньяның күренекле мәгърифәтчеләре: Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай ..... 164

*Л.Х. Дәүләтшина.* Төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасын саклау турында ..... 166

## • ЯҢА КИТАПЛАР

*Р.Г. Әхмәтьянов.* Рисаләи-Газизә ..... 168

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары ..... 172

*Ф.Ш. Хуҗин.* Т.Н. Кривошеева. Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции ..... 175

Иҗтимагый-фәнни тормышыбыздан ..... 177

УДК 811.512.145´373

***А.Ф. Йосыпов***

# XIX ГАСЫР ТАТАР ПОЭЗИЯСЕ ТЕЛЕНДӘ МӨНӘСӘБӘТ БЕЛДЕРҮ АЛЫМНАРЫ

В статье рассматриваются лексико-стилистические нормы татарской поэзии XIX века. Раскрываются функция и специфика употребления стилистических средств, выражающие различные соотношения (адекватность, тождественность, противоположность соотношение, равенство) в татарской поэзии данного периода на материале суфийских произведений.

**Ключевые слова:** лексика, суфизм, стилистические средства, гипербола, литота, антитеза, повторы.

Татар әдәби теле тарихында XIX йөз — XX йөз башы зур үзгәрешләр һәм тел тирәсендә барган көрәшнең иң кызган чагы буларак билгеләнә. Бу чор татар әдәби теле нормаларының формалашуы, үзенчәлекләре хакында сөйләшү барышында поэтик әсәрләр, аерым алганда суфичыл поэзия, үзәктә тора. XIX йөз татар суфичылык шигъриятe телендә стилистик вариантлылык максатында классик шигъри тел һәм суфичылык әсәрләре теленә хас тел үзенчәлекләре кулланыла.

XIX гасыр татар поэзиясе теле лексикасының үсеш-үзгәреш процессын берничә яссылыкта билгеләргә мөмкин: тарихи-лексикологик яктан сүзләрнең эволюциясе яки килеп чыгышы ягыннан баюы, тарихи-стилистик юнәлештә лексиканың семантик яктан үзгәрүе. XIX йөз татар поэзиясе теле тел үсешендәге төп тенденцияләрне һәм каршылыкларны, шушы вакыт аралыгында барган үзгәрешләрне, әдәби нормаларның калыплашу юлларын чагылдыруы ягыннан кызыклы.

Татар әдәби, фәлсәфи фикеренә көчле йогынты ясаган суфичылык тел тарихында да эзен калдыра. Көнчыгыш суфичылык әдәбиятының башлангыч чорында гарәп теле нигез телләрнең берсе булып санала. Соңрак — XI гасырдан башлап — әдәби әсәр һәм фәлсәфи трактатлар фарсы телендә дөнья күрә башлый [Эрнст, с. 194], фарсы телле суфичылык поэзиясе Иран, Әфганстан, Урта Азия, Азәрбайҗан, Төркия, Һиндстан төбәкләрендә үсеш ала [Очерки, с. 245]. Инглиз белгече Аннемари Шиммель билгеләп үткәнчә, «суфичылык тел үсешенә дә зур йогынты ясый: юристлар, дин белгечләре һәм тәрҗемәчеләр суфичылыкка хас әйләнмәләрне тел өлкәсенә алып кереп, гарәп телен баета һәм камилләштерә, аны сыгылмалы итә, мәгънә җиткерү мөмкинлекләрен киңәйтә». Поль Нвийа мистикларның «аутентик» тел барлыкка китерүен ачыклый һәм нәкъ менә мистиклар ярдәме белән гарәп телендә күп мәгънәле, яшерен эчтәлекле сүзләрнең артуын билгели. Аның фикеренчә, суфичылык текстларында тел-сурәтләү чаралары, гади бизәк чарасы булудан туктап, мәгънә тирәнлеген, ми-

стик эчтәлекне җиткерү баскычына күтәрелә [Шиммель, с. 34]. Алар серлелекне, дөньяны танып бетерә алмау фикерен җиткерергә ярдәм итә.

Суфичылык әсәрләренә фикерне «ачкыч» булган символлар, кинаят, төсләр символикасы аша җиткерү хас: гасырлар дәвамында рухи халәтне, хис-тойгыны җиткерү өчен аның үз төшенчәләре, образлар системасы эшләнә һәм алар үзенә бер мәгънәне беркетә. Шуңа да суфичылыкның поэзияне мәгънә һәм символлар ягыннан баетуда өлеше зур [Степанянц, с. 10], ул «моңа кадәр кулланылып килеп, иҗади яңалыгын югалткан клише-образларның мәгънәләрен трансформацияләп, үзгәртеп, дини-суфичыл, фәлсәфи эчтәлеккә төреп тәкъдим итә башлый» [Пригарина, 1983, с. 96]. Н.И. Пригаринаның фарсы әдәбиятына кагылышлы әйтелгән бу фикере татар поэзиясе мисалында да актуаль. Гасырлар дәвамында рухи халәтне, хис-тойгыны җиткерү өчен аның үз төшенчәләре, образлар системасы эшләнә һәм алар үзенә бер мәгънәне беркетә. Суфичылык әдәбиятында, гомумән, символлаштыру — ике эчтәлекне белдерү сыйфаты — алга чыга, суфи эчтәлек, интерпретация аша табыла. Галимнәр фикеренчә, суфи әдәбиятның ике планлылыгы — аның популярлыгын, суфичылык тирәлеге чикләреннән чыгып китүен аңлатучы факт ул [Заһидуллина, б. 112].

Суфилар тарафыннан бик күп символ, метафораларның файдаланылуы телне дә стилистик җәһәттән баета, тулыландыра, шуңа мөнәсәбәттә А. Шиммель аны «стилистик яктан катлауландырылган техник тел» буларак билгели [Шиммель, с. 50]. Н. Пригарина фикеренчә, мондый стилистик катлаулылык XI—XII гасыр чикләрендә канун дәрәҗәсенә күтәрелә һәм гадилек инде түбән стиль буларак кына кабул ителә башлый [Пригарина, 1989, с. 95]. Бу фикер татар теле мисалында да раслана, татар суфичылык поэзиясе телендә дә тел-сурәтләү чаралары, образлылыкның үзәктә торуы күзәтелә.

XIX йөз татар поэзиясе телендә стилистик алымнар ике зур төркемгә аерыла:

I. Күчерелмә мәгънә белән бәйләнешле стилистик алымнар, сыйфатлау чаралары. Монда метафорик төркемне (метафора, чагыштыру, символ һ.б. алымнар) һәм метонимик төркемнәрне аерырга мөмкин.

II. Мөнәсәбәтне белдерү алымнары (тәңгәллек мөнәсәбәтен белдерү; капма-каршы мөнәсәбәтне белдерү; тигезлек мөнәсәбәтен белдерү).

Тикшеренүләр суфичылык әсәрләре телендә *мөнәсәбәтне белдерү алымнарының* активлыгын күрсәтте. Әлеге мәкалә чикләрендә без нигездә шул типтагы сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәбез.

XIX йөз суфичылык әсәрләре телендә *тигезсезлек мөнәсәбәтен белдерә торган алымнардан гипербола* һәм *литоталар* кулланыла. Предмет һәм күренешләрнең күләмен, санын реаль чынбарлыктагыдан зурайтып, күбәйтеп күрсәтү гипербола дип атала. Халык сөйләү телендә алар киң таралган. Суфичылык әсәрләре телендә гиперболаларның түбәндәге төрләре кулланыла:

1. Предметның авырлыгын арттырып күрсәтү:

*Даг кеби авыр газабымы*
*якгыл утка,*
*Бәнә сән куввәт гата кыл бән*
*фәкыйрә, йә гани!*

2. Предметның күләмен зурайтып бирү:

*Бәс кичәм, бер дәм, бу чүл вә таг тик юлыңны*

*Бәс, тәвәҗҗеб кыл, язачы, мәсавал тарк итеб.*

3. Абстракт исемнәрне, кешенең эмоциональ кичерешләренә бәйләнешле сүзләрне сан ягыннан күбәйтеп бирү:

*Күңел гамкин, күзем нәмгин,*
*һәмишә,*
*Хәсрәтләрем төмәнчә артыр*
*җәһанда.*
*Берадәр, горра улма бу җәһана! —*
*Каты мяккарадыр дәүре заман.*

Контраст вакыйгаларны тасвирлаганда гипербола аеруча әһәмиятле урын били. Ш. Зәки яшәешнең авырлыгын сурәтләү өчен метафора һәм гипербола алымын бергә кушып бирә:

*Нәчә сәүкәшләрең муйыныны*
*борды,*
*Дагтай хәйатны бәсләде, соңра,*
*йитәр, диде.*

*Литота* («гадилек»), яки мейозис («кечерәйтелү», «киметелү») — гиперболаның нәкъ киресе: теге яки бу күренеш бу алымны кулланганда гадәттәгедән бик нык кечерәйтеп бирелә. Мәсәлән:

*Бу хәйат Җәһанда күз ачып*
*йомган заман,*
*Китте җәһанда әһле адәм.*

Вакыт аралыгының никадәр булуына карамастан, аны бик тиз үтте мәгънәсендә күз ачып йомганчы дип әйтү — телдә иң нык таралган литоталарның берсе.

Суфичылык әсәрләрендә капмакаршылык мөнәсәбәтен белдерү, нигездә, антитезалар ярдәмендә бирелә. Капма-каршы төшенчәләрне бер-берсенә параллель кую антитезаларның нигезендә ята. Мәсәлән:

*Дотар ирсәң, өстеңә рәхмәт*
*йага,*
*Дотмаз ирсәң, вар юлыңа,*
*китә күр.*
*Дот үгетем, сән үзеңне кылма зур.*

Тормыш-көнкүрештәге төрле предмет һәм күренешләр бер-берсе белән капма-каршы куела. Мондый төшенчәләр контекстта ачыклана. Түбәндәге өзектә сафа һәм җафа, михнәт сүзләре капма-каршылык мөнәсәбәтен белдереп, образ-сурәт тудыралар:

*Сафа вә нигъмәтә ирмәклек өчен*
*Җафа вә михнәтә түзмәк кирәк.*

Сөйләмдә антитезалар барлыкка китерүдә, лексик берәмлек буларак, антонимнар гына катнашуы бердәнбер шарт түгел. Галимнәр күрсәткәнчә, татар әдәби теленең функциональ стильләрендә антитеза семантик яктан төрле лексик берәмлекләр ярдәмендә ясала ала:

*Бу фани эвләре, вәйран килүбән,*
*Ад бакый йортыны тезмәк*
*кирәктер,*
*Бу нәфсем гакла галиб килмәдән*
*уң,*
*Аның тәдбиренә бармак кирәктер.*
*Кичүбән бәррә сурәттән сәрасәр,*
*Мәгани бәхредә йөзмәк кирәктер.*

Бу шигырьләрдә бер-берсенә капма-каршы төшенчәдәге түбәндәге сүзләр бар: *фани — бакый, сурәт — мәгънә, галиб килмәк — бозмак*. Әгәр антитезалар антонимнар белән генә ясалса, мондый күренеш сурәтләү мөмкинлекләрен бик нык чиклап куяр иде. Стилистик кануннар телдәге күп чараларның антитезалы сөйләм төзүдә катнашуын таләп итә.

Гомумән, антитезалар фикерне логик яктан көчәйтүдә, күренешләрне ачык итеп күз алдына китерүдә зур роль уйныйлар.

Татар әдәби теленең төрле стильләрендә, бигрәк тә матур әдәбиятта һәм публицистикада киң кулланыла торган алымнарның берсе —

*кабатлаулар*. Алар нәфис сөйләмнең эмоциональлеген, экспрессивлыгын көчәйтүдә һәм сәнгатьчә яңгырашлы итүдә әһәмиятле стиль чарасы булып торалар. Кабатлау — татар әдәби телендә һәм халыкның җанлы сөйләмендә бик күптәннән килә торган тарихи күренеш [Хаков, б. 81]. Ш. Зәкинең «Суфичылык тәрикатенә чакыру» дигән шигыреннән бер мисал:

*Зиһи мөнгыйм кем, нә хуш ихсан*
*итәр, ихсан итәр,*
*Катрә судан, сурәте инсан итәр,*
*инсан итәр.*
*Гакъл илә нәфсе җәсед икълименә*
*солтан итеб,*
*Сурәт эчрә мәгнәе, ул, җан итәр,*
*җан итәр.*

Суфичылык әсәрләре кабатлау алымына аеруча бай. Кабатлауларның төп функциясе — эчтәлек белән форма арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау, вакыйгаларны конкрет күз алдына китерү һәм сөйләмдә эмоциональлек, поэтик җанлылык тудыру [Хаков, б. 82].

Кабатлаулар башка стилистик чаралар белән бергә кушылып та килә. Күп очракта алар контекстта риторик өндәү һәм сорау интонациясе белән көчәйтеп әйтеләләр:

*Бу сүзе кагәзә язмак кирәктер,*
*Бу дөрре бер ийбә тезмәк*
*кирәктер,*
*Вафасызлык бу дөньяның*
*эшедер,*
*Вафасыз нәснәдән бизмәк*
*кирәктер.*

Психологик кичерешләрне бирү өчен, суфичылык әсәрләрендә аерым юлларның кабатлануы да мөмкин:

*Бу мәкане, бу дөкане тәрк итүб,*
*ул шаһсевар,*
*Ля мякан шәһре сары дәүрван*
*итәр, дәүрван итәр.*
*Морг җаны мөлки насути*
*куюбән, һәр заман,*
*Галәяме ляһутта хуш тәйран*
*итәр, тәйран итәр.*

Билгеле булганча, матур әдәбият әсәрләрендә кабатлауларның берничә төре кулланыла. Җөмләләрнең бер сүздән яки бер фразадан башланып китүе анафора дип йөртелә:

*Нә кем, кыйльсам әйүмдән йә*
*үземдән,*
*Нә тиклү дисәм әшгарь, кафавый.*
*Нә суд ула бәңа ошбу сүземдән?*
*Нә хуш сәүдә виребсан бәңа йа,*
*Раб!?*

Берничә җөмләнең, абзацның яки строфаның бер үк сүзгә яки сүзләргә бетүе *эпифора* (азакка чыгару) дип йөртелә, ягъни эпифора — анафораның нәкъ киресе. Анафора һәр төр сөйләмдә дә очраса, эпифора, башлыча, язма тел өчен хас. Эпифораны, иң элек, проза эпифорасы, шигырь эпифорасы төрләренә; шигырь эпифорасын, үз чиратында, *рәдиф* һәм *рефрен* төрләренә бүләргә мөмкин. Проза эпифорасына бер мисал:

*Афәрин, ул санига кем, лотфы*
*бисъяр әйләде,*
*Чөн кәмал кодрәт илә галәме*
*вар әйләде, —*
*Раэфәт, рәхмәтләренең*
*колларына саны юк,*
*Кем безә ул би ниһаят изһар*
*әйләде.*

*Рәдиф* дип (җайдак артында торучы, ияреп баручы) эпифораның турыдан-туры рифмалашкан сүздән соң килә торганына әйтелә. Рәдиф гарәп, фарсы һәм төрки халыклар поэзиясе өчен аеруча хас. Аның матур үрнәкләре суфичылык әсәрләрендә дә очрый:

*Бәнем дәрдем дәвасы сәндәдер,*
*бәс.*

*Бәнем кальбем һәвәсе сәндәдер,*
*бәс.*
*Нә идарем артты дәрдем,*
*юк халәсә чара, аһ,*
*Хәлеме гарз идарем Солтаныма*
*бер парә, аһ.*
*Йөрәгемдә улды хасыйл һич*
*уелмас яра, аһ.*

Гадәттә беренче строфа азагында кулланылган сүз яки сүзләр тезмәсе башка строфалар азагында да рифмалашкан сүздән соң бернинди үзгәрешсез кабатланырга тиеш. Шуның өстенә кабатланучы сүз форма өчен генә түгел, бәлки шигырьнең эчтәлегенә тыгыз бәйләнгән булырга тиеш. Шул чагында гына рәдиф була. Суфи шагыйрь Ш. Зәки дә рәдифне бик оста кулланган, әдипнең «Заман һәм без», «Мөнаҗәт бәраи шикастәэ нәфс», «…йазыкым чук, азыгым йук», «…булгай, булмагай», «Дишвар улды бәнем хәлем» һ.б. әсәрләре әлеге стиль чарасына нигезләнеп язылган.

Шул рәвешле, XIX гасыр татар поэзиясе теле тарихи-стилистик юнәлештә лексиканың семантик яктан үзгәрүе белән үзенчәлекле һәм биредә стилистик алымнардан төрле мөнәсәбәтләрне белдерә торган чараларга еш мөрәҗәгать ителгән. Мондый төрдән без кабатлауларның аерым төрләренә (анафора, эпифора) аеруча басым ясый алабыз. Алар аша суфи әдәбиятның төп үзенчәлеге — яшерен мистик эчтәлек ачыла.

**Әдәбият**

*Заһидуллина Д.* Дөнья сурәте үзгәрү. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.

Очерки истории распространения исламской цивилизации: в 2 т. М.: Рос. полит. энцик. (РОССПЭН), 2002. Т.1: От рождения исламской цивилизации до монгольского завоевания. 688 с.

*Пригарина Н.И.* Образное содержание бейта в поэзии на персидском языке // Восточная поэтика. М. 1983. С. 89—108.

*Пригарина Н.* Введение // Суфизм в контексте мусульманской культуры. М.: Наука, Гл. ред. вост. лит. 1989. С. 95.

*Степанянц М.Т.* Поиск скрытого смысла // В поисках скрытого смысла. Духовное учение Руми. М.: Ладомир. 1995. С. 4—15.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

*Шиммель А.* Мир исламского мистицизма / пер. с англ. Н.И. Пригариной, А.С. Рапопорт. М.: Алетейа; Энигма. 2000. 416 с.

*Эрнст К.В.* Суфизм / пер. с англ. А. Горкового. М.: ФАИР-ПРЕСС. 2002. 320 с.

Мәкалә № 14-14-16004а/р РГНФ гранты кысаларында эшләнде

***Йосыпов Айрат Фаик улы**, филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының татар теле*
*һәм татар телен укыту методикасы кафедрасы доценты*
*e-mail: faikovich@mail.ru*

УДК 811.512.145´373

***Н.В. Максимов***

# *ӘЗЕР* ҺӘМ *ХӘЗЕР* СҮЗЕ: ЭЧТӘЛЕК ҺӘМ ФОРМА

В статье затрагиваются вопросы, связанные с некоторыми непроясненными моментами в истории татарского языкознания. Например, во многих учебниках, методических пособиях для изучающих татарский язык лексемы ‘әзер’ *(готов)* и ‘хәзер’ *(сейчас)* приводятся в качестве синонимичной пары. В статье доказывается, что подобное смысловое неразграничение становится источником нарушения норм письменной и устной речи.

**Ключивые слова:** значение слова, определить значения слова, необычное значение слова.

Һәр сүз мәгънә белдерә. Сөйләмдә, башка сүзләр белән ачыклаучы (иярүче) яки ачыкланучы (ияртүче) буларак, бәйләнешкә керә. Сүзләр арасындагы дөрес мәгънәви бәйләнешләр текстның эчтәлеген аңларга ярдәм итсә, дөрес булмаганнары — комачаулый. Текстта сүзне дөрес мәгънәсендә куллана белү сөйләмнең сыйфат ягыннан камилләшкән тәэмин итә.

Бүгенге татар сөйләменең сыйфаты ни хәлдә? Ничек язабыз, ничек сөйләшәбез? Татар булмаган балаларга татар телендә, кайсы сүзләрне кулланып, ничек сөйләшергә өйрәтәбез?

Татарстан китап нәшриятында дистә еллар дәвамында чыгарылып килгән «Әлифба» дәреслеге (авторлары Р.Г. Вәлитова һәм С.Г. Вәгыйзов) *укучы тарафыннан өйдә башкарыла торган эш төрен «дәрес хәзерләү»* дип язып килде. 2011 елгы басмада нәшрият, ниһаять, 37 нче тапкыр басып чыгарганда, «Әлифба» дәреслеген дөрес язылышка — *«дәрес әзерләү»* вариантына күчкән. 70—80 ел дәвамында татар мәктәбендә укыган буын дәресен *«хәзерләгән»*, соңгы елларда гына укырга кергәне дәресен *«әзерли»* башлаган димәк. Беренчеләре шулай язган, шулай сөйләшкән. Дөресрәге, укучы (шул исәптән, киләчәктә булачак укытучы, язучы, шагыйрь, тел галиме) элеккерәк буын укытучысы ярдәме белән шулай итеп хаталы сөйләшүгә, хаталы язуга күнектерелгән.

Әлегә кадәр чыгып килгән русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрдә *хәзер (сейчас)* һәм *әзер (готовый)* сүзләренең мәгънәсе төрлечә аңлатыла.

Русча-татарча сүзлекләрдә *сейчас* сүзе татарчага вакыт мәгънәсен белдерүче рәвеш — *хәзер* сүзе белән тәрҗемә ителә: *хәзер, хәзергә, хәзерге моментта; хәзер үк, бик тиз; хәзер генә, әле генә, яңа гына*. Гади укучы һәм телгә өйрәнүче өчен бик аңлаешлы.

Татарча-русча сүзлекләрдә *хәзер* сүзе *сейчас, теперь, нынче, ныне* сүзләре белән тәрҗемә ителеп бирелә; *хәзер* сүзеннән ясалган сүзләрнең — *хәзергә, хәзергәчә, хәзерге, хәзергечә* сүзләренең мәгънәсе тәрҗемәдә бирелә. Монда да татар укучысы һәм телгә өйрәнүче өчен барысы да аңлаешлы.

Сүзлекләрдә, татар укучысын һәм телгә өйрәнүчене бутау өчен, зур «җирлек» тә бар: аңлатмалы сүзлекләрдә дә, татарча-русча сүзлек-

ләрдә дә *хәзер* сүзе *хәбәрлек сүз (предикативное слово)* дип тә бирелә. *Хәзер* сүзе тулы мәгънәле лексик берәмлек, *кайчан?* соравына җавап бирә; фигылне ачыклап, эшнең — үтәлү, башкарылу, хәлнең булу вакытын белдерә.

Уйлап карыйк әле: татар телендә *хәзер* сүзен *хәбәрлек* сүз сыйфатында сөйләмебездә куллану дөресме?

*Әзер* сүзе бары сүзлекләрдә генә *хәбәрлек* сүз дип күрсәтелә. Бу сүз укучыга һәм телне өйрәнүчегә *хәбәрлек* сүз буларак тәкъдим ителә икән, ул тулы мәгънәле лексик берәмлек, ягъни үзе генә — тулы мәгънәле башка сүзләр белән бәйләнешкә кермәгән очракта — *кайсы да булса сорауга җавап буларак кулланылырга тиеш.* Хәбәрлек сүзгә сорау биреп булмый, шуңа күрә ул мөстәкыйль сүз төркемнәре рәтендә каралмый да.

*Әзер* сүзенең синтаксик функцияләре түбәндәгеләр:

1) кемнең дә булса нәрсәнедер эшләргә әзерлеген яки әзер түгеллеген күрсәтү:

*хезмәткә әзер, хезмәткә әзер түгел*
*барырга әзер, барырга әзер түгел*
*сөйләшергә әзер, сөйләшергә әзер түгел*

2) нәрсәнең дә булса кулланылышка әзерлеген яки әзер түгеллеген күрсәтү:

*эше әзер , эше әзер түгел*
*киеме әзер , киеме әзер түгел*
*җавабы әзер , җавабы әзер түгел*

3) җөмләнең эчтәлеге таләп иткәндә, аергыч функциясен үтәү:

*әзер эше бар, әзер җавабы юк*

Фәнни әдәбиятта, хәтта «Татар грамматикасы»нда да хәбәрлек сүзләр рәтендә (*бар, юк, тиеш, кирәк, мөмкин* кебек сүзләр арасында) *әзер* сүзе юк. Мәктәп укучылары һәм югары уку йорты студентлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә һәм методик ярдәмлекләрдә дә ул сүз турында, аның морфологик һәм синтаксик билгеләре турында бөтенләй искә алынмый. Укытучы укучыларына *әзерлә, әзерләү, әзерләүче, әзерләну, әзерләтү, әзерләмә* сүзләренең кайсы тамырга кайсы ясагыч кушымчалар ялганып ясалуын, җөмләдә кайсы кисәк булып килү мөмкинлеген, төзелешен, язма һәм телдән сөйләмдәге вазифасын аңлатуга карата, гомумән, фәнни белешмә таба алмый.

Сүзлектән сүзлеккә дистәләгән еллар буена, мәгънә ягы турында уйланып та тормыйча, механик рәвештә күчерелеп килгән *хәзерләнгәнлек, хәзерләндерү, хәзерләнү, хәзерләтү, хәзерләү, хәзерләүче, хәзерләшү, хәзерлек, хәзерлекле, хәзерлеклелек, хәзерлексез, хәзерлексезлек* сүзләре — татарның язма һәм телдән сөйләмен бозучы, ямьсезләүче сүзләр.

Сүзлекләрне һәм сөйләмебезне шундый сүзләр белән ясалма рәвештә «баету» дөрес гамәл түгелдер. Безнең халык, үзара сөйләшкәндә: *«Кышка утын, печән әзерлибез»*, — дип сөйләшкән. Олылар йорттагы яшьрәк балаларын, тавышланмасыннар өчен: «Абыең белән апаң дәресләрен *әзерли*, тынычрак уйнагыз!» — дип кисәткән. Кунак киләсе булса, ризык пешереп, өстәл *әзерләгәннәр*. Элек тә шулай сөйләшкәннәр һәм язганнар, хәзер дә күпчелек шулай сөйләшә һәм яза.

Тагын бер фикер. Сүзлекләрдә [Татар теленең..., б. 526] **хәзер** *хәб. сүз сөйл.* ирония белән инкарь итүне белдерү *(Хәзер, йөгерәм, көтеп тор!)* дип бирү мәгънә ягыннан дөресме икән? Мондый очракларда хәзер сүзе татар сөйләмендә хәбәрлек сүз буларак та, вакыт мәгънәсен белдерүче сүз буларак та кулланылмый. Сөйләшкәндә, үзебезне игътибар белән-

рәк тыңласак, сөйләмебездә ул сүз *кемдер тарафыннан кушылган эшнең үтәлешенә карата сөйләүче тарафыннан белдерелгән тискәре мөнәсәбәтне, тойгыны белдерүче ымлык сүз мәгънәсендә* кулланыла.

*Хәзер* сүзенең телдән һәм язма сөйләмдә кайсы очракта — ымлык, кайсы очракта вакыт мәгънәсен белдерүче сүз буларак кулланылуын гади укучы, бәлки, аңлый да алмас. Дәреслеккә кертелгән түбәндәге текстны [Сафиуллина һ.б., 2013, 3 кисәк, б. 30] укыгач, башлангыч сыйныфларда эшләүче укытучы мәгънәви сернең «ачкычын» үзе дә аңламас:

*... Бүре, мескен, нишләсен, бүләргә тотынган:*

*— Син бик зур, шуңа күрә табышның иң зурысы — тау кәҗәсе сиңа булыр. Мин — арада уртанчысы, димәк, җәйран миңа тияр. Ә Төлке — иң кечебез, аның өлешенә куян чыгар, — дигән ул Юлбарыска.*

*Бу сүзләрне ишеткәч, Юлбарыс:*

*— Син үзеңә иң тәмлесен — җәйранны алмакчы булдыңмы?! Хәзер күрсәтәм мин сиңа өлешеңне! — дип ярсып ырылдаган.*

*Шулай дигән дә, юлбарыс бер мизгелдә Бүрене кабып та йоткан. Аннары, Төлкегә таба борылып:*

*— Әйдә, хәзер син бүлеп кара инде! — дигән.*

Бу очракта мәгънәне дөрес аңламау тиешле тыныш билгесенең тиешле урынына куелмаудан да килә. Мәгънәви сер *хәзер* сүзе тыныш билгесе (өтер) ярдәмендә ымлык буларак аерымлангач чишелә:

| | | |
|---|---|---|
| ымлык | ***Хәзер** күрсәтәм мин сиңа өлешеңне!* | ***Хәзер**, күрсәтәм мин сиңа өлешеңне!* |
| рәвеш | ***Хәзер** син бүлеп кара инде! — дигән.* | |

Безнең халык бик күп гасырлар элек, яшәеш тәҗрибәсенә нигезләнеп, *әзер* һәм *хәзер* сүзләрен бинар компонентлар буларак та кулланган һәм сөйләменә тирән мәгънәле шундый гыйбарә керткән: *әзергә хәзер* ягъни *үзе эшләмичә, башкалар тир түгеп эшләп тапканны файдаланырга яратучы ялкау кеше* шулай аталган. Сүзләргә төшкән басым гыйбарәнең мәгънәсен тагын да көчәйтә.

Соңгы 20 ел эчендә татар телен өйрәнүче татар һәм рус балалары өчен чыгарылган сүзлекләрдә, татарча сөйләшергә өйрәтү өчен төзелгән кулланмаларда *әзер* һәм *хәзер* сүзләре белән төзелгән сүзтезмәләрнең, җөмләләрнең татар һәм рус телендә бирелешен укып карыйк һәм нәтиҗә ясыйк. Үзебез ничек язабыз, ничек сөйләшәбез; башка халык балаларын 20 ел дәвамында татарча ничек сөйләшергә өйрәтәбез?! Галимнәр, дәреслекне, сүзлекләрне, уку әсбапларын төзүчеләр:

*Кем дәрес хәзерли?* Мин дәрес хәзерлим. *Дәрес хәзерлиләр* [Асадуллин, с. 14].

**Хәзер** I — сейчас, теперь (*Хәзер* үк өйгә кер); **хәзер** II — готовый (Өстәл *хәзер*); **хәзергә** — пока. (*Хәзергә* сау булып торыгыз); **хәзерлек** — подготовка; готовность (Имтиханнарга *хәзерлек* әйбәт бара); **хәзерләргә** — готовить; заготовлять (Кышка гөмбә *хәзерләп* куйдым) [Сафиуллина, 1996, с. 111]; *хәзерләгән* ди, көтеп тор! [Сафиуллина, 2001, б. 281].

Диләрә, синең китап, дәфтәрләрең *әзерме*? [Сафиуллина һ.б., 2013, 1 кисәк, б. 4]. Беркөнне умартачы бабай белән әлеге малай умарталарны кышлыкка *хәзерләп* йөриләр

иде [Шунда ук, б. 45] мин дәрес *хәзерлим* [Шунда ук, б. 89]. Кышка бал *хәзерләнеп* җитте [Шунда ук, б. 93]. Дәресләремне *хәзерләп* бетергәч кенә, мин әнигә булыша башлыйм [Шунда ук, б. 134]. Без аның белән бергә түгәрәкләргә йөрибез, бергә дәрес *әзерлибез*. [Шунда ук, б. 168]. Әлфия, дәресләрен *хәзерләп* бетергәч кенә, урамга чыкты [Сафиуллина һ.б., 2013, 3 кисәк, б. 126].

**Подготовить** бутерброд с икрой — уылдык белән бутербродлар *әзерләү* [Агишев, 2001, с. 45]. **Готовь** сани летом — арбаны кышын *хәзерлә* [Шунда ук, с. 360]. **Готовить** новый спектакль — яңа спектакль *хәзерләү* [Шунда ук, с. 397]. **Участвовать** в заготовке сена — печән *хәзерләүдә* катнашу [Шунда ук, с. 368]. **Подготовка** к сочинению — сочинениегә *хәзерләнү* [Шунда ук, с. 395]. **Накрыть** на стол — табын *хәзерләү* [Шунда ук, с. 408]. В зале молодёжь **приготовилась** к танцам — залда яшьләр биергә *хәзерләнделәр* [Шунда ук, с. 424].

**Выучить** урок — дәресне *хәзерләп* бетерү [Агишев, 2002, с. 76] .

**Готовить** — *әзерләү, хәзерләү*; **готовить** доклад, лекцию — доклад, лекция *хәзерләү*; **готовить** опыт, уроки, подарки к празднику — тәҗрибә, дәресләрне, бәйрәмгә бүләкләр *әзерләү*; **готовить** ванну, постель для гостей — кунакларга ванна, урын-җир *хәзерләү*. Тренер **готовит** лыжи, коньки к соревнованиям — тренер ярышка чаңгы, тимераяклар *хәзерли*. Колхозные механизаторы **готовят** машины и тракторы к весенним работам — колхоз механизаторлары машина-тракторларны язгы эшләргә *хәзерлиләр*. А видел ты когда-нибудь, как **готовят** коня к скачкам? — Атны бәйгегә ничек *әзерләгәнне* кайчан да булса күргәнең бармы? **Готовить** учителей, врачей, агрономов — укытучылар, врачлар, агрономнар *әзерләү*; здесь **готовят** парикмахеров — биредә чәчтараш осталарын *хәзерлиләр*; **готовить** завтрак, ужин — иртәнге, кичке аш *әзерләү* [Шунда ук, с. 86].

**Готовиться** — *әзерләнү, хәзерләнү*; **готовиться** к уроку, к диспуту, к празднику — дәрескә, диспутка, бәйрәмгә *әзерләнү*; заранее, тщательно **готовиться** — алдан ук, җентекләп *хәзерләнү*. Я **готовлюсь** к сочинению по татарскому языку — мин татар теленнән сочинение язарга *әзерләнәм* [Шунда ук, с. 87].

**Заняться** — *уку, хәзерләнү, дәрес хәзерләү, өйрәнү*; **заняться** с отстающими учениками — артта калган укучылар белән *хәзерләнү*; **заняться** дома, в читальном зале — өйдә, уку залында дәрес *хәзерләү*; **заняться** по вечерам, по ночам — кичләрен, төннәр буе дәрес *хәзерләү*; **заняться** целый день, каждый день — көн буе, көн саен дәрес *хәзерләү*. Вместо того чтобы **заняться**, они гоняют мяч — дәрес *хәзерләү* урынына, алар туп тибеп йөриләр [Шунда ук, с. 130].

«Татарча-русча уку-укыту сүзлеге»ндә дә *хәзер* һәм *әзер* сүзләрен мәгънә ягыннан аерып бирү юк: *хәзер — хәзерге, хәзергә, хәзергәчә, хәзерлек, хәзерлекле, хәзерләнергә, хәзерләргә, хәзерләү* [Татарча-русча ..., б. 321].

Татар сөйләмен хаталы язылышлы һәм әйтелешле сүзләр белән «баетуга» төрле буын язучылары һәм шагыйрьләре дә үз өлешен өстәгән, өсти тора. Татар һәм рус мәктәбе өчен чыгарылган татар теле дәреслекләренә кертелгән түбәндәге текстларны, танылган шагыйрь яки язучы шулай язгач, укытучы ничек укытсын?! Элек тә, хәзер дә татар мәктәбендә — татар баласына, рус

мәктәбендә татар һәм башка милләт баласына язылганча укыткан һәм бүген дә укыта, билгеле:

Үзе зачетларын *хәзерләргә*
Барыннан да соңрак тотына.
*(Һ. Такташ. Алсу.)*

«Чаба торган атны бөтенләй башкача *хәзерләргә* тиешле була икән. Алмачуар тиз арада сабан туе буласын белә, анда үзенең чабасын да сизә һәм шуңа бик нык *хәзерләнә*. Минем *хәзерләнүем* дә аныкыннан ким түгел» *(Г. Ибраһимов. Алмачуар)*. «Ниһаять, малайның *хәзерлеген*, тырышлыгын һәм яшь агын да искә алып, дүртенче класстан алтынчыга күчерделәр» *(М. Әмир. Саф күңел)*. «Син һәрвакыт хәзерләнеп кил. Дәресләреңне *әзерләдеңме*? Динәнең дәрескә *әзерләнәсе* бар» *(Т. Миңнуллин. Үзебез сайлаган язмыш)*.

Татар мәктәбе өчен чыгарылган дәреслеккә әсбапны төзүчеләр [Сафиуллина һ.б., 2013, 1 кисәк, б. 101] Р. Вәлиевнең «Барысын да яратам» шигырен керткән. Матур шигырь. Текстта урынлы кулланылмаган бер генә сүзе бар: «Дәрес *хәзерләгән* чакта Абыемны яратам». Шундый ук мисал рус мәктәбендә укучы рус телендә сөйләшүче балалар өчен чыгарылган дәреслектә дә бар. Әсбапны төзүче [Хәйдәрова, б. 28] һәм шигырьнең авторы гына башка — Б. Рәхмәт: «Тәлинкә, кашыклар, чәнечке, пычаклар Тарата дежурный — аш урыны *хәзерли*». Дәреслектә ике биттән соң Ш. Галиев шигыре урнаштырылган: «Без *әзерлибез* табын, Китереп бөтен ягын».

Сүзлекләрдә, дәреслекләрдә, чәчмә һәм лирик әсәрләрдә нигә *әзер* сүзе — *хәзер*, *хәзер* сүзе *әзер* сүзенең синонимы буларак кулланыла? Алай да, болай да ярый, янәсе. Кайсы язучы яки шагыйрь ничек тели, шулай яза. Дәреслекне төзүче язучы яки шагыйрь җибәргән хата өчен җаваплылыкны үз өстенә алмый. Укучы, сүзнең асыл мәгънәсен аңламыйча гына, язма эшләрен башкара, телдән аралаша. Укытучы исә, укучысы язма һәм телдән сөйләмендә *әзер* сүзе урынына — *хәзер*, *хәзер* сүзе урынына *әзер* сүзен кулланса да, хатага санамый.

Татар теленә өйрәнүче рус балалары, аптырап һәм гаҗәпләнеп, өйрәтүчесенә гел бер сорауны бирә: «Рус телендәге *сейчас* һәм *готовый* сүзләренең мәгънәсен татар телендә мәгънәсе белән тәңгәл килерлек кайсы сүз белән тәрҗемә итсәң дөрес була?». Алар өчен татар телендә *сейчас* сүзеннән — *готовый, готовый* сүзеннән *сейчас* сүзе белдергән мәгънәләр ясалу бик гаҗәп һәм шикле тоела.

Телебезгә карата шундый мөнәсәбәтне акларга ярамый. Сөйләмебездә һәр сүзне, мәгънәсен аңлап, тиешле урынында гына кулланырга өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәк.

| Сүз | Кайсы сүз төркеменә карый? | Соравы | Җөмләдәге (сөйләмдәге) вазифасы | Тамырга ясагыч кушымча ялганып ясалган яңа сүзләр |
|---|---|---|---|---|
| **хәзер** | мөстәкыйль сүз төркеме **рәвеш** | кайчан? | фигыльне ачыклап, эшнең — үтәлү, башкарылу; хәлнең булу вакытын белдерү | хәзер**гә**, хәзергә**чә** хәзер**ге**, хәзерге**чә** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **хәзер** | **ымлык** | | кушылган эшнең үтәлешенә карата сөйләүченең тискәре мөнәсәбәтен, тойгысын белдерү: Хәзер*, син әйткән, мин эшләгән диярләр, көтеп тор*! | |
| **әзер** | ярдәмлек сүз төркеме **хәбәрлек сүз** | | 1) **кемнең дә булса** нәрсәнедер эшләргә әзер яки әзер түгел икәнлеген күрсәтү<br>2) **нәрсәнең дә булса** кулланылышка әзер яки әзер түгел икәнлеген күрсәтү | әзер**лә**<br>әзерлә**ү**<br>әзерлә**үче**<br>әзерлә**мә**<br>әзер**лек** |

Шуны истән чыгармыйк: хезмәтендә *хәзерләнгәнлек, хәзерләндерү, хәзерләнү, хәзерләтү, хәзерләү, хәзерләүче, хәзерлек, хәзерлекле, хәзерлеклелек, хәзерлексез, хәзерлексезлек, хәзерләмә* сүзләрен кулланган дәреслек төзүче укытучы һәм тел галиме, сүзлек төзүчеләр, язучылар һәм шагыйрьләр укучыларына, телебезне өйрәнүчеләргә, ким дигәндә, берьюлы ике хата — орфографик һәм сөйләм хатасы «бүләк итә».

Шунысы да бар: *хәзер* сүзендә басым беренче иҗеккә төшә, димәк, тел законына нигезләнсәк, югарыда санап үтелгән сүзләрдә дә ул беренче иҗектә калырга тиеш: *хәзер — хәзерлек — хәзерлекле — хәзерлеклелек*. Бусы исә татарның сөйләм телен көлке хәленә төшерерлек тагын бер — өченче хата булыр иде.

Татар телендә тамыр сүзнең соңгы иҗегенә төшкән басым гына тамырга ялганган кушымчаларга күчә ала. Мәсәлән:
*әзер — әзерлек — әзерлекле — әзерлеклелек*
*бакча — бакчачы — бакчачылар — бакчачыларга*

*Әзер* һәм *хәзер* сүзләре ярдәмендә белдерелгән мәгънәләр арасында бәйләнеш, гомумән, юк. Алар эчтәлеге ягыннан да, формасы ягыннан да туры килми торган лексик берәмлекләр.

## Әдәбият

*Асадуллин А.Ш.* Учимся говорить, читать и писать по-татарски. Казань: Мәгариф, 1993. 151 с.

*Агишев Х.Г., Гайнуллина Л.Х.* Русско-татарский словарь словосочетаний. Казань, 2001. Вып. 1: Имена существительные. 535 с.

*Агишев Х.Г., Гайнуллина Л.Х.* Русско-татарский словарь словосочетаний для учащихся. Казань, 2002. Вып. 2: 1000 и один глагол. 462 с.

Русско-татарский словарь. М.: Русский язык, 1985. 736 с.

*Нуриева А.Х.* Татар теле: Өчьеллык башл. татар мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2000. 159 б.

*Нуриева А.Х., Саттарова Н.А.* Татар теле: Өчьеллык башл. татар мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 1993. 175 б.

*Сафиуллина Г.М., Хәсәнова Ф.Ф., Мөхәммәтҗанова Ә.Г.* Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. Казан: Мәгариф — Вакыт, 2013. 1 нче кисәк. 135 б.

*Сафиуллина Г.М., Хәсәнова Ф.Ф., Мөхәммәтҗанова Ә.Г.* Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф — Вакыт, 3 нче кисәк. 2013. 111 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1996. 285 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарча-русча фразеологик сүзлек. Казан: Мәгариф, 2001. 335 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татарча-русча сүзлек: ике томда. Казан. Мәгариф, 2007. Т. 1. 726 б.

Татарча-русча сүзлек: ике томда. Казан:. Мәгариф, 2007. Т. 2. 726 б.

Татарча-русча уку-укыту сүзлеге. М.: Русский язык, 1992. 416 с.

*Хәйдәрова Р.З.* Татар теле һәм уку китабы. Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан: Мәгариф, 2006. 151 б.

***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының татар теле*
*һәм татар телен укыту методикасы кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145´373

***И.И. Сабитова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ «КЕШЕ» СҮЗЕНӘ КАРАГАН ТЕМАТИК ТӨРКЕМЕ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ СҮЗЬЯСАЛЫШ ЧЫЛБЫРЛАРЫ

В статье рассматриваются словообразовательные цепи, образованные от лексики тематической группы «Человек». Изучение структуры данных цепочек предполагает словообразовательный анализ всех входящих в цепочку звеньев. Словообразовательные цепи, образованные от лексики тематической группы «Человек», характеризуются по количеству компонентов — как бинарные и полинарные; по лексико-грамматической соотнесённости исходного слова и конечного звена — как линейные и кольцевые; по характеру присоединения суффиксов, последовательному и чересступенчатому — как полные и неполные.

**Ключевые слова:** тематическая группа, словообразование, словообразовательное гнездо, словообразовательная парадигма, словообразовательная пара, словообразовательная цепь, производное и непроизводное слово, бинарные и полинарные цепи, прямые и кольцевые цепи, полные и неполные цепи.

Татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган лексика зур сүзьясалыш потенциалына ия. Шушы төркемгә караган сүзләр татар телендә иң зур күпчелекне тәшкил итә һәм татар теленең төп лексик фондына керә, аралашуда еш кулланыла һәм тотрыклы сүзләр булып саналалар. Бу, танып белү процессында кеше үзен һәм үзенең яшәешен үзәккә куеп, яңа атамаларга исем биргәндә, аны иң элек нәкъ менә шул яктан чагыштырып, метафорик юл белән яңа төшенчәләр барлыкка китерү белән аңлатыла.

Сүзләр ясалуда иң әһәмиятле һәм иң катлаулы берәмлекләренең берсе — сүзьясалыш оясы. Сүзьясалыш оясы — ясалышлары буенча үзара бәйләнгән һәм уртак мәгънәгә ия булган тамырдаш сүзләр җыелмасы. Ул сүзьясалыш парларын, чылбырларын һәм парадигмасын үз эченә ала. Бу мәкаләдә татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган сүзләрдән ясалган сүзьясалыш ояларындагы сүзьясалыш чылбырларына кыскача характеристика бирелә.

Рус тел белемендә сүзьясалыш чылбырлары тирәнтен һәм һәрьяклап өйрәнелгән. Моның шулай икәнлеге О.П. Ермакова, А. Кдырбаева, С.А. Тихонов, А.И. Моисеев, Г.П. Нещименко, Б.Б. Таджибаев, А.Н. Тихонов, И.А. Ширшов һ.б. дериватолог хезмәтләреннән, төрле грамматикалардан һәм дәреслекләрдән күренә. Аларда сүзьясалыш чылбырына төрле билгеләмә бирелсә дә, нигездә алар бер үк фикерне белдерәләр. С.А. Тихонов сүзьясалыш чылбырын «ряд однокоренных слов, находящихся в отношениях последовательной производности» дип аңлата [Тихонов С., с. 264]. О.В. Закирова тарафыннан югары уку йортлары студентлары өчен язылган дәреслектә сүзьясалыш чылбыры «Ряд однокоренных слов, находящихся в отношениях последовательной мотивированности, производности» дип атала [Закирова, с. 20]. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Бүгенге көндә татар тел белемендә сүзьясалыш чылбырларын аерым алып өйрәнгән хезмәтләр юк.

Бары тик татар теленең сүз ясалышын тикшергән хезмәтләрдә генә сүзьясалыш чылбырларының кайбер аспектлары яктыртылган. Ф. Хисамова үзенең югары уку йортлары өчен язган дәреслегендә «Бер үк тамырга бер-бер артлы берничә ясагыч кушымча ялганып сүз ясалу сүзьясалыш чылбырын барлыкка китерә» дип яза һәм сүзьясалыш чылбырында сүз ясагыч нигез һәр этапта үзгәреп торуын билгеләп үтә. Сүзьясалыш чылбырына кергән кушымчаларның еш кына кушылып бирелү очракларын ясагыч кушымчаларның эзлекле ялгануы, ягъни сүзьясалыш чылбыры, дип карау телнең морфологик төзелешен аңлату өчен һичшикшез отышлырак, дигән фикергә килә [Хисамова, б. 34].

Безнеңчә, сүзьясалыш чылбырын бер-берсенә бер-бер артлы бәйләнеп килгән сүзләр хасыйл итә. Сүзьясалыш чылбырын сүзьясагыч кушымчалар кушып ясалган тамырдаш сүзләр рәте дип тә әйтеп була.

Мисалга балтыр, кул I, гәүдә ояларын алыйк:

**БАЛТЫР** *и. анат.*
балтыр-**ган** *и. бот.*
балтырган-**лык** *и.*
...

**КУЛ** *I и. анат.*
кул-*лан(у) ф.*
куллан-**ма** *II с.*
кулланма-**лык** *и.*
...

**ГӘҮДӘ** *и.*
гәүдә-**лән***(ү)* ф.
гәүдәлән-**еш** *и.*
...

Оялардан күренгәнчә, *балтыр* сүзенә *-ган* сүзьясагыч кушымчасы кушылып *балтырган* сүзе ясалган, *балтырган* сүзенә *-лык* кушымчасы кушылып *балтырганлык* сүзе ясалган; *кул* сүзенә *-лан* сүзьясагыч кушымчасы кушылып *куллан* сүзе ясалган, *куллан* сүзенә *-ма* кушымчасы кушылып — *кулланма*, *кулланма* сүзенә *-лык* сүзьясагыч кушымчасы кушылып *кулланмалык* сүзе ясалган; гәүдә сүзенә *-лән* сүзьясагыч кушымчасы кушылып *гәүдәлән* сүзе ясалган, *гәүдәлән* сүзенә *-еш* кушымчасы кушылып *гәүдәләнеш* сүзе ясалган. Шулай итеп, *балтыр — балтырган — балтырганлык, кул-куллан — кулланма — кулланмалык, гәүдә — гәүдәлән — гәүдәләнеш* чылбырлары барлыкка килгән.

Чылбырның баш сүзе бер үк вакытта ояның баш сүзе дә булып тора. Ул ясалма булмаган сүз һәм бер үк вакытта ясаучы функциясен дә үти:

**КОРСАК** *и. анат.*
корсак-**лан***(у) ф.*
корсак-**лы** *с.*
корсаклы-**лык** *и.*
...

**БАШ** *и. анат.*
баш-**ак** *и.*
башак-**лан***(у) ф.*
башак-**лап** *рәв.*
...

Чылбырның беренче һәм соңгы буыныннан калганнары ясалма һәм ясаучы сүз булып тора. Мисалга *тел* сүзеннән ясалган ояны һәм шул оядагы *тел — телә — теләк — теләктәш — теләктәшлек* чылбырын алыйк. *Тел* сүзе ояның баш сүзе һәм чылбырның беренче буыны, ул *телә* сүзен ясый, димәк, телә сүзе ясалма сүз һәм, үз чиратында, *теләк* сүзен ясаучы сүз дә булып тора. *Теләк* сүзе, үз чиратында, ясалма сүз һәм *теләктәш* сүзе өчен ясаучы сүз дә. *Теләктәш* сүзе ясалма сүз һәм бер үк вакытта *теләктәшлек* сүзе өчен ясаучы сүз дә була. Чылбырның соңгы буыны ясалма сүз генә була һәм ясаучы функциясен үтәми. Әлеге очрак-

та бу — *теләктәшлек* сүзе.

Тел белемендә сүзьясалыш чылбырларын, төзелешләренә карап, берничә төргә бүләләр.

Компонентлары саны буенча бинар һәм полинар чылбырлар була (чылбырның теләсә кайсы буыны, шул исәптән баш сүз дә, чылбырның компоненты булып санала). Бинар чылбырлар ике сүздән — баш сүз һәм бер ясалма сүздән тора. Татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган атамаларның күпчелеге бинар чылбыр ясыйлар. Мәсәлән, *үт — үтләү, уч — учлап, түш — түшлек, тубык — тубыктан, төк — төкләч, тир — тирчән, тел — телләнү, терсәк — терсәкләшү, ми — мисез, селәгәй — селәгәйләү, муен — муеннан, мыек — мыеклач* һ.б. бик күпләр. Бу чылбырларда баш сүз ролен *үт, уч, түш, тубык, төк, тир, тел, терсәк, ми, селәгәй, муен, мыек сүзләре уйнаса, үтләү, учлап, түшлек, тубыктан, төкләч, тирчән, телләнү, терсәкләшү, мисез, селәгәйләү, муеннан, мыеклач* сүзләре, үз чиратында, ясалма сүзләр булалар. Анализдан күренгәнчә, *аңкау, ашык, бәвел, бәдән, беләзек, биз, бүксә, бүсер, җелек, җилкә, ияк, касык, кендек, керфек, кимек, күкәй, лайла, лепкә, маңка, ми, миң, муен, сакал, селәгәй, сөял, сул, сүрү, сыйрак, сырт, талак, тән, танау, тәпи, тәрәт, терсәк, тизәк, тубык, үкчә, үңәч, үпкә, үт, чигә, элпә, эрен, яңак, яры* оялары бары тик бинар чылбырлардан тора. Шулай ук башында алынма сүз булган ояларга да *(артерия, вена, диафрагма, лимфа, трахея, бәвел, бәдән)* бу күренеш хас.

Полинар чылбыр өч һәм аннан артык компоненттан, ягъни баш сүз һәм ике һәм аннан артык ясалма сүздән тора. Татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган атамалардан ясалган ояларда өч, дүрт һәм биш компонентлы чылбырлар да очрый. Сан ягына килгәндә, полинар чылбырлар арасында өч компонентлы чылбырлар күбрәк: *тир — тирчән — тирчәнлек, күз — күзәнәк — күзәнәкчел, төк — төкле — төклегән, кул — култык — култыклау, теш — тешлә — тешләм, муен — муенчак — муенчаклау, тел — телмәт — телмәтлек, тамак — тамакай — тамакайлану* һ.б., һ.б. Бу чылбырларда *тир, күз, төк, кул, теш, муен, тел, тамак* баш сүзләр, аларның һәрберсеннән икешәр сүз *(тирчән — тирчәнлек, күзәнәк — күзәнәкчел, төкле — төклегән, култык — култыклау, тешлә — тешләм, муенчак — муенчаклау, телмәт — телмәтлек, тамакай — тамакайлану)* ясалган. *Авыз, арка, аяк, бавыр, балтыр, бармак, беләк, бил, бит, борын, бөер, бугаз, буын, гәүдә, иң, ит, йодрык, йөз, йөрәк, казна, кан, карын, каш, колак, корсак, күкрәк, маңгай, муен, сеңер, сөяк табан, тамак, тамыр, тез, түш, умыртка, уч, чәч, яшь* сүзләреннән ясалган ояларда өч компонентлы полинар чылбырлар очрый.

Дүрт компонентлы полинар чылбырлар *баш, май, мыек, теш, тир, төер, төк, шеш* һәм *эч* ояларында ясалганнар. Мәсәлән, *баш — башка — башкача — башкачалану, эч — эчү — эчүче — эчүчелек, мыек — мыекча — мыекчасыз — мыекчасызлар, тир — тирләү — тирләүчән — тирләүчәнлек, шеш — шешен — шешенке — шешенкелек* һ.б.

Татар телендә иң озын чылбыр биш буыннан тора һәм алар чагыштырмача сирәк очрый. Биш компонентлы полинар чылбырлар «кеше» тематик төркеменә караган атамалардан ясалган ике генә ояда күренә *(күз, тел* оялары*). Күз-әт-ү-чән-лек, тел-*

*ә-к-тәш-лек, тел-ә-к-тәш-че, тел-ә-к-тәш-ле, тел-ә-к-тәш-сез* чылбырларының һәркайсы биш компоненттан тора.

Безнеңчә, бу *күз, тел* атамаларының телебездә бик еш кулланылуы, үз чиратында, әлеге сүзләрнең зур сүзьясалыш потенциалына ия булуы белән аңлатыла.

Статистик анализ сан ягыннан бинар чылбырларның полинар чылбырларга караганда күпкә артык булуын күрсәтә.

Чылбырның беренче һәм соңгы буыны нинди сүз төркеменә керүенә карап, сүзьясалыш чылбырлары туры һәм түгәрәк чылбырларга бүленәләр. Чылбырның беренче һәм соңгы буыны төрле сүз төркемнәренә караса, туры чылбыр хасыйл була. Мәсәлән, *баш — башка — башкача — башкачалану, баш — башсыз — башсызлану, бит — битсез — битсезләнү, борын — борынчык — борынчыклау* чылбырларының беренче буыннары *(баш, бит һәм борын* сүзләре) — исем, ә соңгы буыннары *(башкачалану, башсызлану, битсезләнү, борынчыклау* сүзләре) — фигыль, димәк, бу чылбырлар туры.

Түгәрәк чылбырда беренче һәм соңгы буын бер үк сүз төркеменә карый. Мисалга *баш — башсыз — башсызлык, бит — битсез — битсезлек, йон — йонлач — йонлачлык, йөз — йөзсез — йөзсезлек, йөрәк — йөрәксез — йөрәксезлек, кан — кансыз — кансызлык* чылбырларын алыйк. Бу чылбырларда беренче һәм соңгы буын — исем *(баш — башсызлык, бит — битсезлек, гәүдә — гәүдәләнеш, йөз — йөзсезлек, йөрәк — йөрәксезлек, кан — кансызлык)*. Шуңа күрә дә бу чылбырлар түгәрәк чылбырлар була. Анализ туры чылбырларның, түгәрәкләренә караганда, күбрәк булуын күрсәтте.

Татар телендә сүзьясалыш чылбырлары үзләренә генә хас булган билгеле бер сүзьясалыш модельләре нигезендә ясалалар. Алда китерелгән мисаллардан аларның күбесенең бүгенге көндә дә продуктив калыплар һәм «кеше» тематик төркеменә караган атамалар ясауда актив катнашулары ачык күренә. Шул ук вакытта продуктивлыгы түбән булган модельләр буенча ясалган атамалар очрывын да билгеләп үтү урынлы булыр: *кабырга — кабырган, каш — кашага, каш — кашлак, каш — кашлан* һ.б.

Сүзьясагыч кушымчаларның сүзгә бер-бер артлы яки бер баскыч сикертеп тоташып сүз ясавына карап, сүзьясалыш чылбырлары тулы һәм тулы булмаган чылбырларга бүленә. Тулы чылбырга мисал итеп *эч — эчәк — эчәклек, уч — учла — учлам, умыртка — умыркалы — умыркалылар, төк — төкчә — төкчәле — төкчәлелек* һ.б.ларны күрсәтергә була. Бу чылбырларда һәр буын берcharacterбер артлы сүзьясагыч кушымчалары кушылып ясалган.

Бер баскыч сикертеп, ягъни бер баскыч төшереп калдырып сүз ясау рус тел белемендә «чрессступенчатое словообразование» дип атала. А.Н. Тихонов фикеренчә, «Возможность непосредственной смысловой связи между словами различных ступеней словообразования создаёт благоприятную почву для образования слов с пропуском любого количества словообразовательных звеньев. Под покровительством семантики чрессступенчатое словообразование в современном русском языке играет исключительно важную роль, проникает во многие области словообразования, активно расширяет свою сферу действия, особенно в терминологической лексике» [Тихонов А., 1985, с. 47]. Бер баскыч си-

кертеп сүз ясау рус сүзьясалышына хас күренеш булса да, ул сирәк кенә татар телендә дә, бигрәк тә терминологик лексика ясауда очрый. «Кеше» тематик төркеменә караган атамалардан ясалган ояларда да бер баскыч сикертеп ясалган сүзләр бар. Мәсәлән, *эч — эчтәлек — эчтәлекле, эч — эченнән, бавыр — бавыргалык* һ.б. Бу очракта *-тә, -ен, -га* кушымчалары яңа сүз ясауда катнашмыйлар. Шуңа күрә дә бу чылбырлардан *-тә, -ен, -га* кушымчалары кушылып ясалган буыннар *(эчтә, эчен, бавырга)* төшеп калган һәм тулы булмаган чылбырлар хасыйл булган.

Димәк, татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган атамалардан ясалган сүзьясалыш чылбырлары структур яктан бинар һәм полинар, туры һәм түгәрәк, тулы һәм тулы булмаган чылбырлар барлыкка китерәләр. Полинар чылбырларның өч, дүрт, хәтта биш компонентлылары да бар. Сан ягыннан бинар чылбырлар полинар чылбырларга караганда күпкә артык булса, полинар чылбырлар арасында өч компонентлы чылбырлар күбрәк. Күпкомпонентлы чылбырлар ясалу кайбер атамаларның телебездә бик еш кулланылуы һәм әлеге сүзләрнең зур сүзьясалыш потенциалына ия булуы белән аңлатыла. Квантитатив анализ туры чылбырларның, түгәрәкләренә караганда, күбрәк булуын күрсәтте. Бу тематик төркемгә караган лексикадан ясалган ояларда, сирәк кенә булса да, тулы булмаган, ягъни бер баскыч сикертеп ясалган чылбырлар да очрады. «Кеше» тематик төркеменә караган атамалардан ясалган ояларда чылбырлар продуктив һәм продуктивлыгы түбән булган модельләр буенча төзелгән. Продуктив модельләр буенча ясалган сүзьясалыш чылбырлары продуктивлыгы түбән булган модельләр буенча ясалганнарга караганда күбрәк.

## Әдәбият


*Ермакова О.П.* Словообразовательная цепь в семантическом аспекте // Актуальные проблемы русского словообразования: сб. ст. Ташкент. 1982. С. 32—36.

*Закирова О.В.* Современный русский литературный язык. Словообразование: учебно-методический комплекс. Елабуга: изд-во ЕГПУ. 2010. 39 с.

*Земская Е.А.* Словообразование как деятельность. М.: Наука. 1992. 221 с.

*Лыков А.Г., Клечковская Г.А.* Гнездо как высшая словообразовательная единица (к вопросу о соотношении и классификации единиц русского словообразования) // Русская словообразовательная синтагматика и парадигматика: сб. ст. Краснодар. 1991. С. 84—91.

*Моисеев А.И.* Словообразовательная цепь как разновидность словообразовательной парадигмы // Русская словообразовательная синтагматика и парадигматика: сб. ст. Краснодар. 1991. С. 119—129.

Татарская грамматика. Т. I. Казань: Татар. кн. изд-во. 1993. 384 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда / редкол.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров һ.б. СССР ФА КФ Г. Ибраһимов ис. ТӘТИ. Казан: Татар. кит. нәшр. 1977; 1981.

*Тихонов А.Н.* Словообразовательный словарь русского языка: в 2-х т. Ок. 145 000 слов. М.: Рус. яз. 1985. Т. 1. Словообразовательные гнёзда. А.—П. 856 с.

*Тихонов С.А.* О статусе глагольного словообразования // Актуальные проблемы русского словообразования: сб. ст. Ташкент, 1970. 264 с.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф. 2006. 335 б.

*Ширшов И.А.* Словообразовательная цепь и явление полимотивированности // Актуальные проблемы русского словообразования: сб. ст. Ташкент. 1982. С. 91—95.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´366

***Ю.Ф. Борһанова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОГРАФИЯ ЯГЫННАН ТЕРКӘЛМӘГӘН ИНТЕРФИКСЛАРЫН ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ АНАЛИЗ ЯРДӘМЕНДӘ ТИКШЕРҮ

Настоящая статья посвящена экспериментальному анализу незафиксированных интерфиксов татарского языка посредством инструментальной фонетики с привлечением двух дикторов. С помощью осциллограмм доказано наличие незафиксированных орфографией татарского языка интерфиксов, а именно орфографически неоформленного интерфикса «w».

**Ключевые слова**: морфема, интерфикс, интерфиксация, орфографически зафиксированные интерфиксы, орфографически незафиксированные интерфиксы, инструментальная фонетика.

Соңгы елларда гомуми теория буенча һәм татар теле сүз ясалышының конкрет проблемаларын яктырткан күпкырлы әдәбият тагы да яңа һәм кызыклы фәнни хезмәтләр белән баетылды, тулыланды. Ләкин бүгенге көндә, кайбер бәхәсле моментлар аерым авторларның эшләрендә чагылыш тапса да, проблеманың аерым аспектлары ахырга кадәр өйрәнелмәгән.

Сүзьясалышының механизмын һәм сүзнең структурасын өйрәнү, ике морфема арасында барлыкка килгән интерфиксация күренешен тикшерү — галимнәр арасында зур кызыксыну уята.

Сүзнең нигезе белән суффикс арасында чөй — интерфикс барлыкка килә. Интерфикс — үз мәгънәсе булмаган, тамыр белән башка кушымчаны ялгарга ярдәм итә торган элемент. «Морфемный шов — граница морфемы в слове, стык морфем. На морфемном шве происходят различные морфонологические преобразования основы, приспособление её к сочетаемости с суффиксами, взаимоприспособление производящих основ и словообразующих суффиксов, чередование звуков, усечение производящей основы, наложение морфем, вставка интерфиксов и др.» [Энциклопедический ..., с. 557].

Татар тел белеменең теориясендә интерфикслар турында билгеле бер фикер әйтелмәгән, бүгенге көнгә кадәр әле һаман да төрле карашлар яшәп килә.

Сузык авазга тәмамланган нигез һәм сузык авазга башланган суффикс арасында барлыкка килгән өстәмә аваз, гомумән, мондый күренешне өйрәнүгә кызыксыну XX гасырның башында ук уяна. Галимнәр һәрвакытта дөрес язуның әһәмияте, роле һәм җәмгыятьтәге урыны турында, орфография әйтелешенә туры килергә тиеш, дигән фикерләрне әйтеп килделәр. Бу турыда Х. Максуди, Г. Шәрәф, М. Корбангалиев, А. Мостафа, Г. Нугайбәк, Г. Алпаров, Х. Курбатов, Ш. Асылгәрәев, Х. Сәлимов, К. Мусаев, М. Зәкиев, Ф. Ганиев хезмәтләрендә искә алына.

«Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий» дигән хезмәттә интерфиксация күренешенә һәм «интерфикс» төшенчәсенә түбәндәге билгеләмә бирелә. «**Интерфикс** *(лат inter «между» + fixus «прикреплённый»)*. Такие части слова не облада-

ют существенным признаком морфемы — не имеют значения. Поэтому они не являются морфемами. В составе слова они выполняют строевую роль, используются как соединительные элементы между его частями. Отсюда их общее название — интерфиксы. Это понятие ввела в научный обиход Е.А.Земская». [Энциклопедический ..., с. 524]. «**Интерфиксация** — присоединение словообразовательных суффиксов к производящей основе с помощью интерфиксов: *кофе-**й**-ня, кофе-**й**-ник, кофе-**й**-н-ый*» [Шунда ук, б. 526]. Интерфикс — морфеманың иң әһәмиятле билгесенә ия түгел, аның бернинди мәгънәсе дә юк. Шуңа күрә интерфикслар морфема түгел. Алар бары тик сүз эчендә бәйләү, кушу, ялгау, берләштерү функциясен, төзү ролен генә үтиләр, сүзнең өлешләрен бәйләп торучы элементлар булып киләләр.

Татар телендә интерфиксларны орфография ягыннан теркәлгән һәм теркәлмәгән интерфиксларга бүлеп карарга була. Мәсәлән, бүлем саннары ясалганда, сан һәм *-ар/-әр* суффиксы арасында *-ш* аффиксы барлыкка килә: *алты — алты+ш+ар* ‘по шесть’, *җиде — җиде+ш+әр* ‘по семь’, яисә суффикслар сузык авазга тәмамланган тамырга яисә нигезләргә ялганганда, тамыр һәм *-ык/-ек, -ыч/-еч* суффикслары арасында яңа элемент — *«в»(w)* тартыгы барлыкка килә: *шарлавык — шарла+в+ык* ‘водопад’, *чәрелдә+в+ек* ‘свиристель’ һ.б. Күргәнебезчә, аерып алынган интерфикслар бернинди мәгънә белдермиләр, бары тик тамыр һәм кушымчаны бәйләп киләләр һәм орфография ягыннан теркәлгән интерфикслар төренә керәләр.

Әмма, сузык авазга тәмамланган тамыр һәм сузык авазга башланган суффикс арасында орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикс та барлыкка килә ала. Мәсәлән: дару ‘лекарство’ — *дару+w+ым, дару+w+ың, дару+w+ы, дару+w+ыбыз, дару+w+ыгыз, дару+w+ы* (*орф.* дару — даруым, даруың, даруы, даруыбыз, даруыгыз, даруы). Орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикс бары тик бер генә — *«в(w)»*.

Фигыльнең төшем юнәлеше формасы татар телендә *-л (-ыл/-ел)* суффиксы ярдәмендә, кайтым юнәлеше *-н (-ын/-ен)*, уртаклык юнәлеше *-ш, -ыш/-еш*, йөкләтү юнәлеше *-т* суффиксы ярдәмендә ясала. Барлык очракта да *у, ю (йу)* сузыкларына тәмамланган тамыр һәм суффикс арасында чөй кала — ул орфография ягыннан теркәлмәгән «w» интерфиксы: *шу* ‘катайся’ — *шу+w+ыл, шу+w+ыш*; *ку* ‘гони’— *ку+w+ыл, ку+w+ыш*; *ю(йу)* ‘мой’ — *йу+w+ыл, йу+w+ын, йу+w+ыш* һ.б.

Тикшеренү барышында туган фикерләргә һәм фактик мәгълүматларга таянып, эксперименталь-фонетик анализ үткәргәннән соң, татар телендә интерфиксларның булуы, интерфиксларның орфография ягыннан теркәлгән булуы, шул ук вакытта орфография ягыннан теркәлмәгән интерфиксларның барлыгы да ачыкланды. Мондый тикшеренү Казан (Идел буе) федераль университетының эксперименталь фонетика лабораториясендә үткәрелгән нәтиҗәләргә таянып ясалды. Эксперимент өчен ике диктор чакырылды: Ибраһимов Тәвзих Ибраһим улы һәм Гарифуллин Рәхимулла Кәлим улы.

Мәгълүмат нәтиҗәләре күрсәтүенчә, орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикслар бары тик грамматик формаларда гына киләләр. Орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикс бер генә — «в» (w).

Инструменталь фонетика махсус приборлар, җайланмалар ярдәмендә телнең яңгырашын, әйтелешен, сөйләмен тикшерә. Хәзерге заман инструменталь фонетика дистәләгән төгәл прибор һәм җайланмалар бе-

ләп эш итә, авазга җентекле анализ бирә, сөйләмнең акустик ягы махсус компьютер программалары ярдәмендә тикшерелә.

Сүзләрнең әйтелешен эксперименталь яктан тикшергәннән соң, «в»(w) интерфиксы төгәл итеп билгеләнгән, аның булуы бездә бернинди шик уятмый. Ләкин татар теле орфографиясендә шул аваз бернинди хәреф, тамга белән билгеләнмәгән. Бу авазның әйтелешенә күп кенә факторлар тәэсир итә: сөйләмнең темпо-ритмик төзелеше, тавышның тембры — «ир-ат, хатын-кыз тавышы», теге яки бу диалект, һөнәр вәкиле булу, яшь үзенчәлеге һәм белем дәрәҗәсенең нинди булуы; һәм, әлбәттә, сөйләм агышына эмоциональ факторның да йогынтысы шактый.

Мәгълүмати технологияләр үсеше барышында яңгыраган сөйләмне сегментларга бүлү проблемасы яңача куела. Эксперименталь анализ үткәрү өчен төп материал итеп сүз составында орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикслар (сузык авазга тәмамланган тамыр һәм сузык авазга башланган суффикс арасында килеп чыккан аваз) дип билгеләнгән сүзләр кулланылды: *даруы — дару+w+ы* ‘его лекарство’, *юыныйк — ю+w+ыныйк* ‘помоемся’, *туачак — ту+w+ачак* ‘родится’, *юарга — ю+w+арга* ‘помыть’ һ.б. Тикшерелә торган [w] авазы осциллограммаларның һәр очрагында да билгеләнде, аларның төгәл чикләре табылды һәм аерып күрсәтелде. Ике графикта да төп тон ешлыгы үзгәрүнең кәкре сызыгы (кривая изменения частоты основного тона) һәм интенсивлык үзгәрүнең кәкре сызыгында (кривая изменения интенсивности) тирбәлешләр күренә. Бу — «w» авазының бөтен мисалларда да барлыгы турында сөйли.

Татар теленең язылышында рус алфавитында булган барлык хәрефләр дә кулланыла. Кызганыч, яңа алфавитның һәм орфографиянең зур кимчелеге — ирен-ирен [w] авазының мөстәкыйль билгесе, символы юк. Хәрефләрнең булмавы сөйләм әдәби нормаларының бозылуына һәм язылыш кагыйдәләренең кыенлашуына китерә. Язылышта, орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикс «w» татар телендә булган *в, у* хәрефләре белән алмашына.

Сүзләрне анализлаганнан соң, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: орфография ягыннан теркәлмәгән интерфикслар татар телендә бар, аларны орфография ягыннан билгеләргә һәм киләчәктә татар теленең офрографиясенә, «w» авазын хәреф белән күрсәтеп, төзәтмәләр кертергә кирәк.

**Әдәбият**

Татар грамматикасы / ред. М.З. Зәкиев. М.: ИНСАН; Казан: Фикер, 1998. I т. 512 б.

Татар грамматикасы / ред. М.З. Зәкиев. М.: ИНСАН; Казан: Фикер, 2002. II т. 448 б.

Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2 т. / А.Н. Тихонов, Р.И. Хашимов, Г.С. Журавлёва и др.; под общ. ред. А.Н. Тихонова, Р.И. Хашимова. М.: Флинта: Наука, 2008. I т. 840 с.

***Борһанова Юлия Фәрит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: burganovajulia@yandex.ru*

УДК 811.512.145´373

***Г.Р. Гайнетдинова***

# «СӨРӘН СУГУ» КАЛЕНДАРЬ ЙОЛАСЫНЫҢ ТЕКСТЛАРЫ ЛЕКСИКАСЫНА ТАРИХИ-ЛИНГВИСТИК АНАЛИЗ

Изучение лексического значения слова, особенностей их использования является одной из важных областей языкознания. В данной статье проведен историко-лингвистический анализ лексики текстов обряда весенне-летнего цикла «Сөрән сугу» татар Заказанья.

**Ключеве слова:** лексический состав, историко-лингвистический анализ, календарные праздники, обычаи.

Һәр телнең лексик составы — халык тарихының кыйммәтле материалы. Анда халыкның барлыкка килүе, үсеше, көнкүреше, мәдәнияте, рухи һәм матди байлыклары, гомумхалык мәдәнияте үсешендәге роле чагылыш таба.

Сүзнең мәгънәсен, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү тел белеменең әһәмиятле өлкәсе булып тора. Лексиканы тарихи-чагыштырма планда өйрәнү тюркологлар өчен хәзерге көндә дә катлаулы мәсьәләләрнең берсе булып исәпләнә.

Язгы-җәйге ел циклының йолалары һәм бәйрәмнәрен төгәл үткәрү датасы булмаган. Аларны үткәрү һәр елдагы табигый климат шартлары белән бәйле. Төгәл көнен аксакаллар җыены хәл иткән. Шуның белән беррәттән аерым йолалар чәчү эшләре белән бәйләнгән булган: беренчеләре — чәчүгә кадәр, икенчеләре — чәчү көнне, өченчеләре чәчүдән соң үткәрелгән.

«Сөрән сугу» йоласы Казан татарларында теркәлгән. Яшь егетләр бизәлгән атларда йомырка, сөлге җыйганнар. Алар тәрәзә каршысына туктаганнар яисә ишегалдына кергәннәр. Хуҗабикә аларга берничә йомырка чыгарган. «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә *jumurqa* формасында бирелгән. Беренче тапкыр уйгыр язуында булган тыйб китабында (Берлин коллекциясеннән) теркәлгән: *öztä ušaq qart önsär taqïyu jumurqasïn öt birlä sürtsär edgü* — тәндә кечкенә шеш чыкса, аны йомырканың сарысы белән сөртсәң, яхшы булыр. Татар теленең урта диалектында *йоморкъа* формасында китерелгән. «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә түбәндәгечә бирелгән: *йомырка — диал. җŏмŏркъа, йомыртка*. Гомум төрки сүз буларак, йумуртка формасы бирелгән. Сүзлек авторы бу үзгәрешләрне болай аңлата: *ыртка // ертка = ырткы // ертке* аффикслары ярдәмендә *йом-/йум-* тамырыннан ясалган [Әхмәтьянов, б. 229].

Ризыкны үрелгән кабык кәрзиненә — *карнашага, чирмәгә* яисә *кызау, тубалга* салганнар.

*Чирмә* — диалекталь сүз, Минзәлә сөйләшендә кулланыла — йомырка яисә Сабантуй өчен җыелган башка төрле әйберләр салу өчен кулланма.

*Кызау* сүзе *kizlä* сүзеннән (яшерергә, сакларга) килеп чыккан, дип фаразлана. Бу сүз Мәхмүд Кашгарыйның «Дивану лөгат эт-төрк» сүзлегендә китерелгән.

*Тубал* сүзенең килеп чыгышын ике яктан карарга мөмкин: 1) «Татар теленең диалекталь сүзлегендә» сергач сөйләшенең сүзе итеп каралган, кияү яисә кәләш ягыннан туйга китерелә торган камыр ризыкларын аңлата; 2) «Борынгы төрки сүзлектә» *topu* (тупларга, сакларга) сүзе теркәлгән. Шул ук сүз «Irik Bitig» («Багу китабы») кулъязмасында да китерелгән [Древнетюркский ..., с. 575]. Кайвакытта егетләрне *сыра* белән сыйлаганнар. «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге»ндә сыра шул ук формада, мәгънәдә бирелгән. Әлеге сүз иран теле аркылы борынгы һинд алынмасы, дип исәпләнә [Этимологический ..., с. 413]. «Сөрән сугу» йоласының азагында егетләрнең берсе йомырка салынган чирмәне (карнашаны, тубалны) тотып алып, авыл башына чаба торган булган. Әгәр дә егетне куып тота алмасалар, барлык җыелган йомырка шуңа булган, ләкин күп очракта аны куып тотканнар. Җыелган бөтен йомырканы сәүдәгәрләргә сатканнар, акчасына кирәкле ризыклар сатып алынган һәм бер йортта яисә кырда күмәкләшеп сыйланганнар. Мамадыш өязенең кайбер авылларында (К. Кирмән, Төркәш) йомырканы җыйганнан соң егетләр йөгерү, ат чабышлары ярышларын үткәргәннәр. Җиңүчеләргә җыелган йомыркаларны бүләк иткәннәр.

Йомырка җыю такмазалар, рәхмәт сүзләре, җырлар белән кушылып барган. Татарстан Республикасының Кукмара районының Күкшел авылында «Сөрән сугу» — Сабантуй алдыннан сөлге һәм яулык җыю йоласы. Хәзерге мәгънәдә *сөрән* — киләчәк бәйрәм турында хәбәр итү дигәнне аңлата. Бу борынгы төрки сүз *sür* тамырыннан барлыкка килгән, дип исәпләнә. «Борынгы төрки тел сүзлеге»ндә ул фигыль: 1) ияртергә; 2) куарга; 3) җитештерергә; 4) мохтаҗлыкта яшәү, тору.

Әлеге йолада 15—17 яшендәге тиз арада армия сафларына барырга тиешле егетләр (рекрутлар) катнаша. Үз эченә берничә аспектны ала: 1) рекрутларга сый-хөрмәт күрсәтү; 2) сый өчен рәхмәт әйтү. *Сый* сүзенең иске мәгънәсе тува телендә *«суй»* формасында (калым, туйга кыйммәтле бүләк) китерелгән. Татар телендә «хөрмәт итү, сыйлау» мәгънәсен белдерә; 3) «кияү чөю» йоласы. Әлеге ритуал башка чит җирләрдән кияү булып кайтучы кешене «үз итү». Кияүне чөю — аңа хөрмәт күрсәтү ритуалы; 4) яшь киленнән чиккән сөлге алу. Әлеге бүләк колганың иң югары өлешенә эленгән. *Сөлге* сүзе *sül* тамырыннан барлыкка килгән, дип фаразларга мөмкин. «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә *сафлык, чисталык* дип тәрҗемә ителгән. Башка кызлар да, яулык чигеп, рекрутларга бүләкләрен бирәләр. Шуны әйтергә кирәк, чиккән яулыкны кыз бары тик үзенә охшаган егеткә генә бүләк итә. *«Әйе шул, шулай шул, кунак кыздан кульяулык»...* Бүләк алганда шундый юллар әйтелә.

*Кульяулык* сүзенең *кул* өлеше *qol* сүзеннән барлыкка килгән. Әлеге сүзнең беренче язмалары Йосыф Баласагунның «Котадгу белег»ендә, шулай ук Әхмәд Йүгнәкинең «Һибәтел — хәкаикъ» поэмасында теркәлгән.

Кайбер Казан арты авылларында яшь киленнән ирләр күлмәге һәм намазлык, яисә ирләр күлмәге һәм күпертеп чиккән яулык мәҗбүри бүләк булып торган (Малмыж өязенең Смәил авылында, Казан өязенең Мәмдел авылында) [Уразманова, с. 37]. *Килен* — төрки сүз. Мәхмүд

Кашгарый сүзлегендә теркәлгән. Мәсәлән, *jüvüšlüg kelin kübägü javaš bulur* — бирнәле килен сабыр кияүле булыр.

Каһирәдә саклanучы XIV гасырның беренче яртысына караган язма истәлектә шундый җөмлә бар: *bezänip bu dünja özin körgitür / etinmiš kelin teg köŋül jelgütür — бизәнеп (матурланып), бу дөнья үзен күрсәтә / бизәнгән чибәркәй сыман йөрәкне дулкынландыра*. Турфан коллекциясеннән уйгыр язмалы төрле эчтәлекле фрагмента (астрология һәм көнкүреш календарьләре, медицина, сынамышлар һ.б.) *килен* сүзе теркәлгән: *kelin alsa tapindurmaz — килен алсалар, аны хезмәт итәргә мәҗбүр итәрләр.*

Кичен рекрутлар, аланда җыелып, түгәрәккә басалар. Бу хәрәкәт сакраль мәгънәгә ия, бердәмлекне, бербөтенлекне аңлата. Сөрән сугу бәйрәмендә язгы эшләр башланыр алдыннан үзенчәлекле чистарыну йоласы үткәрелгән. Моның өчен урамда яисә ындырда, зур учак ягып, өстеннән сикергәннәр. Шулай итеп катнашучылар гөнаһлардан, явыз рухлар тәэсиреннән «чистарынганнар». Язын җир — кардан, кешеләр кышкы киемнәрдән арынган кебек, бу вакыт тискәре энергиядән котылу өчен уңай дип исәпләнгән.

Сөрән сугу йоласы теркәлгән авылларда *сөрән, сөрән чабу, сөрән сугу* дип йөртелгән. *Чабу* сүзе «Борынгы төрки тел сүзлеге»ндә берничә мәгънәдә бирелгән: 1) *čap — камчылау, чыбыркылау, кыйнау*. Әлеге мәгънәдә беренче тапкыр М. Кашгарыйның «Диване лөгат эт-төрк» сүзлегендә теркәлгән: *ol atnï čïbïq birlä čapdï — ул атын чыбыркы белән камчылады;* 2) *čap — буяу, сылау, майлау; ягу; сылап чыгару*. Беренче тапкыр М. Кашгарыйның «Диване лөгат эт-төрк» сүзлегендә теркәлгән: *er evin čapdï — ир үз йортын (балчык белән) сылады*; 3) *čap — йөзәргә*. Шул ук сүзлектә: *er suvda čapdï — ир суда йөзде*; Йосыф Баласагуниның «Котадгу билиг» поэмасында теркәлгән: *qajusï čapar kör qaju suv ičär — кара: берәүләр йөзәләр, икенчеләр — су эчәләр*; 4) *čap — табу, эзләп табу; килеп чыгу*. Әлеге мәгънәдә XIII гасырда иҗат ителгән «Угыз каганы турында» риваятендә беренче тапкыр очрый: *soŋ ǯolda bir altun janï čapdïlar aldïlar — соңрак алар юлда алтын ук таптылар һәм алдылар*.

*Сугу* сүзе «Борынгы төрки тел сүзлеге»ндә берничә мәгънәдә бирелгән: 1) *soq — кыйнарга, сугарга*. «Алтын ярык» язма истәлегендә беренче тапкыр теркәлгән: *meni ïsurur baš soqarlar — мине тешлиләр һәм башыма сугалар*; 2) *soq — вакларга, төяргә, турарга*. Әлеге мәгънәдә уйгыр язуында медицина эчтәлекле фрагментта теркәлгән: *bïšïγ siŋir eki baqïr buda tüpi birlä soqup — ике пешерелгән сеңерне йөзем тамыры белән ваклап; turmanï soqup sïqïp suvïn alïp künčït jaγï birlä qatïp tamïzsar aγrïγ sonar — тырманы ваклап, суын сыгып чыгарып, кунжут мае белән кушып тамызсаң, авырту басылыр*; М. Кашгарыйның «Диване лөгат эт-төрк» сүзлегендә дә теркәлгән: *er tuz soqdï — ир тозны вaклады;* 3) *soq — чукырга*. X гасырда ханнар (патшалар) турындагы уйгыр язмасында: *quş quzγun soqar — козгыннар чукыйлар*; М. Кашгарый сүзлегендә: *quş teŋ soqdï — кош җим чүпләде*.

Әлеге мәкаләдә сөрән сугу йоласы текстлары лексикасының бер өлеше генә тикшерелде. Алдагы хез-

мәтләрдә бу юнәлешне дәвам итү планлаштырыла.

*Сөрән сугу* йоласы язгы чәчү эшләре, Сабантуй бәйрәме белән тыгыз бәйләнгән. Татарстанның Мамадыш районында һәм Пермь татарлары арасында хәзерге көндә дә авылларда бүләк җыйганда җырлана торган җырлар *Сөрән*, ә йоласы *Сөрән сугу* дип атала [Бакиров, с. 55].

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. Бөре, 2005. 232 б.

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012. 400 с.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 840 б.

*Уразманова Р.К.* Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (годовой цикл XIX — нач. XX вв.). Казань: Дом печати, 2001. 198 с.

Этимологический словарь тюркских языков. М.: Восточная литература РАН, 2003. 446 с.

***Гайнетдинова Гөлнара Рашат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: gayn_gulya@mail.ru*

УДК 811.512.145′373

***Ә.К. Булатова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭВФЕМИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

В статье рассматривается специфика употреблений эвфемизмов в татарском языке. Автор уделяет пристальное внимание целям использования эвфемизмов в речи и их функциям.

**Ключевые слова:** эвфемизм, татарский язык, коррелят, слово-заменитель, лексикология.

Сүзнең һәркайсы сөйләүчегә (тыңлаучыга) аерым йогынты ясый, үзенчә тәэсир итә. Кайбер очракта сөйләмне ятышлы, әдәпле итү, әйтелгән фикернең тәэсир көчен бераз йомшарту, киметү максатыннан телдә махсус сүзләр яисә формалар да кулланыла.

**Эвфемизм** *(гр. euphemismos — яхшы сөйлим)* — әхлак һәм сөйләм кануннарына туры килми торган сүзләрне алмаштырып килүче лексик берәмлек. Мәсәлән, татар телендәге *кандала* сүзенең мәгънәсе ‘кеше каны белән тукланучы паразит бөҗәк’, халык ышанулары буенча, аны шулай атап йөртсәң, ул үрчергә мөмкин, шунлыктан һәрвакыт диярлек *кандала* урынына *кибәк* (номинатив мәгънәдә ‘ашлык сукканда барлыкка килгән калдыклар, гадәттә бөртеклеләрнең тышчалары’) эвфемизмын кулланалар. Халык ышануы буенча, әлеге бөҗәкне бу сүз белән атаганда, ул кибә, бетә. Чагыштыр.: *Миңа, өй эче бөркү булу өстенә, таракан, кандалалар төрле яктан һөҗүм итә башлыйлар* (М. Гафури). — *Йосыф муенынннан кибәк тотты* (Г. Коләхмәтов).

Шулай ук күз кабагындагы май бизләренең эренле ялкынсынуы арпа авыруы дип атала, әмма еш кына олы кешеләр: *«Арпа, димә, көрпә ул, кибеп бетсен»*, — дип кисәтәләр, шулай имлиләр (икенче варианты — *«Арпа түгел, бодай бу, бетсен-китсен»)*.

Эвфемистик сүзләр түбәндәге максатларда файдаланыла алалар:

— җәмгыятьтә һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә, аралашуда конфликтлардан читләшү, әңгәмәдәшләр арасында уңайсызлык килеп тумасын өчен;

— нинди дә булса эшне яшерергә, нәрсәдер турында әйтеп бетермәскә кирәк булганда;

— башкалар өчен сер саналган, адресат өчен генә аңлаешлы, мөһим мәгълүмат, яңалык җиткерү максаты белән.

Югарыда күрсәтелгән максатлардан чыгып, эвфемизмнарның төп функцияләрен билгеләп үтәргә мөмкин.

1. Эвфемизмнар төрле хәвефле хәлләрнең һәм күренешләрнең төп атамаларын алыштырып бирәләр. Мәсәлән, турыдан-туры кешенең үлүе хакында аның якыннарына, дусларына, танышларына йомшартыбрак хәбәр итү.

2. Эвфемизмнар төрле күңелсез, ятышсыз әйберләрнең атамаларын алмаштыру өчен кулланылалар: *бет, кандала, серкә* һ.б. шундый сүзләрне — *бөҗәк* дип кенә атау.

3. Эвфемизмнар шулай ук аерым иҗтимагый төркем өчен кулай булмаган, килешсез булган әйберләрне башка төрле атау өчен файдаланыла-

лар: *борын сеңгерү* урынына — *борынын бушату, кулъяулык куллану* дип әйтү.

4. Этикет белән бәйле булган эвфемизмар. Бу очракта гадәттә табигый җитешсез якларны кызгану җирлегендә кулланылган сүзләр истә тотыла. Мәсәлән, *җүләр* дип әйтү урынына *бераз буталган, башы томаланган* кебек фразеологик әйтелмәләрне китерү.

5. Чынбарлык күренешләрен яхшырак итеп күрсәтергә тырышу нигезендә китерелгән эвфемистик сүзләр: *урладым* урынына *мин алдым* дип әйтү, *ялганлыйсыз* дип кискен әйтүне *сез ялгышасыз, сез хаклы* түгел кебек йомшак тәэсирле сүзләргә алыштыру.

6. Искергән яки җәмгыять тарафыннан түбән саналган һөнәр исемнәрен алыштыру: *сәркатиб — офис-менеджер; курьер — экспедитор; җыештыручы, идән юучы — клининг-менеджер* һ.б.

Сөйләүченең (тыңлаучының) теге яисә бу төшенчәне әдәпле, килешле, ятышлы кабул итүе гадәттә кеше тормышының аерым өлкәләренә яисә аерым темаларына кагылган сүзләр куллануга кайтып кала. Шундыйларның кайберләрен карап узыйк.

1. Кеше организмының аерым өлешләре, оят урыннары. Гадәти сөйләмдә әлеге өлешләрне, әгъзаларны белдерүче сүзләр оятлы, килешсез булып кабул ителә, аларны кеше үз исемнәре белән атарга тартына. Медицина өлкәсендә эшләүчеләр әлеге лексик берәмлекләрне латин телендә китерелгән профессиональ атамалар белән бирәләр. Чагыштыр: ***Күт** кашырга да вакыт юк (мәкаль). — Баязитны әчелеккә яткыралар, бөтен шәкертне җыялар да, аркасын, бөтен **йомшак җирләрен** ачтырып, мәдрәсәнең иң әшәке малаеннан унбиш чыбык суктыралар* (Г. Ибраһимов ). — *Кайчан тора икән соң ул? **Арт санын** кояш кыздыра башлагачмы?* (Г. Бәширов)

2. Физиологик халәтне белдергән сүзләр. Чагыштыр: *Чык! Нәрсә корсаклы хатын төсле тулганасың?* (И.Салахов). — *Нәфисәнең көмәнле булуы да рас килеп тора* (Г. Гыйльманов). — *Ул әни булырга әзерләнә иде* (Р. Вәлиев). — *Балага әллә кайчан узганын Айсылу үзе дә сизмәгән күрәсең* (М. Шабай).

3. Капма-каршы җенес вәкилләре арасындагы бәйләнеш (җенси тормыш). *Монысы да 1993 елда туган кыз белән 2008 елның декабреннән бирле интим мөнәсәбәттә булган* («Безнең гәҗит»). — *Алар яратышу, сөешү уены уйныйлар* (Г. Гыйльманов). — *Алар арасында берни булмады* («Безнең гәҗит»).

4. Яман авыру яисә үлемне хәбәр итүдә кулланыла торган сүзләр, тәгъбирләр. Чагыштыр: *Улың үлде. Сагнып хатлар язма, бәхетсез карт, Зәңгәр күзле улың исменә; Ул юк инде... Сагынып хатлар көтмә, «изге» карчык!* (Һ. Такташ). — *Синең яланыңда әткәй китте аклар кулыннан* (Һ. Такташ). — *Әтиебез Герман җирендә күзен йомды* («Безнең гәҗит»). — *Ике көннән Харрас карт өзелде* (Г. Галиев). — *Тузган карчык дөньялыктан арынган* (Г. Гыйльманов). —*Мин... тиздән китеп... барырмын инде, Муллакай* (Г. Галиев). — *Малай вакытында, аңа өйләнәм, дип хыялланган Галия дә, үпкәсенә салкын тидереп, язгы сулар ташыганда, мәңгелеккә китеп барды* (Г. Галиев).

Санап үтелгән эвфемизмнар кешенең шәхси тормышына кайтып кала.

Югарыда китерелгән күзәтүләрдән чыгып, шундый нәтиҗә ясар-

га мөмкин: эвфемизация татар теле өчен хас күренеш, эвфемизмнар көчле тәэсир итә торган сүзләрнең йогынтысын азмы-күпме йомшартып, аларны ятышлы, әдәпле яңгырашлы итәләр. Бу уңайдан шуны да искәртеп китү урынлы булыр: телдә бик үк ятышлы һәм килешле булмаган, ягъни «ямьсез» сүзләрне куллану безнең көннәрдә нормага әйләнеп бара, алар, барыннан да элек, үзара сөйләмдә кулланылалар, әкренләп мәгълүмат чараларына да үтеп керәләр, шуңа бәйле рәвештә телдә әлеге сүзләрнең эвфемистик коррелятларын куллану сирәгәя бара.

**Әдәбият**

*Булатова А.К.* Эвфемизмы в татарском языке // Актуальные проблемы тюркской и финно-угорской филологии: теория и опыт изучения. Елабуга. 2012. С. 5 — 57.

*Леонтьев А.А.* Формы существования значения // Психолингвистические проблемы семантики. М.: Наука, 1983. С. 154 — 182.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

*Ханбикова Ш.С.* Эвфемизм һәм какофемизмнар // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре.Казан. 1963. 2 нче кит. Б. 158—169.

*Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999. 256 б.

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Л.Ш. Бәдертдинова***

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ФӘННИ ӨЙРӘНЕЛЕШЕНӘ КАРАТА

В данной статье представлена информация о сборе и составлении сводного списка диссертаций по татарскому литературоведению, которые были защищены в период с 1943 по 2013 гг. Кроме того, дан краткий обзор изученности отдельных периодов, тем, родов и жанров татарской литературы.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, литературоведение, диссертации по татарской филологии.

Татар әдәбиятының фәнни яктан өйрәнелеше турында сүз йөрткәндә, әлеге зур булмаган тикшеренү кысаларында, 2013 елга кадәр татар әдәбиятын яктыртып язылган диссертацияләр күз алдында тотылды. Фәнни эшләрнең исемлеген туплау өчен, берничә информацион чыганакка мөрәҗәгать ителде. Шуларның беренчесе — Әбрар һәм Шамил Кәримуллиннарның «Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год» [Каримуллин]. Китап авторлары, диссертацияләрнең гомуми саны — 329, дип, тел гыйлеменә караганнары — 181, калган 149 диссертация әдәбият мәсьәләләрен яктырта, дигән фикергә килгәннәр [Каримуллин, с. 8]. Шул ук вакытта, хезмәттә китерелгән таблицада әдәбиятка караган диссертацияләр саны 148, эчтәлектә исә 151 хезмәткә тасвирлама бирелә. Күрсәткечтә китерелгән таблицаның әдәбият өлкәсенә караган өлеше түбәндәгечә: 29 докторлык һәм 119 кандидатлык диссертациясе.

1999 елга кадәр татар әдәбияты һәм китап белеме, фольклоры буенча яклланган диссертацияләрнең күрсәткечләре

| Елы | Докторлык диссертацияләре | Кандидатлык диссертацияләре |
|---|---|---|
| 1943 | — | 1 |
| 1946 | — | 2 |
| 1947 | — | 2 |
| 1949 | — | 6 |
| 1950 | — | 1 |
| 1951 | — | 1 |
| 1952 | — | 1 |
| 1953 | — | 3 |
| 1955 | — | 4 |
| 1956 | — | 1 |
| 1958 | 1 | 2 |
| 1959 | — | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 1960 | — | 2 |
| 1961 | — | 1 |
| 1962 | 1 | 2 |
| 1963 | — | 1 |
| 1964 | — | 7 |
| 1965 | — | 1 |
| 1966 | 1 | 2 |
| 1967 | 1 | 2 |
| 1968 | 1 | 6 |
| 1969 | 1 | 4 |
| 1970 | — | 3 |
| 1971 | 2 | 8 |
| 1972 | 1 | 5 |
| 1973 | — | 3 |
| 1974 | 1 | 2 |
| 1975 | — | 2 |
| 1978 | 1 | 2 |
| 1979 | — | 4 |
| 1980 | — | 2 |
| 1981 | 1 | 1 |
| 1982 | — | 3 |
| 1983 | 2 | 1 |
| 1985 | 1 | 3 |
| 1986 | — | 1 |
| 1987 | 1 | 1 |
| 1988 | — | 2 |
| 1989 | 2 | 2 |
| 1990 | 1 | 2 |
| 1991 | 1 | 2 |
| 1992 | 1 | 4 |
| 1993 | 1 | 2 |
| 1994 | — | 1 |
| 1995 | 1 | 2 |
| 1996 | 3 | 1 |
| 1998 | 3 | 9 |
| Барлыгы: | 29 | 119 |

Биредә тел гыйлеменнән 2 кандидатлык һәм 1 докторлык диссертациясе дә исәпкә алынган, әмма 1983 елда Г. Гыйльманов тарафыннан якланган кандидатлык диссертациясе саналмаган. Күрсәткечнең аерым җитешсезлекләре хакында Х. Миңнегулов та үз фикерләрен җиткерә [Миңнегулов, 230 б.].

Шул рәвешле, күрсәткечтә китерелгән саннарны төгәлләштерсәк, 1999 елга кадәр татар әдәбиятыннан

барлыгы 149 диссертация якланган, дип әйтә алабыз. Шуларның 121 е — кандидатлык һәм 28 е — докторлык диссертациясе. Әйтергә кирәк, хезмәт авторлары «әдәбият тарихы» эченә фольклор һәм татар китабы тарихы буенча якланган фәнни хезмәтләрне дә кертеп карыйлар. 1999 елга кадәр халык иҗаты буенча 8 кандидатлык, 3 докторлык диссертациясе, китап тарихы буенча 4 кандидатлык, 1 докторлык диссертациясе яклана. Әгәр аларны исәпкә алмасак, әдәбиятка караган диссертацияләрнең саны 133 булып чыга: 109 кандидатлык һәм 24 докторлык диссертациясе.

Татар әдәбиятыннан беренче кандидатлык диссертациясе 1943 елда яклана, ул — Мәрзия Фәйзуллинаның «Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның буржуаз-демократик революция елларында иҗат эшчәнлеге» хезмәте. Беренче докторлык диссертациясе 1958 елда Мөхәммәт Гайнуллин тарафыннан тәкъдим ителә. Диссертациянең темасы — «Беренче рус революциясе чорында татар әдәбияты һәм публицистикасы».

Иң күп докторлык диссертацияләре 1996, 1998 елларга туры килә (ул елларда өчәр хезмәт яклана), иң күп кандидатлык диссертацияләре фән дөньясына 1964, 1971 һәм 1998 елларда тәкъдим ителә (әлеге елларда сигезәр диссертация якланган). Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре Казан, Мәскәү, Уфа, Алма-Ата, Баку, Ташкент, Ленинград шәһәрләрендә якланган.

Ике галим тарафыннан төзелгән күрсәткеч үз вакытында әдәбият галиме Х. Миңнегулов тарафыннан югары бәяләнә: «Гомумән, бу китап — татар фән дөньясында уникаль күренеш. Аны әзерләүгә һәм чыгаруга күп көч һәм вакыт сарыф ителгән. Хезмәтнең гамәли, фәнни һәм педагогик әһәмияте зур. Бер яктан, ул татар филологиясе фәненең үсеш динамикасын, торышын, төп юнәлешләрен күзалларга ярдәм итсә, икенче яктан, бу өлкәдәге кимчелекләрне күреп төзәтергә, алга таба мөһим проблемаларны билгеләргә, фәндә дәвамчанлыкны сакларга булыша» [Миңнегулов, 231 б.].

Әбрар Кәримуллин башлаган эшне дәвам итеп, алга таба диссертацияләрне барлау өчен, түбәндәге чыганаклар файдаланылды:

1. Труды ученых Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова за 1939–2009 годы [Труды...];

2. Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге китапханәсенең электрон каталогы һәм диссертацияләр картотекасы;

3. Россия дәүләт китапханәсенең электрон каталогы;

4. Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге китапханәсендә тупланган диссертацияләр картотекасы.

1999—2013 елларда татар әдәбияты һәм китап белеме, фольклоры буенча якланган диссертацияләрнең күрсәткечләре

| Елы | Докторлык диссертацияләре | Кандидатлык диссертацияләре | Елы | Докторлык диссертацияләре | Кандидатлык диссертацияләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1999 | 4 | 4 | 2003 | — | 5 |
| 2000 | 3 | 11 | 2004 | — | 16 |
| 2001 | 4 | 10 | 2005 | 1 | 12 |
| 2002 | 4 | 16 | 2006 | 1 | 12 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2007 | 1 | 17 | 2011 | 2 | 8 |
| 2008 | — | 11 | 2012 | 1 | 10 |
| 2009 | — | 15 | 2013 | — | 7 |
| 2010 | 2 | 13 | Барлыгы: | 23 | 167 |

Күзәтелгән вакыт аралыгында тупланган диссертацияләрдән 40 ы фольклор һәм китап белеменә карый.

2014 елга кадәр татар китап белеме һәм фольклоры буенча якланган диссертацияләрнең күрсәткечләре

| Елы | Фольклор буенча якланган докторлык диссертацияләре | Фольклор буенча якланган кандидатлык диссертацияләре | Елы | Китап белеме буенча якланган докторлык диссертацияләре | Китап белеме буенча якланган кандидатлык диссертацияләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1947 | — | 1 | 1947 | — | — |
| 1959 | — | 1 | 1959 | — | — |
| 1966 | — | 1 | 1966 | — | — |
| 1968 | — | 2 | 1968 | — | 1 |
| 1969 | 1 | 1 | 1969 | — | — |
| 1973 | — | 1 | 1973 | — | — |
| 1974 | — | — | 1974 | — | 1 |
| | | | 1978 | 1 | — |
| 1985 | — | 1 | 1985 | — | — |
| 1989 | 1 | — | 1989 | — | — |
| 1994 | — | 1 | 1994 | — | 1 |
| 1995 | 1 | — | 1995 | — | — |
| 1998 | — | 1 | 1998 | — | 1 |
| 1999 | — | 1 | 1999 | — | — |
| 2000 | — | 5 | 2000 | — | — |
| 2001 | 1 | 1 | 2001 | — | — |
| 2004 | — | 1 | 2004 | — | — |
| 2005 | — | 3 | 2005 | — | — |
| 2006 | — | — | 2006 | 1 | — |
| 2007 | — | 2 | 2007 | — | — |
| 2008 | — | 1 | 2008 | — | — |
| 2010 | — | — | 2010 | 1 | — |
| 2011 | 1 | — | 2011 | — | — |
| 2012 | — | 3 | 2012 | — | — |
| 2013 | — | 1 | 2013 | — | — |
| Барлыгы: | 5 | 28 | Барлыгы: | 3 | 4 |
| | | 33 | | | 7 |

Шул рәвешле, бүгенге көнгә кадәр татар әдәбияты, фольклоры һәм китап белеменә караган диссертацион эшләрнең гомуми саны 341. Таблицаның бары әдәбиятка караган өлешендә саннар түбәндәгечә килеп чыга: 43 докторлык һәм 258 кандидатлык диссертациясе.

1943—2013 елларда татар әдәбият белеме буенча якланган диссертацияләрнең күрсәткечләре

| Елы | Докторлык диссертацияләре | Кандидатлык диссертацияләре | Елы | Докторлык диссертацияләре | Кандидатлык диссертацияләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1943 | — | 1 | 1981 | 1 | 1 |
| 1946 | — | 2 | 1982 | — | 2 |
| 1947 | — | 1 | 1983 | 2 | 2 |
| 1949 | — | 6 | 1985 | 1 | 2 |
| 1950 | — | 1 | 1986 | — | 1 |
| 1951 | — | 1 | 1987 | 1 | 1 |
| 1952 | — | 1 | 1988 | — | 2 |
| 1953 | — | 3 | 1989 | 1 | 2 |
| 1955 | — | 4 | 1990 | — | 2 |
| 1956 | — | 1 | 1991 | 1 | 2 |
| 1958 | 1 | 2 | 1992 | 1 | 4 |
| 1960 | — | 2 | 1993 | 1 | 2 |
| 1961 | — | 1 | 1995 | — | 2 |
| 1962 | 1 | 2 | 1996 | 3 | 1 |
| 1963 | — | 1 | 1998 | 3 | 8 |
| 1964 | — | 8 | 1999 | 4 | 3 |
| 1965 | — | 1 | 2000 | 3 | 6 |
| 1966 | 1 | 1 | 2001 | 3 | 9 |
| 1967 | 1 | 2 | 2002 | 4 | 16 |
| 1968 | 1 | 4 | 2003 | — | 5 |
| 1969 | — | 3 | 2004 | — | 15 |
| 1970 | — | 3 | 2005 | 1 | 9 |
| 1971 | 2 | 7 | 2006 | — | 12 |
| 1972 | 1 | 4 | 2007 | 1 | 15 |
| 1973 | — | 2 | 2008 | — | 10 |
| 1974 | 1 | 1 | 2009 | — | 15 |
| 1975 | — | 2 | 2010 | 1 | 13 |
| 1978 | — | 2 | 2011 | 1 | 8 |
| 1979 | — | 4 | 2012 | 1 | 7 |
| 1980 | — | 2 | 2013 | — | 6 |
| | | | Барлыгы: | 43 | 258 |

Шулай итеп, гомуми исәпләүләр буенча, 2014 елга кадәр татар әдәбиятыннан барлыгы 301 диссертация якланган. Шулардан 133 хезмәт 1999 елга кадәр якланган булса, 1999 елдан 2014 елга кадәр (соңгы 15 елда) 168 (19 докторлык һәм 149 кандидатлык) диссертация якланган, дип әйтә алабыз. Фәнни хезмәтләр нигездә Казанда, Мәскәүдә, Уфада, Тубылда яклана.

Хезмәтләрнең гомуми санына карап, унъеллыклап анализласак, түбәндәге нәтиҗә чыга *(рәс. 1)*.




*Рәс. 1. 1943—2013 елларда татар әдәбияты буенча якланган барлык диссертацияләрнең унар еллык, процентлы күрсәткече*

1940 нчы елларда барлык диссертацияләрнең якынча 3% языла (10 хезмәт);
1950 нче елларда ≈ 5% (14 хезмәт);
1960 нчы елларда ≈ 16% (31 хезмәт);
1970 нче елларда ≈ 10%;
1980 нче елларда ≈ 7%;
1990 нчы елларда ≈ 13%;
2000 нче елларда ≈ 41 %;
2010 нчы елларда әлегә ≈ 12 %.

Ягъни, диаграммадан күренгәнчә, татар әдәбиятыннан диссертацияләр язылуның иң уңышлы чоры булып 2000 нче еллар аерылып чыга, бу чорда 124 диссертация язылган. Шулардан 11 е докторлык һәм 113 е кандидатлык диссертациясе.

Исемлек шулай ук татар әдәбиятының төрләре, төрле тармак һәм юнәлешләре буенча өйрәнелеш тарихын күзәтеп чыгарга мөмкинлек бирә. 301 диссертация арасында иң өйрәнелгән төр булып проза тора. Әдәбиятның бу төрен яктыртып 120 ләп диссертацион эш якланган. Аннан аз гына шигърият калыша. Драматургия белән әдәби тәнкыйтьнең исә өйрәнелү дәрәҗәсе түбәнрәк *(рәс. 2)*.




*Рәс. 2. Татар әдәбиятының төрләре, төрле тармак һәм юнәлешләре буенча өйрәнелеш дәрәҗәсе*

Жанрларга килгәндә, иң күп тикшерелгән дип романны исәпләргә кирәк, бигрәк тә тарихи роман жанрының формалашу һәм үсешенә галимнәр берничә мәртәбә тукталалар. Шулай ук борынгы шигъри жанрларны тикшергән берничә диссертация бар.

Тарихи планда әдәбиятның кайсы чорына ныграк игътибар бирелүен ачыклау өчен, түбәндәге таблицага күз салыйк *(рәс. 3):*




*Рәс. 3. Татар әдәбиятын чорлап яктырту күрсәткече*

Димәк, татар галимнәре диссертация темасын билгеләгәндә, еш кына XX йөз башы әдәбиятына мөрәҗәгать итәләр. Әлеге фәнни эшләрнең саны 100 гә якын. Икенче урында үткән гасырның 60—80 нче еллары тора. Борынгы һәм Урта гасыр, хәзерге заман әдәбияты да аннан аз калыша. 1940—1950 нче еллар әдәбияты билгеле бер дәрәҗәдә күләгәдә калып бара.

Татар әдәбиятының чорларга бүленешенә таянып, «аерым вакыт аралыгында кайсы темалар калкып чыккан соң?» дигән сорауга да җавап табып була. Әгәр борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын тикшергәндә көнчыгыш әдәбияты белән бәйләнешләр, шигъри әсәрләргә мөрәҗәгать итү, аерым язучылар иҗатын тикшерү өстенлек итсә, совет чорын яктырткан диссертацияләрдә эстетик төшенчәләр белән эш итү күзәтелә, галимнәр реализм, романтизм, уңай герой мәсьәләләрен чишәргә тырышалар. XX гасыр ахырында Г. Исхакый иҗаты актуальләшеп китә, шәхес, герой, чор концепцияләре калкып чыга.

Аерым язучы һәм әдипләребезнең иҗатын турыдан-туры өйрәнүгә килсәк тә, кызыклы гына нәтиҗәләр чыгарып була. Биредә беренчелекне Г. Исхакый иҗаты алып тора, аңа 15 диссертацион хезмәт багышланган.

Г. Исхакый иҗатын тикшергән галимнәрнең диссертацияләре (авторефератлары) исемлеге

1. Абдулбариева Т.А. Традиции классицизма в драматургии Гаяза Исхаки (к проблеме мотивов государственности): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2010. 27 с.

2. Габидуллина Ф.И. Гаяз Исхаки — романист (проблематика и ее художественное воплощение): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.

3. Гайнанова Л.М. Художественное пространство и время в прозе Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2010.19 с.

4. Зайнуллина Г.И. Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

5. Кадырова А.О. Пьесы Исхаки на тему интеллигенции — аспект «новой драмы»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 27 с.

6. Каримова А.А. Идейно-эстетическая эволюция проблемы феминизма в творчестве Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 27 с.

7. Мансуров И.С. Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции: авто-

реф. дис. ... канд. филол. наук: Казань, 2005. 26 с.

8. Самитова С.Г. Идейно-эстетическая эволюция творчества Гаяза Исхаки (1914—1917 гг.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 20 с.

9. Сахапов М.Ж. Творчество Гаяза Исхаки и татарская литература XX века: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 1998. 60 с.

10. Хайруллина Д.М. Образ женщины в русской и татарской литературе 1890—1917 годов на примере творчества Г. Исхаки и М. Горького: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 20 с.

11. Харрасова Р.Ф. Ранняя проза Гаяза Исхаки в контексте литературных взаимосвязей (1895—1905): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

12. Шагбанова Х.С. Становление творчества Гаяза Исхаки (1897—1910 гг.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 18 с.

13. Шагбанова Х.С. Проблема личности в творчестве Г. Исхаки: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Москва, 2006. 39 с.

14. Якупова Г.Х. Дискуссии писателей в контексте татарской духовной жизни начала XX века: (на примере Г. Исхаки, Ф. Карими и др.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2006. 25 с.

15. Яруллина Р.А. Идейно-эстетическое своеобразие творчества Гаяза Исхаки (1897—1906): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 22 с.

Барлык диссертацияләр 1998 елдан соң якланган. Игътибар итсәк, 2 диссертация язучының эмиграциядәге чорына багышлана.

Икенче урында Г. Тукай иҗаты тора. 11 диссертация.

## Г. Тукай иҗатын тикшергән галимнәрнең диссертацияләре (авторефератлары) исемлеге

1. Абдуллина Д.М. Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.

2. Агишев Я.Х. Общественно-политические мотивы в творчестве татарского народного поэта Г. Тукая: дис. ... канд. филол. наук. М., 1946. 152 с.

3. Башкуров Р.Ш. Переводы Г. Тукая из русской литературы: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1958. 21 с.

4. Габбасова К.А. Изображение природы в поэзии Габдуллы Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 27 с.

5. Ганиева Р.К. Сатира в творчестве Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1964. 20 с.

6. Гафиятуллина Н.М. Образ Тукая в татарской поэзии XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 21 с.

7. Замалетдинов Л.Ш. Татарская народная сказка и литературные сказки Г. Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1993. 24 с. 8. Лаисов Н.Х. Лирика Тукая (вопросы метода и жанра): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1970. 19 с. 9. Нуруллин И.З. К вопросу о развитии идейно-эстетических и литературно-критических взглядов Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1953. 15 с.

10. Файзуллина М.Г. Литературная деятельность великого поэта Габдуллы Тукая в годы буржуазно-демо-

кратической революции: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1943. 131, 2 л.

11. Шайхисламов З.Р. Тема Тукая в творчестве Ахмеда Файзи (драмы и роман. Работа над вариантами): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1999. 27 с.

Г. Ибраһимов иҗаты буенча 10 диссертация язылган. Шуларның берсе докторлык диссертациясе.

Г. Ибраһимов иҗатын тикшергән галимнәрнең диссертацияләре (авторефератлары) исемлеге

1. Адгамова Г.М. Проблема освобождения женщины в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1963. 23 с.

2. Гимадеев У.И. Публицистическая деятельность Галимджана Ибрагимова в период Великой Октябрьской революции и гражданской войны (1917—1920 годы): автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 1967. 19 с.

3. Кадыров О.Х. Романтизм Галимджана Ибрагимова (творчество и эстетика): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1967. 31 с.

4. Маннурова М.Ш. Интернациональные идеи и образы в татарском историко-революционном романе (изображение русского революционера в романах Г. Ибрагимова, К. Наджми, И. Гази): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1971. 21 с.

5. Мингазова Р.А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

6. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1992. 28 с.

7. Саляхова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук: Казань, 2004. 23 с.

8. Хайруллина Г.С. Переводы произведений Галимджана Ибрагимова на русский язык: поэтика и стиль: автореф. дис. … канд. филол. наук. Москва, 2001. 15 с.

9. Хасанов М.Х. Творчество Галимджана Ибрагимова (дооктябрьский период): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1961. 20 с.

10. Хасанов М.Х. Эволюция творчества Г. Ибрагимова в послеоктябрьский период: автореф. дис. … докт. филол. наук. Москва, 1971. 38 с.

Муса Җәлил иҗатына багышланган кандидатлык диссертацияләренең саны җиде. Әйтергә кирәк, герой-шагыйрь иҗатын яктырткан соңгы диссертацион хезмәт 1980 елда языла, ул язучы иҗатындагы эстетик идеалны өйрәнүгә юнәлтелгән. Димәк, Җәлил фәне бүген күләгәдә кала бирә. 1975 елда шагыйрьнең дүрт томлык һәм 2006 елда биш томлык әсәрләр җыентыклары басылганнан соң, максатчан рәвештә аның иҗатын тикшергән диссертацион хезмәтләр юк, гәрчә әлеге җыентыкларда герой-шагыйрьнең алдагы елларда басылмаган әсәрләре урын алса да. М. Җәлилнең иҗаты һәм эшчәнлеге хәзерге вакытта яңа ысулларга таянып тикшерүне таләп итә.

М. Җәлил иҗатын тикшергән галимнәрнең диссертацияләре (авторефератлары) исемлеге

1. Бикмухаметов Р.Г. Творческий путь Мусы Джалиля: автореф. дис. … канд. филол. наук. Москва, 1955. 17 с.

2. Воздвиженский В.Г. «Моабитские тетради» М. Джалиля и их место в советской литературе военных

лет: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1968. 23 с.

3. Забиров И.Х. Муса Джалиль и моабитская группа татарских писателей: автореф. дис. … канд. филол. наук. Москва, 1971. 20 с.

4. Кашафутдинов М.С. Основные этапы развития татарской советской литературы и творчество Мусы Джалиля: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1960. 22 с.

5. Махмутов А.Г. Идейно-эстетическое своеобразие творчества Мусы Джалиля (к вопросу об эстетическом идеале): автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 1980. 23 с.

6. Мустафин Р.А. Моабитский период жизни и творчества Мусы Джалиля в свете новых материалов и изысканий последних лет: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1971. 24 с.

7. Юзеев Н.Г. Поэмы Мусы Джалиля: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1958. 21 с.

Әдәби бәйләнешләргә багышланган фәнни хезмәтләр

1. Акбиев С.Х. Дагестано-татарские литературные связи (проблемы сравнительно-исторического изучения: автореф. дис. … докт. филол. наук. Алма-Ата, 1989. 48 с.

2. Искаков Б. Казахско-татарские литературные связи (этапы развития): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1970. 39 с.

3. Мамытов С.А. Татарско-кыргызские литературные связи второй половины XIX — начала XX веков автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1992. 20 с.

4. Мухаметов И.Р. Книга Мухаммеда Челеби «Мухаммадия» в контексте татарско-турецких литературных взаимосвязей: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 22 с.

5. Нигматуллина А.М. Татарско-турецкие литературные связи конца XIX — начала XX в. (на материале жизни и творчества турецкого писателя-просветителя Ахмета Мидхата): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 23 с.

6. Саяпова А.М. Татарско-русские литературные связи первой половины 19 века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1982. 23 с.

301 диссертация арасында татар әдәбиятының чит илләрдәге, Әстерхан һәм Себер төбәгендәге үсешен тикшергән хезмәтләр дә бар. Шулар арасында Тубылда язылган һәм якланганнары игътибарга лаек. Әлеге төбәк галимнәре чын мәгънәсендә үзенә бер төркем тәшкил итәләр:

1. Аминов К.Т. Историческая основа и прототипы героев романа Якуба Занкиева «Зори Иртыша»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2012. 24 с.

2. Бабшанова Г.Н. Художественная концепция личности в прозе сибирско-татарских писателей XX века: Занкиев Я. К., Сулейманов Б. В.: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 22 с.

3. Галямова Г.С. Отражение темы Сибири в татарской прозе второй половины XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тюмень, 2006. 18 с.

4. Закирова Л.Р. Художественная деталь в прозе Ф. Амирхана: разновидности, функции, эволюция: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Набережные Челны, 2007. 24 с.

5. Кирамова Х.Х. Литературно-публицистическая деятельность Якуба Занкиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 23 с.

6. Талипова Г.М. Тобольский поэт Амдами и его книга наставле-

ний «Насихатнамэ»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2007. 22 с.

7. Ташкеева Г. Х. Мифологические и фольклорные мотивы в романах Якуба Занкиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 24 с.

8. Уразова Н.М. Х. Ярми о влиянии фольклора на формирование татарской литературы: автореферат дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2008. 23 с.

9. Фаизова Л.Х. Особенности творчества сибирско-татарского поэта Ш. Гадельши: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2006. 24 с.

10. Фаттакова А.А. Женские образы в татарской просветительской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2011. 21 с.

11. Хамитуллина З. С. Просветительские идеи и идеалы в творчестве поэта XIX века М. Акмуллы: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2007. 19 с.

12. Хуснутдинова М.С. Система женских образов в романах Якуба Занкиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2010. 22 с.

13. Якупова Г.Х. Дискуссии писателей в контексте татарской духовной жизни начала XX века (на примере Г. Исхаки, Ф. Карими и др.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2006. 25 с.

Диссертацион эшләрнең бер өлеше шәхес, герой, чор концепциясен тикшерүгә юнәлтелгән. Алар: Г.Н. Бабшанованың «Художественная концепция личности в прозе сибирско-татарских писателей XX века: Занкиев Я.К., Сулейманов Б.В.» (2009), Г.И. Каюмованың «Концепция личности в драматургии Ризвана Хамида и ее художественное воплощение» (2007), Р.Г. Салиховның «Концепция героя в татарском литературоведении» (1999), Л.М. Сәмигуллинаның «Концепция героя в период зарождения и становления татарской драматургии (1887—1910)» (2004), А.М. Саттарованың «Современная татарская драматургия: 1985—2000 гг. (концепция эпохи и героя)» (2004), Ә.Т. Сибгатуллинаның «Эволюция концепции личности в татарской поэзии XIX века» (1990), Р.Х. Хәйбрахмановның «Поэзия Назара Наджми: концепция стиля, личности и эпохи» (2002), Г.Ф. Харисованың «Проза Эдуарда Касимова (эволюция художественной концепции личности)» (2004) һ.б.

Темаларның атамалары арасында «кыскалыкта осталык» принцибы белән исемләнгән диссертацияләр дә бар. Мисал өчен: «Творчество Гумера Баширова», «Творчество Атиллы Расиха», «Творчество Мажита Гафури», «Творчество Сагита Рамеева», «Творчество Шамиля Усманова», «Творчество Утыз-Имяни», «Творчество Хасана Туфана», «Творчество Гафура Кулахметова».

Билгеле, саннар сыйфатны билгеләми. Әмма мондый күзәтүләр уйланырга, эзләнергә дә чакыра. Мәсәлән, хәзерге вакытта бездә күренекле татар әдипләре М. Мәһдиев, Ә. Баянов һәм башка күп кенә язучыларның иҗатларына багышланган диссертацион хезмәтләр юк, Урта гасыр әдәбиятына да игътибар җитми. Ә. Кәримуллин һәм Ш. Кәримуллин тарафыннан төзелгән күрсәткечкә карата язылган бәяләмәсендә галим Х. Миңнегулов татар әдәбиятын өйрәнгән чит ил галимнәренә дә игътибарны юнәлтергә өнди: «...Төркиядә Фатма Өзкан Тукай иҗаты буенча 1992 елда докторлык диссертациясе яклый. Бу төр хезмәтләрнең Мос-

тафа Өнәр, Фазыйл Агиш, Алсу Камалиева, Ибраһим Акыш һәм кайбер башка галимнәр тарафыннан да яклануы мәгълүм. Андыйлар Үзәк Азия, Көнбатыш мәмләкәтләрендә дә бар» [Миңнегулов, 230 б.]. Бүген бездән, дөнья әдәбият гыйлемендә барган үсеш тенденцияләрен дә исәпкә алып, төрки дөньяны онытмый гамәл кылу сорала.

**Әдәбият**

*Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш.А.* Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год. Казань, 2000. 160 с.

*Миңнегулов Х.Й.* Гыйлем дөньясына юлкүрсәткеч // Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. Б. 227—231.

Труды ученых Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова: 1939—2009: библиографический указатель. Казань, 2010. 208 с.

***Бәдертдинова Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*email: nisanbedri@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Г.Н. Зәйниева***

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ӘХЛАКЫЙ МОМЕНТЛАР

## («Яз башы», «Көтүчеләр» мисалында)

В статье рассматриваются вопросы воспитания, нравственности в рассказах Г. Ибрагимова «Начало весны» и «Пастухи». В особенности уделяется внимание роли воспитания ребенка в семье.

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, воспитание, семья, «Начало весны», «Пастухи».

Татар әдәбияты тарихының һәр чорында язучылар тәрбияви, әхлакый мәсьәләләрне яктырталар. «Бүгенгедә үткәннең калдыклары һәм киләчәкнең яралгылары була. Чөнки җәмгыять туктаусыз үсеш-үзгәреш процессы кичерә. Төрле формациядә яшәгән кешеләр аң һәм карашлары ягыннан, бер-берсеннән никадәр аерылмасыннар, барыбер кеше булып калалар, һәм күп кенә гомумкешелек сыйфатлары аларны берләштерә, берберсенә якынайта», дип яза И.З. Нуруллин [Нуруллин, б. 12].

Татар әдәбияты классигы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, галим Галимҗан Ибраһимов (1887—1938) — ХХ йөз башы татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган бөек шәхесләрнең берсе. Аның Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат ителгән хикәяләре аеруча кызыксыну уяталар, алар көчле романтик рухта язылганнар, хикәяләү теле аңлаешлы. Бөек язучының «Яз башы» һәм «Көтүчеләр» хикәяләрендә тәрбияви-әхлакый моментлар, хәзерге заманда актуаль булган ата-ана һәм бала арасындагы мөнәсәбәт, укубелемгә караш мәсьәләләре күтәрелә.

«Яз башы» (1910) хикәясендә мәдрәсәдән туган авылына ялга кайткан шәкертнең үз-үзен тотышы, табигатьне, авыл тормышын, дусларын чын күңелдән сагынуы, аларга соклануы тасвирлана. Монда язучының бала кичерешләрен, рухи халәтен психологик яктан оста күрсәтә белүе ачык чагыла. Әсәрне хикәяләүче төп герой — Салих исемле малай. Иң беренче чиратта ана белән бала арасындагы изге мөнәсәбәтләр сизелә. Әсәр, мәдрәсәдә тугыз ай торып, укып кайткан бала үзенең уңышларын (шәһадәтнамәсен) әнисенә күрсәтү белән башланып китә. Малайның әнисенә булган олы хөрмәте түбәндәге өзектән күренә: «Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим. Тавышы чыгышы вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган: «Рәхмәт, балам, рәхмәт, күз нурым, бәгырем... тырышкансың», дигән сүзләр әле дә колагымда тора кеби тоям. Шул сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче онытa алмаслык бер тойгы белән каршы алганлыгымны хәзер дә исемдә саклыйм». Ана белән ба-

ла арасындагы аралашу искиткеч матур бирелә: баланың әнисен яратуы, шунда ук «нәрсә әйтер икән» дип курку хисе дә чагылуы, укуын бәяләве, хөрмәтләве, әнисе сүзеннән чыкмавы. Әнисенең дә улы өчен шатлануы, аңа карата булган сөю, ярату, уңышлы укуы өчен горурлануы, тырышлыгына соклануы, уңышларын хуплавы, ихтирам хисләре ташып тора: «Артык сүз, артык рәхмәт ишетмәдем. Ләкин өмет вә мәхәббәт белән тулган ул өлкән, матур вә тирән мәгънәле күзләрдә төшәргә калтырашып торган эре бөртекле яшьләр ялтырый, алар ничаклы яшерелергә теләсә дә, ирекле-ирексез керфек очына килеп, берәм-берәм саргылт йөздән тәгәриләр иде... Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый — шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем». Димәк, әнисе белән баласы арасында сүзләр күп түгел, алар караштан ук бер-берсен аңлыйлар.

Язучы малайның эчке хисләрен табигать күренешләре белән бәйләп сурәтли. Мәсәлән, иптәш малайлары белән балыкка бару эпизодында күтәренке рухта табигатьнең искиткеч матурлыгы тасвирлана, малайның һәрнәрсәне зарыгып сагынганы сизелә, ә давыл чыккан эпизоды исә бик тә куркыныч, бала күзлегеннән явыз итеп сурәтләнә. Малайның озак күрешмәгән дуслары белән үзара мөнәсәбәте дә кызыклы. Башта алар оялыбрак аралашалар, бер-ике минут үтү белән элекке дусларча уйный башлыйлар. Салих, әнисенә карата мөнәсәбәте, яхшы укуы, иптәшләре белән аралашуы, рухи халәте, тәрбиясе ягыннан, укучы алдына уңай герой буларак килеп баса.

Галимҗан Ибраһимовның «Көтүчеләр» (1913) хикәясе шулай ук бер малай исеменнән сөйләнә. Әсәрдә ярлылыкта яшәгән көтүче Әптерәш карт һәм аның улы Вахитның тормышы сурәтләнә. Әптерәш картның көтүче булып гомере фәкыйрьлектә үтүе фаҗигале күрсәтелә. Аның яшәргә үз өе, хәтта ашарга савыты булмавы, гомеренең соңгы көннәрен хайван абзарында уздыруы, шунда җан бирүе, малаеның атасына карата мөнәсәбәте — болар барысы да тетрәндергеч күренешләр. Төп геройлар мисалыннан язучының милләт язмышы өчен борчылуы, яшәешне уңай якка үзгәртергә омтылуы сизелә. Әсәрдә шул чор җәмгыятендә хөкем сөргән сыйнфый тигезсезлек ачык күрсәтелә. Вахит образына аерым тукталып үтү урынлы булыр. Вахит — әнисез үскән бала, әтисе баласына тәрбия бирә алмый, чөнки ул көннәр буе көтүдә, аннан кайткач, арып йокыга китә, хәтта әнисе турында да сөйләми, ә баланың күңеле сөю, наз, иркәләнү тойгыларына мохтаҗ: «Күңелем сына, җаныма никтер авыр була. Шул вакыт никтер әнине сагынам. Аның итәгенә ятып, озак аглыйсым килә, дөньяның мине җәберләве турында йөрәгемдә уянган зардан күз яшем белән бушанасым килә башлый. Ләкин ул кабердә... Башка һичкем мине аның кадәрле сөя алмый... Мин берәүгә дә кирәк түгел, мин үзем дә һичкемне, һичкемне якын күрмим, һичберсен яратмыйм, ярата алмыйм...». Әтисе туган авылына кайтып яшәргә карар кылгач, анда алар «тормышның төбендә» яшәүчеләр рәтендә булалар. Авыл халкы мәрхәмәтсез, кырыс, кешелексез булып чыга, Вахитны «ярлы тәкәббер» дип кенә йөртәләр. Әтисенең авыруына карамастан, авылдашларына ачу итеп, ул авылдан китеп бара.

Вахит бала чактан ук бәхетле тормыш эзли. Аның да башка балалар кебек әти-әниле булып яшисе килә, андыйларга ул сокланып туя алмый. Әтисенең, гомере буе эшләп тә, торыр җире дә булмау, малае белән аталарча аралашмау балага бик авыр тәэсир итә. Күңеленең яратуга, назга мохтаҗлыгы ачык сизелә. Аның тормышының иң матур чагы әнә шундый кырыс шартларда үтә. Бу кичерешләр барысы да бала күңелен яралап уза.

Шәһәргә эләгеп, үзенә тынычлык, сөйгән кешесен таба кебек. Һәм шушы тормыш аңа ошый, гаиләсендә ата һәм ир буларак бәхетле яшисе килә аның. Ләкин, әтисен чит кешеләр карамагында калдырып киткәне өчен, үзенә җәмгыятьтә тискәре мөнәсәбәт ала. Әтисенең чит кешеләр кулына калып, сарайда үлүе, ярдәмгә мохтаҗ икәнлеген белеп тә хәлен белмәве, яшәргә үзенә алып китмәве аңа җан тынычлыгы бирми. Ләкин монда Вахитны гына гаепләп булмый. Бу мәсьәләдә гаиләдә дини тәрбия бирелмәү дә берникадәр роль уйнаганын ассызыклыйсы килә, чөнки әти-әнигә карата булган бурычлар, әхлакый мәсьәләләр, дини кануннар буенча, балага яшьтән үк сеңдерелергә тиеш. Язучы шулай ук Вахитның рухи халәтен табигать күренешләре белән бәйләп тасвирлый. Аның йөрәгендә мәхәббәт булганда — бөтен дөнья матур, күңелле; үлем турында уй керсә — караңгы төн, урман күренешләре килеп баса.

Г.Ибраһимов хикәяләрендә күтәрелгән мәсьәләләр мисалында, бала тәрбиясе, һичшиксез, гаиләдән бәйле, дигән нәтиҗә чыгарып була. Халык мәкалендә «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр» дип юкка гына әйтелмәгәндер. Язучы геройларның рухи халәтен, эчке дөньясын, кичерешләрен укучыга оста җиткерә белгән. Хәзерге көндә дә мондый гыйбрәтле хикәяләр тәрбияви әһәмиятләрен югалтмыйлар.

**Әдәбият**

*Нуруллин И.З.* Әдәбият теориясе: Әдәби процесс. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

***Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*email: gulnara.zaineeva@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Ф.Г. Фәйзуллина***

# Г. ТУКАЙ ТӨЗЕГӘН ХРЕСТОМАТИЯНЕҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

В статье рассматривается воспитательно-нравственное значение сборника-хрестоматии «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», составленного Г. Тукаем,

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, педагогика, татарская хрестоматия, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре».

Үз кыйбласын югалтмыйча, чорлардан-чорларга тулыланып килүче әдәбият укучыларга әхлак тәрбиясе бирүче иң төп чараларның берсе булып тора. Һәр милләт иң түбән сыйныфлардан ук, укучыларны үз халкының теле, әдәбияты, рухы белән таныштырып, матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләргә тиеш. Чөнки укучы матур әдәбият аша кешелек өчен мөһим әхлакый сыйфатлар белән таныша. Әдәби әсәрләр яхшылыкны аңларга, мәрхәмәтле, гадел, намуслы булырга өйрәтә, явызлыкны, яманлыкны җиңәргә булыша.

XX гасырның унынчы елларында мәктәп-мәдрәсәләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытылырга тиешлеге үзен сиздерә башласа да, бу таләпкә җавап бирерлек хезмәтләрнең әлегә кадәр булмавы татар теле һәм әдәбиятының фән буларак кертелә башлавында җитди тоткарлык булып тора. 1910 елның ахырында бу юнәлештә бик көтелгән хезмәт — Г.Тукайның, милли әдәбиятыбызның иң гүзәл әсәрләре тупланган, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле җыентыгы дөнья күрә.

Җыентыкны төзегәндә Тукай «әдәбиятның мәктәпкә керүе аркасында, аңар гомум милләт тарафыннан әһәмият бирелмәсме вә шул саядә [шуның аркасында] әдәбият Русия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме дигән өмид» [Тукаев, 1910. б. 2] белән эшләсә дә, аның үзалдына куйган беренче төп максаты — «...балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итү» [Тукаев, 1910, б. 2] була.

Кайбер искелек яклы, караңгы фикерле татар зыялыларының төшенкелеккә бирелеп, «Татарларда тел юк, әдәбият юк» дип, тәмам өметсезлеккә төшүчеләргә Тукай: «Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият!» — дип ышандырып әйтә [Тукаев, 1910, б. 2] һәм фикерен исбатларга теләп, мәктәп-мәдрәсәләр өчен төзелгән хрестоматиясенә, үз шигырьләре белән беррәттән, Каюм Насыйри, Дәрдемәнд, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Риза Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Садри Максуди, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири, Миргазиз Укмасый, Рәшит Ибраһимов, Шәһәр Шәрәф һ.б.ның сайланма шигырь һәм проза әсәрләреннән төрле үрнәкләр җыеп туплый. Шагыйрь үзенең китабын «үземезнең яңа үсеп килмәктә булган милли әдәбият бакчамыздан җыеп, яшь балаларымыз кулына шуның чәчәкләреннән ясалган бер чәчәк бәйләме (букет)» дип тәкъдим итә [Тукаев, 1910, б.1].

Г. Тукайның җыентыкка әсәрләр сайлауда үз таләпләре була. Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында (1911 ел, 1 гыйнвар) ул: «Әле без татарларда

теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк, фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә кирәк», — ди [Тукай, 1986, б. 99]. Хатта: «Мин анда Нәҗип Думавиның «Сугыш», Бәширинең «Балалар теләге» исемендәге шигырьләрен, үзенә һич тә әһәмият бирмичә, фәкать мәгънәви яклары яхшы булганга күрә генә алдым» дип, искәрмә ясый [Шунда ук]. Г. Тукай әлеге әсәрләрне, сәнгати яктан югары дәрәҗәдә булмасалар да, эчтәлек ягыннан җыентыкка кертүгә лаеклы дип саный.

Хезмәттә укучыларга иң беренче тәкъдим ителгән өзек — Гафил бине Габдулланың (Ризаэддин Фәхретдиннең псевдонимы) «Сәлимә»сеннән вәгазь. Тукай үзе «Милли әдәбият дәресләре»ндә «мәгълүм бер максат вә мәсләк тотылмады», — дисә дә, «Ана нәсыйхәте»нең башта ук китерелүе, әлбәттә, очраклы түгелдер. Бу өзектә укучы бала кешенең күркәм сыйфатлары, гүзәл холыклары турында Ана авызыннан ишетә. Туры юлны күрсәтүдә, хакыйкатьне ялганнан аеруда ана сүзләренең тәэсирлерәк булуы, бәлки, бу өзекне сайлауга этәргәндер дә.

Аннан соң килүче «Гомер юлына керүчеләргә» шигыре дә тәрбияви әһәмияткә ия. Тукай бу әсәре белән сабыйларга, мәктәптә укыган еллар бик күңелсез булып тоелса да, үсеп җиткәч, мәктәп елларының бик сагындыруына ишарә ясый булса кирәк.

Тукай әлеге җыентыкка «милли әдәбият бакчасы чәчәкләре»ннән үзе иң асыллары дип санаган әсәрләрне — Закир Һадиның «Мәгъсүм»еннән «Мәгъсүмнең ысулы кадим мәдрәсәсенә укырга баруы», Гаяз Исхакыйның «Теләнче кызы»ннан «Сәгадәтнең авылдагы тормышы», «Корбан гаете», «Калуш» әсәрләреннән өзекләр, Фатих Әмирханның «Татар кызы»ннан, Фатих Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе»ннән, Садри Максудиның «Мәгыйшәт» әсәреннән «Хәлит агай» кебек тәрбияви моментларны үз эченә алган өзекләрне, үрнәк итеп, җыйнап бирә.

Әдәби әсәр, нинди жанрда булмасын, кеше аңын агартучы, илһам бирүче, изгелеккә өндәүче тәрбияче ролен башкара. Укучы әдәби әсәрдән рухи азык алырга тели. Тукай да җыентыкта проза әсәрләре белән поэзия үрнәкләрен аралаштырып бирә. Иҗатында балаларга атап язылган шигырьләр күп булгангамы, әдип бигрәк тә үз әсәрләренә өстенлек биргән. Җыентыкта Г. Тукайның «Туган илемә», «Китап», «Җәйге таң хатирәсе», «Кабан күле төбе» («Кисекбаш»тан), «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты», «Хикмәтле этәч» («Алтын этәч»тән) кебек әсәрләре урын алган. Шулай ук Мәҗит Гафуриның «Яшь гомерем»еннән өзек, «Электрик фонарена хитаб», Мирсаяф Кәримбаевның «Бәхет», Миргазиз Укмасыйның «Таң», Сәгыйть Рәмиевнең «Минутлар», Зариф Бәширинең «Болыт» шигырьләре дә укучыларга тәкъдим ителә.

Хрестоматиядә Гайнетдин Әхмәровның «Казан каласының ничек салынганлыгы хакында бер хикәя», «1445 нче елны Казанның яңадан яңаруы һәм Казан падишаһлыгының башлануы» һәм «Иван Грозный тарафыннан Казан каласының мөхасирәсе [чолганышта калуы] һәм алынуы» дигән язмалары урнаштырылган. Болар китапка берникадәр тарих сулышы өрсә дә, балаларны үз халкыңның тарихы нигезендә тәрбияләү чарасы булып тора. Чөнки

әдәбиятның максаты — кешегә сүз белән тәэсир итү, тарихи дөреслекне җиткерү.

Татар әдәбияты үрнәкләре белән беррәттән, китапта көнчыгыш белгече В.В. Радловның «Төн», «Былбыл» әсәреннән «Болытлар» өзеге һәм, шулай ук, Фатих Әмирханның Һ. Андерсеннан тәрҗемә иткән «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» әкияте дә урын алган.

Каюм Насыйри туплаган татар халык җәүһәрләре — милли мәкальләр җыентыкка аерым бер ямь өсти, эчтәлек ягыннан аны тагы да баета. Мәкальләрнең эчтәлегендә тормышның барлык яклары, катлаулы тарихи-иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән алып, гади көнкүреш детальләренә кадәр, бик тулы чагылыш тапкан. Аларда кешеләрнең үзара аралашып, ярдәмләшеп яшәүләре мактала, күмәклекнең, бердәмлекнең көче күрсәтелә. Халыкның акыл-зиһен байлыгын, рухи сафлыгын, югары әхлагын гәүдәләндергән мәкальләр һәрвакытта да тәрбияви яктан тәэсирле чара булып хезмәт итәләр.

Г. Тукай балалар күңеленә хуш килерлек самими әсәрләр белән янәшә Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»дан «Җәгъфәр әфәнденең саташуы», «Сөембикәнең үлеме», Нәҗип Думавиның «Сугыш», Миргазиз Укмасыйның «Мазарстанда», Дәрдемәнднең «Кораб», Габдерәшит Ибраһимовның «Янчы, яхшы урманым!» кебек реаль чынбарлыкны гәүдәләндергән әсәрләргә дә урын бирә. Ул гүя укучыларга тормышта очраячак авырлыкларны искәртә, аларны нык ихтыярлы, көчле булырга өнди.

Басылып чыккан һәрбер әдәби әсәр яисә фәнни хезмәтнең матбугат битләрендәге төрле мәкаләләр белән чарланып баруы табигый хәл. Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дә тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калмый. Хезмәт басылып чыгу белән үк «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 4 гыйнвар санында Г. Ибраһимовның бәяләмәсе дөнья күрә.

Г. Ибраһимов әлеге хезмәт һәркем тарафыннан көтелгән булганлыкны искәртеп: «Менә шул көтелгән нәрсә, ниһаять, вөҗүдкә [дөньяга] чыкты. Бу бабта Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан иң беренче адым атланды», — дип, үзенең аны хуплавын белдерә [Габди, 1910]. Алга таба җыентыкка карата башка фикерләрен дә җиткерә. Г. Ибраһимов фикеренчә, беренчедән, җыентыкка керергә тиешле әсәрләр, «алынган парчалар милли оригинальный һәм әдәбияте нәфисәдән булмактыр», икенчедән, «әдәбияте нәфисә эченнән сайлауда да, бер нәрсә хакында үгет-нәсыйхәт түгел, әдәби кисәкнең художественный һәм балага аңлаешлы, рухына яраклы, бигрәк тә мөһиме — анда гүзәл хисләр һәм матур мәелләр кузгатырлык булуыдыр» [Габди]. Дәреслекне күздән кичереп чыккач, китапның Г. Ибраһимов куйган таләпләргә җавап бирмәве, киресенчә, биредә «әдәбияте нәфисәнең художественный парчаларын җыю түгел, бәлки вәгазь вә фәлсәфә чүпләгән икән»леге ачык күренеп тора [Габди]. Җыентыкка кер-телгән тәрҗемәи хәлләр, тарихи парчалар, төрле үгет-нәсыйхәткә корылган өзекләр, Г. Ибраһимов уйлаганча, урынсыз булып тоелса да, әлеге әсәрләрнең тәрбияви яктан әһәмиятләре бик зур. Балалар күңелендә бернәрсә дә эзсез югалмый. Аларда яшьтән үк уңай сыйфатлар тәрбияли аласың икән, яхшылык белән яманлыкны аерырга

өйрәтәсең икән, ул, озак та көттерми, үзенең нәтиҗәсен күрсәтәчәк.

Бер гасыр элек басылып чыккан китапның кыйммәте бүген дә югалмаган. Рөстәм Мәһдиев фикеренчә, «әлеге бер карашка җыйнак кына күренгән җыентыкка Габдулла Тукай матур әдәбиятның иң гүзәл әсәрләрен җыеп, яшь буынга милләтебез белән горурлану, аның әдәби җәүһәрләренә мәхәббәт тәрбияләү теләге белән сугарылган — чын мәгънәсендә егерменче йөз башы татар әдәбияты антологиясен тәкъдим итә» [Тукаев, 2000, б. 149]. Үз чорында ул укучыларга татар әдәбияты үрнәкләре белән танышу өчен зарур булса, бүгенге көндә китап халкыбызның әдәби мирасы белән кызыксынган һәркем өчен кызыклы һәм файдалы. Шул әдәби әсәрләрнең нигезендә яткан әхлакый һәм фәлсәфи фикерләр һәр чор өчен дә әһәмиятле булып кала.

**Әдәбият**

Габди. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре // Йолдыз. 1910. 4 гыйнвар.

Тукаев Габдулла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Мәгариф, 1910. 144 б.

Тукай Габдулла. Сәгыйть Сүнчәләйгә // Тукай Габдулла. Әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 99 б. V том. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902—1913).

Тукаев Габдулла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре / төз.: Рөстәм Мәһдиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 160 б.

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы***

*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# РӘДИФ ГАТАШ ИҖАТЫНДА ТУКАЙ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Статья посвящена анализу отражения образа и творчества Тукая в произведениях Радифа Гаташа. В 1960-е годы традиционное начало в татарской поэзии не отрицается полностью, а происходит обогащение классического стиха новыми формами, более четкое выражение получает тенденция взаимопроникновения разных лирических систем. В этот период также продолжается творческое изучение художественных исканий своих предшественников, например наследия Г. Тукая, что нашло выражение в творчестве Р. Гаташа.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, творчество Р. Гаташа, татарский стих, художественные искания 1960-х годов.

Рәдиф Гаташ — XX гасырның алтмышынчы елларында шигърият мәйданына узган үзенчәлекле поэтик иҗеккә ия талантларның берсе. Үз заманында әдәбиятның яңалыгы һәм традициялелеге проблемасын тәнкыйть мәйданына зур көч белән чыгарырга мәҗбүр иткән буын вәкиле. Күпләр әлеге буын иҗатын кискен тәнкыйть утына ала, әмма бик батырлары гына вакытлы матбугат битләрендә үзенең кыю сүзен язып чыгарга курыкмый. Яклаучылар, күкләргә чөючеләр дә табыла. Онытмыйк: тәнкыйтьнең ниндие дә зур батырлык сорый, ә артык мактауда күпмедер ялагайлану, яхшы атлану булмый калмый, шул ук вакытта укучыда, тыңлаучыда һәр икесе каршылыклы хисләр уята.

Алтмышынчы елгыларның шул чор әдәбиятына яңа сулыш өргәнен, әмма бу сулышның төптән, ерактан килгәнен, башка бик күпләрнең сулышын үзенекенә кушканын язып чыгучылар да, чын хакыйкатьне аңлаучылар да табыла. Әйе, һәр буын яңача сүз әйтергә омтыла, «үзгенә» булып тарих битләрендә калырга тели, әмма ахыр чиктә теләсә кайсы яңалыкның онытылган яисә яңартылган искелек икәнлеге ачыклана, «тамырсыз үзгәлекләр» исә кыска гомерле булып, тарих тузаны белән каплана.

XX гасыр ахырына алтмышынчы елгылар, төрле эзләнүләр аша үтеп, рухи баеп, дөнья әдәбиятларындагы барлык әдәби чара-ысуллар белән коралланып, яңа формалардан бөтенләй үк баш тартмаган хәлдә, традицион әдәбият кысаларына кайтып төштеләр, аны шул кысаларда да үстерүнең кирәклеген аңладылар шикелле. Әдәбият тарихына «яңалык алып килүчеләр» исеме белән керсәләр дә, көнбатышның, күршедәш русларның «заман» әдәбиятына күпмедер табынсалар да, алар барысы да Кандалыйлар, Тукайлар, Такташлар, Дәрдемәндләр иҗат иткән әдәбиятны укып үскән иде. Шул ук вакытта, чынлап караганда, телгә алынган корифейларның язганнары үз чорында татар әдәбияты өчен тагын та зуррак яңалык булмаганмыни?! Кыскасы, һәр яңада — иске, һәр искедә яңа бар.

Гомере буена форма эзләнүләреннән баш тартмаган, образлар мәйданын киңәйткәннән-киңәйтә барган Рәдиф Гаташ поэзиясеннән һәм форма яңалыгына, һәм традициялелеккә бихисап мисаллар китерергә мөм-

кин. Ул сүз тәмен, калып ямен эзләү юлыннан атлый бирә. Бүген фикер сөрешебез бер генә юнәлештә барыр. Бу — Рәдиф Гаташ иҗатында традициялелек чалымнарын барлау. Традиция дидеңме, күңелгә иң элек көнчыгышның барлык калыпларын үзләштергән, милли әдәбиятыбызның борынгыдан килгән өлгеләрен дә кулланган, Европа әдәбиятыннан, аның үзенчәлекле образлар дөньясыннан хәбәрдар Тукай килә. Әнә шуңа күрә язмабызда Рәдиф Гаташ поэзиясендә традициялелекне аның «тукайчалыгын», олуг талантка һәм язганнарына мөнәсәбәтен ачу яссылыгында алып барырбыз.

Рәдиф Гаташ иҗатын күз алдыннан уздырсаң, бер нәрсәгә игътибар итәсең: «Гөлләр су сорыйлар» исемле беренче шигъри җыентыгында ук ул Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиев һәм Такташлардан килгән традицияләрне алга куя, әмма, күпмедер вакыт узгач, үз чорының яңа формалар һәм ритмнар эзләгән башка шагыйрьләренә килеп кушыла. Иҗатының соңгы чорында исә яңадан традицион шигърияткә өстенлек бирә. Инде Рәдиф Гаташ Тукай иҗатында югары камиллектә яңгыраган робагый, газәл кебек үзенчәлекле шәркый формаларны җанландыра, шул формаларда остазларының берсе санаган Тукайга атап яисә исемен телгә алып та әсәрләр яза («Ярга эндәшү-хитап!..», «Зөлфәт, нихәл! Кайда — Тукай тамгасы?»).

Рәдиф Гаташ мәхәббәт шагыйре буларак күбрәк танылса да, мирасханәсендә башка тематикага язылган әсәрләр аз түгел. Ул сайлаган һәр юнәлештә Тукай йогынтысы теге яки бу күләмдә бар, дип уйларга кирәк. Әйтик, Рәдиф Гаташ иҗат иткән гражданлык лирикасына Тукай тәэсире күпсанлы текстлар белән раслана. Аның кайбер әсәрләрендә узган гасыр шигъриятендә Тукайда көчле яңгыраш тапкан Рәсәй ватандарлыгы идеясе ассызыклана. Рәдиф Гаташның исемсез бер шигыре болай дип башлана:

*Тарих!*
*Син биргәнсең исем-атны:*
*Без — Тукайдай тугры татарлар...*
*Озын, катлаулы юл калды артта,*
*Битараф сүз юктыр безнең хакта:*
*Без — Рәсәйдә данлы ватандар!*

Шагыйрьнең «Илле яшьлек республикам минем!» әсәрендә Ленинның Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов кебек шәхесләр янәшәсендә Тукайны да искә алып китүе сөйләнә. Рәдиф Гаташ әдәби остазын зур шәхесләрнең тануы белән генә горурланып калмый, башка халыкларның Тукайны белүе өчен дә сөенә, аларның татар шагыйрен укуы турында әсәрләрендә дә яза («Тукайны укый Оне»). Ул «Югары ул Тукай биеклеге!..»ндә милләтенә хезмәтне алга куйган Габдулла Тукайны бик югары рухи һәм әдәби биеклекләрдә тасвирлый һәм шул биеклекләргә күтәрелүнең башкалар өчен бер хыял гына булып калуын әйтә:

*Безгә — кул җитмәслек!*
*Сүз кузгата*
*Кем аңа тиң булу турында?!*
*Тукай!*
*Ахыргача бөеклеген аңлау —*
*Бу да, бәлки, хыял-уй гына?!*
*Ә омтылсак һәм аңласак икән!..*

«Үзгәрмәгән»дә шагыйрь: «Рух тәхетендә чын таҗлы Тукай булган!..» — дип белдерә. Рәдиф Гаташның лирик герое Тукайлар эшен дәвам итүне үзенең намус бурычы саный. Тукай иҗаты белән интертекстуаль яссылыкта иҗат ителгән «Уянгач...» шигырендә ул «уянгач беренче эше» турында уйла-

на һәм «Юынып, чистарынгач, хаклык хисен даулау кирәк», — дигән нәтиҗәгә килә.

Рәдиф Гаташ мирасханәсендә Тукайдан этәрелеп китеп язылган әсәрләр аз түгел. Мәсәлән, аның «Авырганда Тукай рухы белән сөйләшү» шигырендә лирик геройның фикер сөреше Тукайның шул хәл-халәттә уйлануларына күпмедер аваздаш. Идея-тема, мотив яисә лейтмотив, образлар системасы яссылыгында барган бу төр бәйләнешләр һәрвакыт ачык ярылып ятмаска да мөмкин, кайвакыт аларны Тукайга ишарәләр күрсәтеп тора («Безнең муза»), ә аерым бер очракларда аларны Тукайдан алынган гыйбарә-җөмләләр ача: «Какканны күрдем» сөюдә мин ятим, / Ихлас «сыйпап үстерде тик милләтем»...» (Какканны күрдем…»)

Алтмышынчы елгылар иҗатында пәйгамбәр, аның миссиясе турында фәлсәфә кору бер тематик-проблематик юнәлеш булып тора. Рәдиф Гаташ кайбер әсәрләрендә пәйгамбәр сыйфатында нәкъ менә Тукайны атый. Әйтик, «Бу хиссият»тә шундый юллар бар: «Исәнме Тукай-пәйгамбәр / Калдырган өмет уты?!— ...Ә ятмы Дәрдемәнд аһәңе / Безгә, йә Рәми бунты?». «Пәйгамбәр» дәрәҗәсендәге Тукайның чын бөеклеген аңлый алмаган әдәбиятчылардан шагыйрь «…(Берәүгә ишарә)»дә остазы кебек, әмма тәгаен атамыйча гына, үтергеч көлә.

Рәдиф Гаташның Тукай иҗаты белән буеннан-буена бәйләнешле җыентыгы итеп 1986 елда дөнья күргән «Китмә, хыял!» китабын атарга мөмкин. Анда кешенең гражданлык хисләрен зурлаган, ил, халык һәм дөнья тарихын көрәшчеләр тарихы итеп тасвирлаган «Тукай елы — ватандар моң» бүлеге бар. Берничә урынга Тукайга багышланган шигырьләрнең куелуы аны тематик бербөтен итүдә зур роль уйный. Тупланмага кергән беренче әсәр «Кырлай юлында Сәгъди абзый белән сөйләшү» дип атала. Тормыштан алынган сюжетка корылган әлеге шигырьдә лирик геройның прототибы автор үзе, дип уйларга кирәк. Кырлайга барган лирик геройга, артыннан атта Сәгъди абый киләдер, кебек тоела, һәм ул, гаҗизләнеп: «Мине дә уллыкка ал», «Мин дә нәни Апуш кебек гаҗиз бу юлларда», — дип кычкыра сыман. Аны Кырлай һәм күп шагыйрьләр биргән Казан арты үзенә чакырадыр төсле.

Тукай йөргән һәм яшәгән җирләрдә хыялга чумулар, туган якның Тукай исеме белән бәйле урыннарын үз итү Рәдиф Гаташ иҗатында аерым игътибарга лаек («Тукай урамында»). Алар аталган китапта да очрый («Иске Казан, «Болгар», Тукай» һ.б.). «Китмә, хыял!»ның икенче бүлеге «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» дип атала һәм хатын-кызның рухи бөеклегенә, тышкы һәм эчке гүзәллегенә дан җырлауны максат итә. Шуларның берсе тәгаен шәхес — Г. Тукай күңелен әсир итә алган Зәйтүнә Мәүлүдова, шул сәбәпле «Чистай кызы» әсәренә Г. Тукайдан «Шигъреми җәйдем аягың астына...» дигән эпиграф китерелә.

Югарыда аталган әсәрдә лирик «мин» Чистайда җитмеш ел элек булган вакыйгалар турында уйлана. Аның хәтерендә Зәйтүнәнең пристаньда Тукайны көткән вакыты җанлана. Татар әдәбен саклаган туташ күзе төшкән егет артыннан Казанга бара алмый. Фатих Әмирхан аңа Тукай хисләре турында язса да, кыз шагыйрьнең үзеннән хатлар алмый. Текстта Тукайның Зәйтүнәгә багышланган дип фараз-

ланган әсәрләргә, булган дип уйланылган хәлләргә аерым ишарәләр бар («әй кызарды шагыйрь», «кызык гашыйк»). Рәдиф Гаташ Зәйтүнәне гомере буе Тукайга олы мәхәббәт хисләре саклаган хатын-кыз сыйфатында тасвирлый.

Китапның «Авыл сәхифәләре» бүлеге «Моңдашларым, чордашларым» шигыре белән тәмамлана. Тукайга багланышлы әлеге әсәрнең соңгы текст сыйфатында китапка кертелүе аны бербөтен итүдә катнаша. «Авыл сәхифәләре»ндә шагыйрь яңа Тукайларның үсүенә өметләнә, чордашларына, «авылларда, җирдә — / ерак чорлар кичкән / моңны, җырны һаман» шулар ярдәмендә бөек йөртсәк иде, дип мөрәҗәгать итә.

Рәдиф Гаташ иҗатының соңгы этабында Габдулла Тукай исеменә тагын бер кат игътибарын арттыра, аңа төрле темаларны ачканда мөрәҗәгать итә. «Бүгенгебез»дә, Тукай белән Дәрдемәндкә дәшеп, заманның катылыгын, һәрнәрсәгә битарафлыгын әйтсә, «Гасыр башы йолдызлары»нда кайчандыр Тукай, Фатих, Сәгыйть, Гаяз кебек әдәбият, иҗтимагый тормыш арысланнарының бер тәхеткә сыюына соклана. Рәдиф Гаташның бик күп әсәрләрендә Тукайны, аның аянычлы язмышын, кичергәннәрен аңларга тырышу тоемлана («Шагыйрь үзе белгән булыр», «Сөйләшү», «Шагыйрь язмышы»). Бу чорда ул Тукай, татар халкы, Зәйтүнә Мәүлүдова, автор мөнәсәбәтләрен тыгыз бәйләнештә тагын бер кат җанландырып ала («Зәйтүнә — Тукай каберендә», «Зәйтүнә Мәүлүдова-Рәсүлевага газәл-хат»).

Узган гасырның соңгы унъеллыгында каләмен нигездә Көнчыгышның классик газәл һәм робагый жанрларында сынаган, бөтенләй яңача ачылып киткән Р. Гаташның Рудаки, Хәйям, Сәгъди, Нәсими, Нәвои һ.б., үз шагыйрьләребездән Колшәриф, Кандалый, Тукайлар иркәләп тәрбияләгән, ашландырган «Мәхәббәт бакчасы»нда үзе чәчкән матур гөлләрдән түтәлләр балкып утыра. Әлеге шигырьләрдәге мәгъшука образлары шәркый жанр формаларының портрет тудырудагы мөмкинлекләрен күрсәтеп тора. Шул ук вакытта ул — Р. Гаташ кына, үз аһәңнәрен дә кушып иҗат иткән гүзәлләр дөньясы да. Әлеге дә баягы гүзәлләр тасвирында да Г. Тукай тәэсире ачык тоемлана. Бердән, шагыйрьнең төрле калыпүлчәмнәрдә сурәтләнгән мәгъшукалары үзара шактый охшаш, чөнки аларны тудыруда уртак алымнар бар. Тукайга да нык калыплашкан стиль хас. Р.Гаташның мәхәббәт темасына язылган шигырьләре, Тукайның күпчелек әсәрләре кебек үк, тормышта реаль типлары булган адресатларга юлланган кебек.

Кайбер әңгәмәләрдә Р. Гаташ мәхәббәт темасында да гомумилеккә омтылуына ишарә ясаса да, башка очракта язганнары альбом әсәре генә булып калыр иде, дигән фикер әйтсә дә, күзәтүчән, шигырьне шигырьгә бәйли алучан укучыда прототипларга кагылышлы фикер аермачык туа. Аларның барлыгын текст лексикасы, шагыйрь биографиясе, аның аралашкан тирәлеге белән дә дәлилләргә мөмкин. Рәдиф Гаташ еш кына лирик герой гашыйк булган кызның, әти-әнисенең, туганнарының исемен язып үтә, ә аларга тормышта аналогияләр бар. Әйтик, кайбер шигырьләрнең Чулпан атлы Арча кызына яисә кайдадыр еракта яшәгән Ләйләгә аталганлыгын тоябыз. Чулпан — галимә, ул белемле, ул театрларга йөри, ул

фән белән, бигрәк тә Көнчыгыш әдәбиятлары белән шөгыльләнә, дигән нәтиҗәгә киләбез, һәм прототипны фәннәр кандидатлары арасыннан эзләргә тотынабыз.

Шигырь арты шигырь укып, без мәгъшука портретын тулыландыра барабыз. Гүзәлкәйнең кулында еш кына — Ахматова китабы, әмма ул Гаташ язган шигырьләрне дә укый, тик аларга тәнкыйди якын килә. Бу шигырьләр аның хакында булса, ул мактау сүзләре әйтә, башкаларга язылса, җитешсезлекләрен таба. Шагыйрь-герой үртәлебрәк, син минем шигырьләрне тәнкыйть утына алсаң да, үзеңә багышлаганнарны ни өчендер мактыйсың, дип әйткәли. Рәдиф Гаташ иҗат иткән сөекленең кайвакыт күңеле йомшап китүен, шагыйрьгә миһербанлык күзе белән карап алуын, аның аерым шигырьләренә уңай мөнәсәбәт белдерүен күрәбез. Гаташның мәхәббәт шигырьләрен укыганда Тукайның талантны илһамландырган гүзәлләр хакындагы әсәрләре күңелгә еш килә.

Гаташ иҗатының соңгы чорында сөелгән, сөйгән кыз төрек, һинд җырларын җырлый, шигырьләр яза, ярларны мулдан карата, әмма үзен алардан эре тота, барысы белән дә өстән генә торып сөйләшә. Араларыннан берсе чит ил егетенә гашыйк һәм шуның белән калыр кебек. Гаташның лирик «мин»е аның, читләр белән йөреп, миллилекнең асыл сыйфатларын югалтуыннан курка. Лирик «мин»нең сөеклесе кем генә булмасын — мишәр кызымы, башкорт ягыннанмы, ерак бабаларыбыз яшәгән кайсыдыр ерак төбәктәнме — ул чын милли яр: урынын белеп калфагын да кия, зыялы һәм затлы тотышлы, милли сәнгатебезне, бигрәк тә җырларыбызны бар нәрсәдән өстен куя. Тукай да, хатын-кыз образларын иҗат иткәндә, аларның миллилек сыйфатларына зур игътибар бирә.

Рәдиф Гаташ каләме тудырган героиняның башында төрледән-төрле эшләпәләр күренгәли, ул кулына затлы перчаткалар кия. Димәк, кыз милли киемне никадәр генә яратмасын, үзен көнбатыш хатын-кызлары белән дә янәшә күрергә тели, заман модасыннан калышмый. Тукай иҗатында да милли кызлар янәшәсендә заман кокеткалары юк түгел.

Гаташ каләменнән чыккан мәгъшука портретларын күз алдына китерү, үзара чагыштыру өчен бер шигырь генә җитми, тулы бер цикл яисә бер китап белән танышырга кирәк. Тукай һәм Зәйтүнә арасындагы мөнәсәбәтләрне бүгенге галимнәр дә шулай ачмыймыни?! Хәер, Р. Гаташ үзе дә, Тукай шигырьләрендәге ниндидер ишарәләргә таянып, замандашларының ниндидер истәлекләреннән чыгып кына да, олы мәхәббәт хакында зур нәтиҗәләргә килә һәм шул хакта әсәрләр иҗат итә, хыялында әллә нинди күренешләр тергезә. Бер карасаң, укучы чынбарлыкны һичкайчан ачык һәм ахырынача белә алмаячак. Әллә шагыйрьнең шигырь өчен «яратып уйнавы ул», әллә чын яшерен мәхәббәт.

Мәгъшука портретын калыплаштырганда, шагыйрь күп төрле алымнарга мөрәҗәгать итә. Шуларның берсе «битлек алымы». Моңа геройның тышкы кыяфәтендәге детальләр, кием-салымын тасвирлау, аның йорт-җиреннән, туган-тумачаларыннан мәгълүмат бирү дә керә. Галимнәр фикеренчә, соңгылары шулай ук кешенең кем булуында, холкының ниндилегендә зур роль уйный. Ту-

кайны искә төшерик. Хатын-кыз тасвирында ул кул, теш кебек органнарны да әдәби деталь сыйфатында куллана, ул кызның белемлелек дәрәҗәсенә, тәрбиялелегенә, гашыйк итә алырлык холык сыйфатларына да игътибар бирә.

Гаташ файдаланган төрле детальләрне бергә туплап, санап, төркемләп, прототипларына бәйләп чыгарга да булыр иде. Әлеге чибәркәйләрнең күбесе — лирик «мин»нән артык яшь, артык матур, артык сабыр. Димәк, арада киртә калка. Тукай тасвирлаган гүзәлләрнең дә күбесе — буй җитмәслек, шагыйрьне исертерлек, әмма якынайтмаслык түгелмени?! Лирик герой үпкәләгән вакытларда тасвирланган мәгъшука шактый тук кына кыяфәтле дә булырга мөмкин, димәк, төрттерерлек үпкәләткән… Берсенең шигырьдән шигырьгә телгә алынган мәчесе бар. Шуның белән көязләнешеп, урында ятарга ярата. Тукай иҗатында да аерым сыйфатгамәл белән истә калган хатын-кыз образлары юк түгел. Хатын-кызга тәнкыйть белән караган лирик герой образын аның иҗатыннан шулай ук табарга мөмкин.

Рәдиф Гаташ иҗат иткән бер сөекленең күлмәкләре — затлылар, кыйммәтлеләр. Кайберләре ак төстә, кайсы — яз, кайсы — күк төсендә. Ярның йөзенә игътибар аеруча зур: күзләреннән ут бөркелә, керфекләре озын, очлы, уклар кебек сөйгәненә текәлгәннәр. Шунда ук күңелгә төрекләрнең шушы образ-детальләр ярдәмендә иҗат ителгән мәхәббәт җырлары килә. Сүз уңаеннан, Г. Тукай да төрек шагыйрьләренең мәхәббәт лирикасын аеруча яраткан, аннан өйрәнгән, дип уйларга кирәк. Р.Гаташ иҗат иткән гүзәлнең кашы — кыйгач, чәче — ут-ялкын, күзләре тирәсендә, битендә миңе бар. Мәхәббәт темасына иҗат иткәндә борынгыдан килгән, Кандалый яратып кулланган, Дәрдемәндләр, Тукайлар алга таба үстергән лексик кыр чикләрендә хәрәкәт итәргә Рәдиф Гаташ каләменә дә урын җитәрлек калган булып чыга. Безнең тарафтан алда телгә алынган детальләр күпсанлы түгел, әмма алар һәрвакыт кабатлана, ассызыклана.

Каләм иясенең эмоциональ буяулары, геройга эмоциональ мөнәсәбәте укучыда портретын күзаллатуда мөһим роль уйный, характеристика бирү алымы булып тора. Шуларга бәйле рәвештә, без геройдан йә читләшәбез, йә аңа якынаябыз, ә бу якынаю-читләшүләр вакытында аның портретын үз тәҗрибәбезгә таянып тулыландырабыз. Тукай әсәрләре белән танышканда да, Р.Гаташ шигырьләрен укыганда да шулай.

Рәдиф Гаташ иҗат иткән чибәрләрдәге салкынлык, робагый һәм газәлләрдән күренгәнчә, кайчак башкаларны бу кызлардан читкә этәрә. Алар һавалылар булып тоела. Бу холык аларның йөрешләрендә, кешеләргә игътибарсызлыкларында, әйткән сүзләрендә, лирик «мин»гә мөнәсәбәтләрендә чагыла. Кеше портретындагы үзгәрмәүчәнлек сыйфатларын еш телгә алу аеруча кызларның холкын яктыртуга, аның даимилеген күрсәтүгә булыша. Тукайның лирик «мин»е үзенә игътибарсызрак кызлар алдында үзен диванадай хис итә, кыз кабызган утта янарга әзер бер күбәләк кебек ул.

Рәдиф Гаташ шигърияте белән танышкач, аны илһамландырган гүзәлләр берничә булып күз алдына килә. Лирик герой асыл бер ярдан китә, әмма нәкъ шундый икенче ярны таба. Димәк, Р. Гаташның, ул иҗат иткән лирик «мин»нең хатынкызга карата шактый ныгыган, ка-

лыплашкан зәвыгы бар. Тукай да гашыйк кына булып калмыйча, алга таба гаилә корырга, балалар үстерергә тиешле татар кызына бер үк таләпләр белән якын килә. Ул зыялылыкны, мәгърифәтлелекне, «милләт анасы» булуны һәрвакыт югары күтәрә.

Персонаж портреты, белгәнебезчә, беренче чиратта — тышкы кыяфәте: ничек йөрүе, нәрсә киюе, карашы, буе, аяк-кулы, төс-бите, кыланышлары... Шигърияттә әлеге сыйфатларны конкретлаштыру мәҗбүри дә түгел, ул шагыйрь тарафыннан гомумиләштерелгән хисләр аша чагылдырыла ала, әмма аларны тезмә текстка кертү, теге яки бу хәрәкәткә, предмет өлешенә ишарәләп алу иҗатны реалистик эчтәлекле, хисләрне ышандыргыч итә. Тукайда теге яки бу сыйфат-хәлне ассызыклау зур мәгънә йөге башкара, ул кешенең нинди социаль-психологик төркемгә каравын ачыкларга булыша.

Р. Гаташ тудырган Милли Ярның (Чулпанның, Ләйләнең) Шәрыкның көчле мәхәббәт белән янган гүзәлләре Ләйлә, Ширин яисә үз шагыйрьләребез иҗат иткән Зөләйха, Зөһрә, Сәхипҗамал, Лулу кебек хатын-кызлар һәм Тукай тудырган образлар арасында лаеклы урыны бар. Үзенә гашыйкны аңларга теләмәве белән ул шулар арасыннан аеруча Сәхипҗамалга якын шикелле. Болар өстенә әлеге ханымнарда булмаган күп кенә заман сыйфатлары хас аңа. Ә бит Г. Тукай иҗат иткән образлар да — заман кызлары.

Мәхәбббәт темасына бәйле чагыштырулар күпкәрәк китте, шагыйрьнең гражданлык лирикасы турында уйланулар икенчерәк планга күчте. Соңгы сүзләребездән чыгып, Рәдиф Гаташ мәхәббәт шагыйре булып кына күңелдә калмасын өчен, яңадан аның ил, милләт тормышына бәйле әсәрләрен искә төшерик. Аларны да укучы яхшы белә, дип уйлыйм: шагыйрь 2001 елда дөнья күргән «Газәлләр», 2005 елда басылып чыккан «Мәңгелек сусау» китаплары өчен 2008 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Бу Рәдиф Гаташ иҗатында, аерым алганда аның көрәшче рухлы гражданлык лирикасында, билгеле бер күләмдә Тукай рухын, Тукай традицияләрен тануны да чагылдыра шикелле. Ярты гасыр иҗат иткән шигъриятендә Тукайга турыдан-туры кагылышлы әсәрләрнең шактый булуы, публицистик язмаларда сүз очының еш кына Тукайга килеп төртелүе Рәдиф Гаташның татарның бөек шагыйренә чын мөнәсәбәтен ачык күрсәтеп тора булса кирәк.

***Харрасова Рифә Фәтхерахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: rita.rahman@yandex.ru*

УДК 821.512.145

*Л.Н. Йөзмөхәммәтова*

# ПОСТМОДЕРНИСТИК ТАТАР ПРОЗАСЫНДА УЕН АЛЫМЫ
## (М. Кәбиров, Р. Габделхакова иҗатлары мисалында)

В статье анализируются произведения современных татарских прозаиков М. Кабирова и Р. Габделхаковой в контексте проблемы постмодернистской игры. Автор делает попытку выявить прием игры в повести «Ул» / «Он» М. Кабирова и рассказах «Китүчеләр» / «Уходящие» и «Сират күпере» / «Мост Сират» Р. Габделхаковой на уровне содержания и формы.

**Ключевые слова:** современная литература, современная татарская проза, прием игры, постмодернистская игра, постмодернизм.

Уен категориясе гуманитар фәннәр өлкәсендә төрле яклап өйрәнелгән каршылыклы һәм кызыклы күренеш булып тора. Постмодернистик мәдәният, аерым алганда әдәбият, кысаларында исә уен алымы үзенчәлекле текст структурасын төзүгә хезмәт итә, постмодернизм поэтикасының әһәмиятле элементы булып санала.

Философия фәннәре докторы М.Р. Жбанков фикеренчә, уен — физик һәм акыл эшчәнлегенең бер төре, аның турыдан-туры практик әһәмияте юк, ләкин ул индивидка үзенең актуаль иҗтимагый рольләре кысаларыннан чыгып үсү мөмкинлеге бирә. Уен элементына карата бүгенге кызыксынуны М.Р. Жбанков XX гасыр гуманитар фикеренең үзәген тәшкил иткән чынбарлыкны кешегә генә хас танып белү юлларына нигезләнеп ачарга теләү белән аңлата. Уен — кеше ирегенең яшәү рәвеше (Сартр), аерым шәхесләр генә кичерә алган югары илһам (Ортега-и-Гассет), индивидны «аның чынбарлыгыннан өстен» булып үз орбитасына чакыра торган үзкыйммәтле эшчәнлек (Гадамер) буларак карый [Постмодернизм, с. 293].

Шунысын да әйтеп үтү мөһим: уен принцибының цивилизация өчен әһәмияты хакында Платон үзенең «Кануннар»ында ук сөйли [Платон, с. 282—283].

Дөнья фәне тарихы барышында уен коммуникация ысулы (Э. Берн), дөньяны эстетик матурлау (Ф. Шеллинг) һәм телнең яшәеше (Л. Витгенштейн) буларак аңлатыла. Ләкин әлеге күренешнең асылын ачыклау ягыннан уенны мәдәният феномены дип караган Й. Хейзинг хезмәте аерым кыйммәткә ия. Галим фикеренчә, кешенең беренче игътибарга лаек иҗтимагый эшчәнлеге үк инде уен белән сугарылган. Мәдәни тормышны алга җибәрә торган көчләр миф һәм культтан башлана: хокук һәм тәртип, аралашу һәм эшмәкәрлек, һөнәрчелек һәм сәнгать, шигърият, галимлек һәм фән. Боларның барысы да тамырлары белән шул ук уен гамәлләренә барып тоташа [Хейзинг]. Шул рәвешле, күренекле Россия галиме И.П. Ильин сүзләре белән әйткәндә, Й. Хейзинг уенны барлык глобаль кешелек мәдәниятен оештыра торган төп принцип буларак аңлый [Ильин, с. 94]. Постмодернизмда әлеге идея күп яклы үсеш кичерә. Постмодернистларча дөньяны сиземләүгә хас булган, ассызыкланган ироник, уен рәвешендәге үзбилгеләнү модусы

сәнгать практикасында гына түгел, бу темага фәлсәфә оештыру стилистикасында да чагылыш таба [Шунда ук, б. 95].

Татар әдәбияты кысаларында уен алымына Й.Г. Нигъмәтуллина «Татар әдәбиятында һәм рәсем сәнгатендә «соңарган модернизм» (2002) хезмәтендә туктала. Галим хәзерге әдәбиятта уен элементының роле нык үсү хакында белдерә. Т. Миңнуллин, З. Хәким иҗатлары мисалында «уен аша карнавальләштерү һәм примитив алымнар куллану» тикшерелә [Нигматуллина, с. 158].

Сюжет төзүдә уен алымының ролен бәяләү өчен бүгенге татар прозасы үрнәкләренә мөрәҗәгать итәргә була. Бу җәһәттән без М. Кәбировның «Ул» повестена, Р. Габделхакованың «Китүчеләр» һәм «Сират күпере» хикәяләренә игътибарыбызны юнәлттек.

«Ул» повестеның төп герое — һәрвакыт үз янәшәсендә «игезәге» барлыгын тоеп яшәүче яшь язучы. Әлеге хәл аны куркыта, чөнки үзеңнең игезәгеңне очрату күп мәдәниятләрдә начар билге булып санала. Игезәк төп геройның барлык вазифаларын үз өстенә ала башлый, шул рәвешле кинәт кенә активлашып киткән язучыны башы белән эшкә чумарга мәҗбүр итә. Вакыйгаларның мондый үстерелеше төп геройны җир тормышыннан, гаиләсеннән, мәхәббәтеннән, хәтта көндәлек көнкүреш мәшәкатьләреннән читләштерә. Әсәрнең ахырына кадәр герой өчен дә, укучы өчен дә игезәкнең шәхесе сер булып кала бирә, барысы да әлеге субъектны тану уенына җигелә, бары тик әсәрнең ахырында гына игезәкнең өрәк булуы ачыклана. Бәхет, уңыш, танылу артыннан куып, кеше үзен югалта, ул оча алу турындагы хыялыннан ваз кичә, аның урынын өрәк ала — әлеге нәтиҗә повестьның идеясе булып формалаша. Төш һәм өн, аеклык һәм исереклек чигендә төп герой автор билгеләгән гомумкешелек, рухи, метафизик катастрофаны чишәргә омтыла. Бүгенге җәмгыятьтә шәхесләр түгел, ә копияләр, игезәкләр, симулякрлар яши, шәхеснең, индивидның кыйммәте югалган. *«Өйгә кайткач, теге гәҗитне яңадан карадым. Иркенләп. Аның беренче битендәге сурәттә Президентның артыннан мыеклы һәм күзлекле бер кеше карап тора иде. Мин, әлбәттә, ул кешенең кем икәнен белә идем. Заманында, әле өйләнешкәнгә кадәр үк, аның фотосын гәҗиттә күргәч, хатын да, мин дип уйлап, үбеп алган иде. Мин дип уйлап... Димәк, мине ул дип уйлаганнар... Мин, күрәсең, төскә-биткә бик үзенчәлекле кеше түгелмендер. Чөнки үземә охшаган кешеләрнең мин белгәне генә дә бик хәтсез иде. Беренче сыйныфтан бирле бергә укыган дус егетем белән хәтта әтиәниләр дә буташтыра иде, ә башкалар хакында сүз дә юк, без хәтта кызлар озатырга да алмашып йөри идек. Аннан соң бер юмористны беләм. Шундый ук кара күзлек, кара мыек. Буйга гына миннән аз гына кыскарак. Тагын бер баянчы бар. Бермәлне концерт карарга баргач, мине, шул баянчы дип уйлап, кунакка да алып киткәннәр иде хәтта»* [Кәбиров, б. 349].

Тексттагы әһәмиятле моментлардан (болар турында алда күпмедер дәрәҗәдә инде әйтелде) кеше мөмкинлекләренең чиксезлеге (төп герой әсәрдә очу сәләтенә ия була) һәм кешенең дөньяны кабул итү үзенчәлекләре кебек темаларны атарга була. Текстта билгеләнгәнчә *«кешенең халәтен тормыш түгел, ә аның тормышка карашы хәл итә.*

*Һәм кешенең мөмкинлеге аның тормышка булган мөнәсәбәтеннән тора»* [Шунда ук, б. 368].

Әсәр үзәгендә — хәзерге дөнья әдәбиятында мөһим урын алып торган кешенең үзен югалтуы темасы. Европа постмодернист язучылары һәм укучысы өчен ул — зур кызыксыну объекты, 1998 елда әдәбият өлкәсендә Нобель премиясенә лаек булган португал язучысы Жозе Сарамагоның «Игезәк» (2008) романы да киң иҗтимагый резонанс тудырган иде. Анда, һәр кешенең аң төпкелендә башка «мин» яши, ул хәлиткеч ситуацияләрдә тышка чыга, яшәү дәверендә эшләгән хаталы гамәлләребезне күрсәтә, туры юлга өндәргә тырыша, дип ассызыклана. Икенче яктан, кеше һәрвакыт ярыш юлында, үзенең «мин»е белән көрәштә, куркуда, чөнки теләсә кайсы моментта копия оргиналны алмаштыра ала.

Шәхесне югалту проблемасы белән беррәттән, М. Кәбиров повестенда бүгенге җәмгыятенең рухи саегуына игътибар ителә. Яшь буын өчен рухи матурлык дөньясы — *«искелек калдыгы», «болар әтиләренең дә, әниләренең дә кем икәнен белми үскән милләтсез һәм тамырсыз бер токым иделәр...»* [Шунда ук, б. 354]. Хәер, санап үтелгән замана чирләре постмодерн эпохасының аерылгысыз билгеләре булып формалаша, язучы исә моны нечкә тоемлап ала.

Текстта Гете, Анна Иоанновна, Екатерина II, күренекле рус шагыйре кенәз П.А. Вяземский телгә алына. Замана проблемалары кысаларында әлеге тарихи исемнәр белән уйнау сюжетка аерым бер саллылык өсти.

Уен алымы Р. Габделхакова әсәрләренең сюжет нигезендә ята. Зур булмаган «Сират күпере» дип исемләнгән хикәядә үзенчәлекле рәвештә Коръәннән алынган сюжет бирелә. Билгеле булганча, Сират-әлмөстәкыйм (صراطالمستقيم гарәп. *дөрес юл*) — җәһәннәм белән җәннәт арасында сузылган нечкә күпер, аның аша Кыямәт көнендә барлык кешеләр үтәчәк: Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп яшәүчеләр дә, үтәми торганнары да. Әлеге күперне кичеп җәннәткә кадәр бары тик Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәгәннәр, изге гамәлләре гөнаһларыннан өстен булган кешеләр генә барып җитәчәк. Калганнар исә, гөнаһлары авырлыгын күтәреп, Сират күперен кичеп чыга алмаячаклар һәм җәһәннәм утына төшеп китәчәкләр. Тик кайберәүләргә генә, чистарыну җәзасыннан соң, аннан чыгу мөмкин булачак. Сират күпере — Коръәндә күп мәртәбә күкләргә, җәннәткә илтә торган «кылдан нечкә, кылычтан үткен» туры юл мәгънәсендә искә алынган төшенчә [Исламская энциклопедия].

Әсәрдәге вакыйгалар Россия гаскәрләре басып кергән Әфганстанда бара. Мөҗәһидләр дошманнарын — кол солдатларны — үзләренең Сират күпере аша чыгарырга карар кылалар, бары тик иман кәлимәсен әйтә алганнарга гына исән калу мөмкинлеге бирәләр. Упкын алдында үлем көтүче җиде Россия егете арасында Рамил дә була. Бу (исемнең мәгънәсе: могъҗизалы, экияти. Гарәп телендә рамл «комда күрәзә итү»не аңлата. Көнчыгышта таралган комдагы нокталар һәм юллар аша күрәзәлек итү юлы (Алим Гафуров) [Словарь личных имен]. Рамил — хикәянең төп герое. Аның күз алдында ике дустын — рус һәм украин солдатын — мөҗәһидләр үлемгә җибәрә: 7—8 метрлы күперне үтеп чыгу омтылышы солдатлар өчен уңышсыз тәмамлана. Бу момент-

та, нәкъ әкияттәгечә, Рамилнең күз алдына әбисе килеп баса, ә бит заманында аның дини өйрәтүләренә егет колак салмый. *«Аяклар мамыкка әйләнгән, йөрәк гүя тибүдән туктаган. Упкын кырына килеп баскач, егет, аның тирәнлегеннән коты очып, калтыранып куйды. Ул инде яртылаш үлек иде. Курку тулы өметсез карашын каршы ярга төбәп беренче адымын атлады, әмма шундук кире чигенергә мәҗбүр булды. Чөнки, тар басмага йомшак кына басып, аның каршысына ак күлмәкле, ак яулыклы бер карчык килә иде! Гүя атламый, ә йөзә. Рамилнең бөтен тәне чымырдап китте, ул тораташ катып калды: аның каршына, нурлы йөзләрен балкытып, әбисе килә иде! Егет аның эчкә баткан кечкенә төймә күзләрен, тешләре булмаганлыктан кечерәеп, җыерылып, уймак очы кадәр генә калган иренсез авызын, уң яңагында калкып торган борчак хәтле миңен — барысынбарысын ап-ачык күрде. «Әби, сак бул, егыла күрмә», — дип әйтергә теләде Рамил. Тик тавышы чыкмады...»* [Габделхакова, б. 330]. Нәкъ менә әбисе аңарга иман кәлимәсен ирештерә: *«Лә иләһе-иллаллаһү, Мөхәммәдүр рәсүүлиллаһү, дип әйт, улым!»* [Шунда ук, б. 330]. Рамил өмет белән әлеге җөмләне кабатлый, аның артыннан ук дуслары да. Шул рәвешле егетләр исән кала. Өйгә кайткач, төп герой әбисенең үлеме хакында белә, ә кабер ташында исә Рамил иман кәлимәсе әйтеп исән калган көн уелган була. Шул рәвешле, язучы мөҗәһидләр уенына илаһи уенны, чынбарлык чикләрендә аңлатып булмаган хәлне каршы куя. Бу ике катлы уен укучыны үзенчәлекле фәлсәфәгә, тормышта кешеләр гамәленнән зуррак гамәлләр барлык турындагы фикергә китерә.

Р. Габделхакованың «Китүчеләр» дип исемләнгән фәлсәфи хикәясе дә уен алымына нигезләнә. Хикәянең төп герое Касыйм (исемнең мәгънәсе: бүлүче, өләшүче, бүлешүче) [Словарь личных имен] көнчелек нигезендә туган талашуда хатыны Ранияне үтерә (исемнең мәгънәсе: матур кыз, чәчәк) [Шунда ук], соңыннан, җәзадан качып, үзенә аклану эзләп, ил буенча сукбайлыкта йөри. Шул вакыт ул үзе шикелле үк сукбай шагыйрь белән таныша, әлеге персонаж әсәрнең төп фәлсәфи идеясен яңгырата: *«Син ялгышкансың, — диде шагыйрь. — Әгәр хөкем булса, гаепләүчеләр, хөкем итүчеләр дә башкалар булыр иде. Ә хәзер гаепләүче дә, гаепләнүче дә, хөкем итүче һәм җәза бирүче дә син үзең. Үз өстеңә бик зур эш, бурыч йөкләгәнсең син. Бу бит коточкыч авыр! Җинаятең, гөнаһларың өчен тиешле җәзаны вакытында алу вөҗдан газабын киметә. Син шуны аңламыйсың»* [Габделхакова, б. 420].

Дустының йогынтысы астында улын табу нияте белән Касыйм туган шәһәре — Дәһшәтле калага юнәлә. Ләкин анда бер кешегә дә аңлашылмый торган куркыныч сугыш бара. Шәһәр төп геройны җимерек, бушаган халәттә каршылый, Касыйм белән бары тик җил генә (текстта традицион туган җир җиле образы бар) сөйләшә. Текст кешеләрнең җиргә үтерергә түгел, ә яшәргә килүе хакында сөйли. Төп герой өенә кайтып, хатыны белән улының фотографиясенә тап була, фотоның датасы геройга газизләренең исәнлеге хакында белдерә һәм аларны һичшиксез эзләп табарга кирәк дигән уйга этәрә.

Әсәрдә белдерелгәнчә, тормышның асылы нидә булуын әйтү, объектив реальлек белән субъектив бәя

арасындагы чикне билгеләү шактый кыен. Тормыш төрле формаларда кешенең аңында, хисләрендә (еш кына куркуда, ачулануда, шикләнүләрдә), күзаллауларында, фаразларында үтеп китә. Кайдадыр сугыш бара икән, башка җирдә бәхетле тыныч яшәеш дәвам итә. Һәркем үз бәхетен үзе төзи, үзе үк аны җимерә, ә иң авыр җәза — үз-үзеңне хөкем итү. Бары тик саф, ихлас балалар дөньясы гына реаль, үзгәрешсез. Нәкъ менә шуңа күрә аны җимерү мөмкин түгел. *«Мин әкрен генә тирбәлеп торган таган янына килдем. Могҗиза, кайчандыр минем улым уйнаган балалар мәйданчыгына берни дә булмаган. Ул хәрабәләр арасында әкият иледәй, тормыш утравы булып аерылып тора...»* [Шунда ук, б. 423].

Алда санап үтелгәннәрдән тыш, текстта туган җирнең изгелеге, кеше гомеренең кыйммәте, аны тартып алырга Алладан башка берәүнең дә хакы булмау турындагы уйлануларга әһәмият бирелә. Әсәрдә гаилә һәм мәхәббәт чын бәхеткә, коткарылуга юл булып, кешелекнең иң бөек хәзинәсе кебек аңлашыла. Хәтта иреккә гашыйк шагыйрь бары тик чын мәхәббәтен тапкач кына бәхеткә ирешә.

Китүчеләр — үз йортларын ташлап китәргә, Дәһшәтле шәһәр белән хушлашырга мәҗбүр булган кешеләр: төп герой, аның хатыны, улы, сугышта үлгәннәр, бер-берсен үтерергә хөкем ителгән туганнар, күршеләр, ватандашлар. Иллюзор вакыйгалар нигезендә тулы бер фәлсәфи концепция, шартлылыктан олы хакыйкатьне төзегән укучының күзаллавы белән уен безнең тарафтан анализланган алымның кызыклы, хәзерге әдәбиятның һәм тулаем мәдәниятнең иң әһәмиятле күренешләреннән берсе булуы хакындагы фикерне тәгаенли.

Шул рәвешле, хәзерге татар әдәбиятында уен эчтәлек дәрәҗәсендә — фантастик, әкияти сюжет, форма дәрәҗәсендә (еш кына эчтәлектә дә) — төрле өслүбләрне кушу, интертекстуальлек, мифлардан килгән кодны җимерү, төрле тарихи фактларга мөрәҗәгать итү, алар хакында янәдән башка күзлектән уйлану төсен ала. Уен ярдәмендә татар язучылары дөньяның талантлы фикер ияләрен борчыган проблемаларга мөрәҗәгать итәләр: шәхеснең яңа заманда тоткан урыны, җәмгыятьнең рухы саегу, никах һәм гаилә институтларының кризисы; моның белән беррәттән әсәрләр чынбарлыкның чиктән тыш гомумиләштерелгән сурәтен төзи. Татар текстларында сюжетлар еш кына дөньяга карашның милли формасына, татар мифларына, динимөселман сюжетлары структурасына нигезләнә, татарлар һәм кешелек җәмгыятендә гомум кабул ителгән кануннар, кыйммәтләр кабат бәяләнә. Әлеге алым авторга куелган максатны оригиналь рәвештә тормышка ашырырга ярдәм итә, зәвыклы укучының әдәбиятка таләпләрен канәгатьләндерә.

## Әдәбият

*Габделхакова Р.Г.* Тау артында кояш бар: роман, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 479 б.

*Ильин И.П.* Постмодернизм. Словарь терминов. М.: ИНИОН РАН (отдел литературоведения); INTRADA. 2001. 384 с.

Исламская энциклопедия [Электронный ресурс]. URL: http://islamist.ru/%D1%81%D0%B8%D1%80%D0%B0%D1%82/ (дата обращения: 9.05.2014).

*Кәбиров М.* Мәхәббәт яңгыры: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 431 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.

Платон. Собрание сочинений в 3 т. М.: Мысль, 1971. Т. 3, Ч. 1. 687 с.

Постмодернизм: энциклопедия. Мн.: Интерпрессервис; Книжный Дом, 2001. 1040 с.

Словарь личных имен [Электронный ресурс]. URL: http://dic.academic.ru/dic.nsf/personal_names/ (дата обращения: 9.05.2014).

*Хейзинги Й.* HomoLudens [Электронный ресурс]. URL: http://royallib.ru/read/heyzinga_yohan/Homo_Ludens.html#81920 (дата обращения: 3.05.2014).

***Йөзмөхәммәтова Ландыш Нургаян кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты аспиранты*
*e-mail: land_yz@mail.ru*

УДК 94

***Ф.Ш. Хуҗин***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАРСТАН ҖИРЛӘРЕҺУННАР ҺӘМ ТӨРКИ КАГАНЛЫКЛАРЫ ЧОРЫНДА: историографик күзәтү

Автор статьи предлагает историографический обзор изученности этнической ситуации Среднего Поволжья и Приуралья в эпоху гуннов и Тюркских каганатов. Отмечаются несомненные успехи в решении обозначенной проблемы и анализируются дискуссионные моменты в изучении и этнической интерпретации археологических материалов, связанных, в первую очередь, именьковской культурой.

**Ключевые слова:** гунны, тюркизация края, восточные славяне и именьковская культура, поздние сарматы.

Урта Идел төбәгенә төрки кабиләләр кайчан үтеп керә башлаган? дигән сорауга җавап әлегә кадәр табылмаган. Табигый ки, әлеге проблеманы чишү өстендә галимнәр күптәннән эшлиләр. Бүгенге көндә тарих фәнендә иң нык таралган җавапларны (концепцияләрне) өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин: 1) болгарларга кадәр безнең төбәкләрдә хәзерге мари, удмурт, мордва халыкларының борынгы бабалары — фин-угыр кабиләләре яшәгән, болгарлар исә Урта Идел буйларына көньяктан, Хәзәр дәүләте территориясеннән, VIII гасыр урталарында гына күчеп килгәннәр [Смирнов, 1951; 1962, с. 160—174; Каховский, 1965, с. 222 и сл.; Федоров-Давыдов, с. 72—83; Кузеев, 1992, с. 43—52; һ.б.]; 2) Урта Иделнең төркиләшүе болгарлардан күпкә элегрәк, III—IV гасырларда һуннар чорында ук башланып, VI—VII гасырларда, ягъни Төрки каганлыклары чорында дәвам иткән, димәк, болгар бабаларыбыз чит-ят кавем җирләренә түгел, бәлки тугандаш кабиләләр арасына килеп төпләнгәннәр [Бартольд, 1968, с. 37—38;. Худяков, 1927, с. 135—146; Халиков, 1971, с. 7—36; һ.б.]; 3) төркиләрне Урта Идел буйларына каяндыр күчеп килгән килмешәкләр дип санау дөреслеккә туры килми, чөнки алар шушы җирләрдә әле безнең эрага кадәр I меңьеллык башында ук формалашып, һуннарга кадәр үк тыныч кына яшәп ятканнар [Фирсов, 1919; Калинин, 1948; Малов, 1948; Зәкиев, 2008; 2012].

Соңгы концепция авторларының карашлары, күп кенә галимнәр тарафыннан кискен тәнкыйть утына дучар булса да, һичшиксез, игътибарга лаек, чөнки ул тел, тарих, археология һәм антропология материаллары белән раслана. Мәсәлән, Казан археология мәктәбенә нигез салган күренекле галим Н.Ф. Калинин 1940 нчы елларда ук инде, Идел — Кама төбәгендә элгәреге тимер гасырында формалашкан ананьино культурасы кабиләләрен бөек грек тарихчысы Геродот тарафыннан телгә алынган һәм этник яктан Кара диңгез буйларында б.э.к. VII—III гасырларда яшәгән скифлар-

га охшаш фиссагет/тюрагет, иирк/тюрк (төрк) кабиләләре белән тәңгәлләштерергә мөмкин, дип санаган иде [Калинин, 1948, с. 93—94; Малов, 1948, с. 116—119]. Соңгы елларда элеге караш академик М.З. Зәкиев тарафыннан тагын да баетылып, өстәмә фактлар белән ныгытылып, аның күп кенә хезмәтләрендә чагылыш тапты [Зәкиев, 1998, б. 163—177; 2008, б. 203—219; 2012, б. 209—224 һ.б.]. А.Х. Халиков исә үзенең бер хезмәтендә иң борынгы төркиләрнең Урта Идел төбәкләренә тагын да элегрәк, б.э.к. II меңьеллык урталарында ук үтеп керү ихтималы булганлыгын искәртеп үткән иде («среди носителей турбино-сейминского металла и валиковой керамики, проникших через Урал по Каме и Волге в Восточную Европу, могли быть и представители племен алтайской языковой общности — прототюрки или тюрко-монгольские племена» [Халиков, 2011, с. 29]).

Кыскача гына әлеге фактларның кайберләренә тукталып үтик.

Ананьино культурасын өйрәнүче археологларның фикеренчә, әлеге кабиләләр яисә аларның зур гына бер төркеме Кама буйларына б.э.к. VII—VI гасырларда көнчыгыштан килеп урнашканнар. Аларның Көньяк Себер, аерым алганда, Алтай якларында формалашкан булуы мөмкин: Каманың түбән агымы тирәләрендә яшәгән ананьино археологик культурасы вәкилләренең баш сөяге төзелешендә монголоид элементлары ярылып ята [Акимова, 1968, с. 19—20]; бай каберлекләр өстенә, шул чорның Көньяк Себер кабиләләренә хас булганча, сугыш кораллары уеп ясалган таш стелалар урнаштырылган [Чижевский, 2008, с. 57—59, 81—82].

Әле б.э. к. V гасырда ук Геродотның игътибарын җәлеп иткән аргиппей кабиләләре — алар Көньяк Урал тирәләрендә һәм аннан төньяктарак урнашкан җирләрдә яшәгән булырга тиеш — «скифлар кебек үк киенеп йөрсәләр дә», телләре белән алардан аерылып торганнар, җиде тылмач ярдәме белән җиде тел аша гына аралаша алганнар. Аргиппейларның Геродот «Тарих»ында теркәлеп калган асхи/асчи (әче/ачы) сүзен галимнәр, бер дә шикләнмичә, төрки телләрдән чыгып аңлаталар [Геродот, 2004, с. 220, 530; Зәкиев, 2008, б. 209].

Борынгы тарихчы сүзләренә караганда, аргиппейлар башка кабиләләрдән үзләренең тышкы кыяфәтләре белән дә аерылып торганнар: алар «тумыштан пеләшләр» («лысые от рождения»), «яссы борынлылар» һәм «киң ияклеләр». Ихтимал, биредә сүз барлык төрки халыкларның иратлары өчен хас булган гадәт — чәчләрен үстермичә, һәрдаим кырып йөрү гадәте турында барадыр. Игътибар итегез: «Болгар ханнары исемлеге» («Именник болгарских ханов») дип аталган борынгы документта Дунай болгарлары хакимнәре «чәчләре кыркылган кенәзләр» («князья/правители с остриженными головами») исеме белән телгә алынган. «Чәчләрен кыркып, толымнар йөртә торган хәзәрләр» («бреющие головы и носящие косы хазары») 627 елда Дербент ныгытмаларын штурмлаучы түрк (Төрки каганаты) гаскәрләре составында сугышалар [История…, 2006, с. 48]. Шунысы кызык, Идел белән Иртыш елгалары арасында, ягъни төрки халыклар яши торган ареалда, бүген дә тамырында «тазлар» топонимын йөртә торган торак пунктлары бар [Гарипова, 1995, с. 35].

Кайбер галимнәрнең фаразлавынча, аргиппейлар иң борынгы төрки кабиләләрнең (огурпраболгар-

ларның) көнбатыш төркемен тәшкил иткәннәр булса кирәк [Халиков, 2011, с. 141—142]. Әмма бу кыю фикерне расларга әлегә ышанычлы фактлар җитеп бетми. Тик шунысы шик уятмый: скифлар дәверендә Хинган тауларыннан һәм Байкал аръягыннан башланып, Дунай-Карпат буйларына кадәр сузылган иксез-чиксез Евразия далаларында тереклек иткән халыкларның көнчыгыш төркемнәре, һичшиксез, борынгы төркиләрнең мөстәкыйль этнос булып оешуында хәлиткеч роль уйнаганнар. Борынгы скифлар культурасының нигезе, хәзерге заман галимнәренең раславынча, Үзәк Азия җирлегендә формалаша башлаган, биредә, Алтай үзәнлекләрендә һәм күрше-тирә өлкәләрдә аларның дөньякүләм атаклы археологик истәлекләре — б.э.к. VIII—V гасырларга караган Аржан, Пазырык, Туэкты, Башадар, Укок курганнары казып тикшерелгән. Кара диңгез буйларына скифлар инде калыплашкан, әзер культура белән соңрак үтеп керәләр [Грязнов, 1980, с. 50—59]. Менә шул курганнарны калдырган кабиләләр борынгы Кытай язма чыганакларында беренче тапкыр үз исемнәре белән б.э.к. IV—III гасырларда телгә алына башлаган һуннарның этносын, матди культурасын һәм рухи мәдәниятен формалаштыруда катнашалар. Һуннар дәүләте б.э.к. III гасыр ахырында оеша.

Төрки халыкларның иң борынгы бабаларыннан саналган һуннар тарихы начар өйрәнелгән, дип булмый. Россия һәм чит ил историографиясендә әлеге проблеманың төрле аспектларына багышланган хезмәтләр санап бетергесез [иң соңгы мәгълүматлар һәм әдәбият: Боталов, 2009]. Тик шунысы бар: тикшеренүләр методик һәм методологик яктан камилләшкән, киңрәк колач ала барган саен хәл итәсе бәхәсле мәсьәләләр саны арта гына бара.

Мисал өчен һуннарның этносы (теле) проблемасын алып карыйк. Элегрәк тә бериш галимнәр аларны монгол телле, икенчеләре исә төрки телле халыклар төркеменә кертеп йөрттәләр иде [Дёрфер, 1986]. Шулай да күпчелек галимнәр һуннарны төрки телләр дип санау ягында булды. Без дә шул фикердә, чөнки һуннарның төркләр этногенезындагы роле (ана бүре коткарып калган һун малае турындагы этногенетик легенданы гына исегезгә төшерегез), Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа төбәкләре белән бәйләнгән тарихлар, шул тарихка нисбәтле ономастика материаллары, матди һәм рухи мәдәният өлкәсендәге үзенчәлекләр, ниһаять, төрки телләрдән чыгып аңлатыла торган сүзләр, хәтта аерым фразалар — боларның барысы да аларның төрки телле булуларына шик калдырмыйлар. Дөрес, һуннарның күп кенә археологик истәлекләре (мәсәлән, дөньякүләм атаклы Ноин-Ула каберлеге, соңгы елларда тикшерелгән башка объектлар) хәзерге Монголия территориясендә урнашкан. Ләкин бу факт кына аларны борынгы монголлар белән тәңгәлләштерергә нигез була алмый [Коновалов, 1985, с. 41—50; Тумэн, 1985, с. 87—96; Боталов, 2009, с. 42—114]. Сүз дә юк, монгол этногенезында һуннарның ролен инкарь итү дә дөреслеккә туры килмәс иде, чөнки ахыр чиктә ике халыкның да борынгы бабалары уртак ич, соңыннанрак та, ягъни мөстәкыйль этнослар формалашкач, алар бер үк табигать шартларында, мәдәни, социаль-икътисади үсеше ягыннан карaганда якынча бер үк дәрәҗәдә торган җәмгыятьтә яшәгәннәр.

Шуңа басым ясап үтәсе килә: төрки халыклар историографиясендә

һуннарны хәзерге төрки халыкларның гомум бабалары дип кабул итү традициягә кергән [Gülensoy, 2011, s. 75—100]. Урта гасырлар чорына, бигрәк тә Идел Болгары һәм Алтын Урда дәүләтләре яшәгән дәвергә караган төрки-татар цивилизациясенең чишмә башы, тарихи нигезләре дә һуннарның югары үскән дәүләти мәдәниятенә барып тоташа [Хузин, 2007, с. 26—37; 2013, с. 7—32]. Һуннар тарихына җитди игътибар итүнең тагын бер сәбәбе шунда ки, Көнчыгыш Европаның, аерым алганда Урта Идел төбәкләренең, төркиләшә башлавы, ниһаять, болгар бабаларыбызның Каспий, Азов, Кара диңгез буе далаларына күчеп утырулары да һуннар белән бәйләнгән. Кытайлар тарафыннан җиңелгәннән соң төньяк һуннар, юлларында очраган кабиләләрне буйсындырып һәм сугышка яраклы ир-атны үзләренә ияртеп, II—III гасырларда ук инде Арал — Каспий тирәләренә килеп чыгалар, IV гасырда исә алар Көнбатыш Европа җирләренә яу чаба башлыйлар.

Һуннар миграциясе Көнчыгыш Европаның этник картасына җитди үзгәрешләр кертә. Идел — Урал төбәкләрендә яшәгән фин-угыр халыкларының бер өлеше һуннар хәрәкәтенә кушылырга мәҗбүр була. Абориген кабиләләрнең мәдәни тормышындагы кайбер үзгәрешләр археологик материалларда чагылыш таба. Мәсәлән, Пермь краенда, Киров, Ульян өлкәләрендә, Татарстанда табылган бронза казаннарны, һичшиксез, әлеге төбәкләргә үтеп кергән һун сугышчылары алып килгән. Самара өлкәсендә тикшерелгән каберлекләрдә һуннарның матди культурасына хас әйберләр: кылычлар, ук очлары, ат йөгәне бизәкләре, каеш прәшкәләре бар [Богачев, 2011, с. 186—202]. Күчмәннәр йогынтысы астында җирле халыкларның күмү йоласында яңа элемент — үлгән кешеләрне курганнарда күмү йоласы барлыкка килә. Тел галимнәре фикеренчә, этник үзгәрешләр хәтта топонимикада да чагылыш тапкан [Гарипова, 1995, с. 243—247].

«Һуннар Идел — Кама буенда» проблемасын өйрәнүдә яңа этап узган гасыр урталарында башлана. Татарстанның хәзерге Менделеев районы Турай авылы янында урнашкан борынгы зиратта күренекле археолог В.Ф. Генинг тарафыннан IV гасыр ахыры — V гасырның беренче яртысында күмелгән ике дистәдән артык сугышчының бай каберләре казып тикшерелде [Генинг, 1976, с. 55—108]. Тирәнлеге 2 метрдан алып 3,7 метрга җитә торган каберләргә төшереп урнаштырылган агач табутларда башларын көньяк-көнбатышка каратып куелган гаскәр башлыклары ята. Мәет белән янәшәдә саплары көмеш фольга белән бизәлгән кылычлар, сөңге һәм ук очлары, сугыш балталары, очлым, көбә күлмәк һәм башка кораллар куелган. Күмелгән сугышчыларның этносын ачыклауга В.Ф. Генинг бик сак килә: «Нәкъ менә шул вакытта (IV гасыр ахырында. — Ф.Х.) Көньяк Урал һәм Түбән Идел далаларыннан ташкындай булып һуннар урдасы узып китә һәм Турай төркеме, ихтимал, шул ташкынга ияреп көнбатышка хәрәкәт итүче сугышчылар булгандыр. Бу төркем, күрәсең, һуннарның Кара диңгез даларына һөҗүме алдыннан (370 ел), ниндидер сәбәпләр аркасында төп гаскәрдән аерылып калып, төньякка, Түбән Кама тирәләренә күчеп киткәндер» [Генинг, 1976, с. 108]. Галим, Турай авылы янын-

да күмелгән сугышчыларның төрки кабиләләрдән чыккан булуын дөреслеккә якын, дип саный [Генинг, 1972, с. 288].

Аның бу фикере археологларның күпчелеге тарафыннан яклау тапты [Халиков, 1986, с. 73—90; Сунгатов, 2006, с. 153—155], әмма Турай каберлегенең башка этник төркемнәр тарафыннан калдырылган булуын исбатларга алынучылар да бар. Мәсәлән, Самара археологы Г.А. Матвеева, Турай сугышчылары каберлегендә табылган әйберләрнең аналогияләрен Себер һәм Урта Азия якларыннан түгел, бәлки көнбатыштан, славяннар белән турыдан-туры бәйләнеше булган пшевор археологик культурасы материалларыннан эзләргә кирәк, дип язып чыкты [Матвеева, 2004, с. 73]. Удмуртия дәүләт университеты археологы профессор Р.Д. Голдина исә турайлыларны һуннар һөҗүме вакытында тар-мар ителгән, Кара диңгез буйларыннан күчеп утырган герман телле готлар белән тиңләштерергә тырышып карады [Голдина, Бернц, 2010]. Әлеге археологлар Турай каберлегендә табылган кайбер әйберләрнең (мәсәлән, сугыш балталарының) көнбатыш халыкларыныкына охшаш булуына басым ясыйлар. «Турай проблемасын» чишүдәге катлаулы ситуациядән чыгу юлын А.В. Богачев күрсәтте һәм аның фикере белән бүгенге көндә күпләр килешә. Турай сугышчылары ул, Аттиланың үлеменнән соң (453 ел) Көнбатыш Европадан кире Кара диңгез буе далаларына әйләнеп кайткан һуннарның Урта Идел һәм Урал якларына күчеп киткән бер төркеме дип саный [Богачев, 2009, с. 207—220].

Заманында академик В.В. Бартольд һәм М.Г. Худяков чувашларның килеп чыгышын һуннар белән бәйләп карарга омтылыш ясаганнар иде [Бартольд, 1968, с. 37—38; Худяков, 1927, 135—146]. Әлеге фикерне А.Х. Халиков узган гасырның икенче яртысында Сура һәм Зөя елгалары бассейнында казып тикшерелгән Писералы (Мари Эл) һәм Андреево (Мордовия) каберлекләренең бай материаллары белән ныгытырга тырышты [Халиков, 1987, с. 24; 2011, с. 29]. Писералы-Андреево тибындагы каберлекләрнең үзенчәлекләрен галим Көньяк Уралда һәм Казакъстанның төньяк-көнбатыш территорияләрендә яшәгән төркиләрдә таба. Әлеге төркиләрнең бер төркеме, имеш, элегрәк Көнбатыш Себернең төрки-угыр телле кабиләләре белән катнашырга өлгергән һәм II гасыр урталарында ук Иделгә юнәлгән һуннар составында хәрәкәт итә, аннан соң, алардан аерылып, Сура — Зөя буйларына килеп чыга. Менә шул кечкенә генә төркем, А.Х. Халиков фикеренчә, хәзерге чувашларның этнос буларак оешу процессында катнаша. Әйе, Писералы һәм Андреево каберлекләрендә күмелгән кешеләр, һичшиксез, чит кабиләләрдән чыккан күчмәннәр — галимнең бу тезисы беркемдә дә шик уятмый. Әмма чуваш этногенезында аларның катнашы бармы? Бусы — бәхәсле мәсьәлә. Әлеге проблема белән махсус шөгыльләнгән Самара археологы С.Э. Зубов Писералы һәм Андреево авыллары янындагы каберлекләрдә табылган сугышчыларның калдыкларын һуннар басымы астында Көнбатыш Себердән күчеп килгән угырлар — саргат археологик культурасы белән бәйли [Зубов, 2011, с. 87]. Бу кайбер археологик материаллар белән расланган, шунлыктан ярыйсы гына ышандыру көченә ия булган чираттагы фараз гына.

Мәкаләнең ахырында инде ярты гасырдан артык актуальлелеген һич тә югалтмаган, вакыт үткән саен кискенләшә генә баручы бәхәсләр белән «баетылгын» имәнкискә проблемасына кагылып үтү урынлы булыр. 1953—1954 елларда Республикабызның Лаеш районы Имән Кискә авылы янында Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиков тарафыннан IV—VII гасырларга караган шәһәрлек [Калинин, 1960, с. 226—250], 1956—1957 елларда шул ук районның Рождествено авылы янында В.Ф. Генинг тарафыннан зур гына каберлек казып тикшерелә [Генинг, 1960, с. 131—144]. Яңа ачылган имәнкискә археологик культурасына тулы характеристиканы П.Н. Старостинның 1967 елда Мәскәүдә басылып чыккан монографиясеннән табарга мөмкин [Старостин, 1967]. Бүгенге көндә фәндә борынгы имәнкискәлеләр калдырган 600 дән артык археологик истәлек билгеле. Алар, башлыча, Самара һәм Ульян өлкәләрендә, Татарстан Республикасында — Сура елгасыннан алып Агыйделгә кадәр, Каманың түбән агымыннан башлап Самар елгасына кадәр булган зур гына территориядә урнашканнар.

Имәнкискә кабиләләренең матди культурасы, күмү йолалары җирле халыкныкыннан кискен аерылып тора. Мәсәлән, мәетләрне алар башта яндырганнар (киемнәре белән), көл-күмер, янган сөяк калдыкларын, бөтенләй янып юкка чыкмаган металл әйберләрне, кечкенә генә чокыр казып, шуның төбенә таратып ташлаганнар, янәшәгә бер яисә берничә балчык чүлмәк куйганнар. Авыл урыннарын, ныгытылган торак пунктларын казыганда йорт һәм каралты-кура калдыклары, савыт-саба китекләре, эш һәм сугыш кораллары, балчыктан әвәләп ясалган хайван сурәтләре табыла. Имәнкискәлеләрдә игенчелек нык үсеш алган. Җирле кабиләләр арасында алар, иң беренчеләрдән булып, җирне ат җигелгән сука белән сөреп эшкәрткәннәр. Тимерчелек белән шөгыльләнгәннәр, башка төрле һөнәрләрне белгәннәр. Ерак төбәкләр, хәтта Шәрекъ илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырганнар. Кыскасы, әлеге кабилә кешеләре ярыйсы гына югары үсешкә ирешкән җәмгыятьтә яшәгәннәр.

Кемнәр алар, имәнкискәлеләр? Бу сорауга беренче җавапны Н.Ф. Калинин бирде. Аның фаразлавынча, имәнкискә археологик культурасын, кайберәүләр уйлаганча, җирле фин-угырлар түгел, бәлки төрки телдә сөйләшүче бортаслар калдырганнар [Калинин, Халиков, 1954, с. 57 и сл.]. Бу фикергә соңрак В.Ф. Генинг та кушыла [Генинг, 1972, с. 289]. Гомумән, имәнкискәлеләрнең Урта Идел буйларына һуннар, аннан соң Төрки каганатлар чорында килеп утырган халык булуына шикләнүчеләр юк диярлек. Ә аларның төгәл этносы турында сүз чыкканда карашлар төрлечә кала бирә. П.Д. Степанов, мәсәлән, безнең яклар өчен чит-ят имәнкискә кабиләләрен угыр-мадьярлар (венгрлар) дип санады [Степанов, 1964, с. 136—148; 1967, с. 105]. А.П. Смирнов исә, Рождествено каберлеге материалларын көнчыгыш славяннарныкы белән чагыштырып, анда күмелгән кешеләрнең борынгы славяннар кавемененнән чыгулары турындагы фикерне алга сөрде [Смирнов, 1960, с. 7]. Бу фикерне 1980 елларда Г.И. Матвеева күтәреп алды, өстәмә аргументлар белән баетты [Матвеева, 1981, с. 52—73; 2004] һәм ул, әлеге фикер, тарихи-

археологик әдәбиятта киң яклау табып [Седов, 1994, с. 315; Приходнюк, 1998, с. 76; Голдина, 1999, с. 261, 266, 277; Богачев, 2007], 7 томлык «Татар тарихы»ның беренче томы авторлары тарафыннан да кабул ителде [Кляшторный, Старостин, 2002, с. 210—217].

Имәнкискәлеләрнең этник асылына үзгәрәк караш ташлаучылар да булды. А.Х. Халиков, мәсәлән, аларны борынгы балтлар («протолитовцы») дип атый башлады, Идел—Урал төбәкләрендә хәтта балт топонимнарын да табып алды [Халиков, 1988, с. 119—126; 2011, с. 81—83]. Галимнәр арасында бу фикерне яклаучылар табылмады.

Е.П. Казаковның яңа һәм оригиналь фаразы имәнкискә культурасының килеп чыгышын иран телле сарматлар дөньясы белән бәйли [Казаков, 1996, с. 40—57; 1996, с. 97—150; 2004, с. 280—284; 2006, с. 155—162; 2011, с. 8—39]. Әлеге фаразның ныклы тарихи нигезе бар. Е.П. Казаков имәнкискә кабиләләренең яңа табылган каберлекләрен тикшереп, аларда мәетне яндыру (кремация) гына түгел, бәлки яндырмыйча күмү (ингумация) йоласы да булуын ачыклады. Соңгысы борынгы славяннар өчен һич тә хас йола түгел. Галим үзенең тикшеренүләрен комплексլы характерда алып бара, ягъни сарматларның күмү йолаларын да, матди культураларын да тирән анализлап, фәнни яктан кире кага алмаслык күзәтүләр, нәтиҗәләр ясый. Е.П. Казаковның сармат кабиләләрен тулысынча иран телендә сөйләшүчеләр рәтенә куюын гына кабул итеп булмый. Археология материаллары күрсәткәнчә, II—IV гасырларда Көньяк Урал, Түбән Идел һәм Дон буе далаларында тереклек итеп ятучы сарматлар һуннарның көчле йогынтысына эләгәләр, аларның бер өлеше хәтта төркиләшә дә [Боталов, 2000]. Исегезгә төшереп үтим: күренекле болгарчы-галим проф. А.П. Смирнов әле узган гасыр урталарында ук Идел болгарларының килеп чыгышында, аларга хас үзенчәлекле культураның формалашуында сарматларның роле искиткеч зур булуын билгеләп үткән иде [Смирнов, 1951, с. 19—20]. Болгарлар белән бер рәттән төрки телле аланнар да — этник яктан алар, һичшиксез, сарматлар токымыннан — соңрак Хәзәр каганлыгының төп халкын тәшкил иткәннәр. Сарматларның һәм аларның дәвамчылары саналган аланнарның әүвәл һуннар, соңыннанрак Хәзәр каганаты составындагы болгарлар тарафыннан төркиләшкән кабиләләр булуы турындагы фикер киләчәктә яңа фәнни агументлар белән тагын да баетылыр, тулыландырылыр дип уйлыйм.

Имәнкискәлеләрнең славяннар булуын шик астына алырга мәҗбүр итә торган сәбәпләрнең тагын берсе шул: соңгы елларда үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә аларның, протославяннарның, Одер — Висла бассейны тирәләрендә урнашкан борынгы җирләреннән, М.З. Зәкиев сүзләре белән әйткәндә, ана-ватаныннан [Седов, 2002, с. 69] Көнчыгыш Европаның урман-далалы өлкәләренә, хосусан, киләчәктә Киев Русе үсеп чыгачак җирләргә күчеп утырулары V гасырда гына булуы ачыкланды. Археология буенча югары уку йортлары өчен Мәскәү дәүләт университеты чыгарган соңгы дәреслеккә күз төшерик (биредә фактлар кат-кат үлчәнеп бирелгәндер дип уйлыйм): «Как мы знаем, ни одна из земледельческих археологических культур... первой

половины I тыс. н.э., чьи памятники исследованы на обширных лесостепных пространствах, не являлась чисто славянской — население каждой из них было неоднородным и состояло из различных этнических компонентов, автохтонных и пришлых... На территории от Эльбы до Днепра и от Поморья до Дуная в V в. складывается относительно единообразная археологическая культура, получившая название пражской. Пражская культура (корчакская на территории Украины. — *Ф.Х.*) является практически единственной культурой, чья принадлежность ранним славянам является общепризнанной» [Археология..., 2006, с. 410]. Прага-корчак культурасын калдырган славяннар мәйданы 1 гектардан артмаган авылларда көн күргәннәр, ныгытылган шәһәрлекләр бик сирәк очрый. Казылмалар табылдыкларга бай түгел («славянские культуры выглядят на удивление бедными» [Щукин, 2005, с. 158]): кулдан эшләнгән чүлмәк китекләре, орчык башлары, пычаклар, сирәк кенә каеш прәшкәләре, фибулалар, беләзекләр, аз санлы башка төрле әйберләр. Менә шул славяннар, имеш, үзләре яши торган җирләргә генә сыешмыйча, III—IV гасырлардан башлап (?), искиткеч зур киңлекләрне үзләштергәннәр — аларның, имәнкискәлеләрнең, көнчыгыш төбәкләрдәге археологик истәлекләре хәтта Агыйдел буйларында, Уфа тирәсендә дә табылган.

Монда шикләнер нәрсәләр күп әлбәттә. Халыкларның Бөек күченеш чорында славяннарның һуннар, башка төрки күчмәннәр тарафыннан урыннарыннан кузгатылып, тынычрак төньяк-көнчыгыш тарафларга юл тотуы, беренче карашка, бер дә гаҗәп түгел. Тик, бик җиңел генә мондый реконструкцияләр тәкъдим иткәнче, имәнкискә кабиләләре калдырган археологик истәлекләрне максатчан һәм комплекслы рәвештә тикшерергә, нәтиҗәләрен гомумиләштереп, әлеге өлкәдә эшләүче белгечләргә җиткерергә кирәк. Шулай булмаганда, имәнкискә «славяннарын», академик В.В. Седов фикеренә кушылып [Седов, 2001, с. 5—15], Идел Болгары дәүләтен оештыручы һәм шул дәүләт чикләрендә яшәүче төп халыклар рәтенә кертеп куярга әзер галимнәр дә табылачак.

Аңлашыла ки, Урта Идел буе халыкларының болгарларга кадәрге чорын өйрәнүдә, тарихи чыганакларның аз булуы сәбәпле, археология фәненә өстенлекле урын бирелә. Кызганыч, Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтында бу өлкәдә эшләүче бер генә белгеч дә юк. Галимнәрне генә түгел, киң катлау җәмәгатьчелекне дә тирәнтен кызыксындыра торган этник тарихыбыз проблемалары киләчәктә киң планда, комплекслы рәвештә өйрәнелергә тиеш.

**Әдәбият**

Gülensoy Tuncer. Barbar türkler. Ankara, 2011. 494 s.

*Акимова М.С.* Антропология древнего населения Приуралья. М.: Наука, 1968. 119 с.

Археология: учеб. / под ред. акад В.Л. Янина. М.: Изд-во МГУ, 2006. 608 с.

*Бартольд В.В.* Двенадцать лекций по истории турецких народов Средней Азии // Бартольд В.В. Сочинения. М., 1968. Т. V. С. 19—192.

*Богачев А.В.* Хронология двукружковых поясных накладок и проблема миграций в Волго-Камье на рубеже IV—V веков // Археологические памятники Оренбужья. Вып. VII. Оренбург, 2007.

*Богачев А.В.* Славяне, германцы, гунны, болгары на Средней Волге в I тыс. н.э. — Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2011. 340 с.

*Боталов С.Г.* Гунны и тюрки: историко-археологическая реконструкция. Челябинск: Рифей, 2009. 672 с.

*Боталов С.Г., Гуцалов С.Ю.* Гунно-сарматы Урало-Казахстанских степей. Челябинск: Рифей, 2000. 267 с.

*Гарипова Ф.Г.* История в названиях. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 287 с.

*Генинг В.Ф.* Селище и могильник с обрядом трупосожжения доболгарского времени у села Рождествено в Татарии // Материалы и исследования по археологии СССР. М. 1960. № 80. С. 131—144.

*Генинг В.Ф.* Тураевский могильник V в. н.э. (захоронения военачальников) // Из археологии Волго-Камья. Казань, 1976. С. 55—108.

*Генинг В.Ф.* Южное Приуаралье в III—VII вв. н.э. (проблема этноса и его происхождения) // Проблемы археологии и древней истории угров. М., 1972. С. 221—295.

*Геродот*. История в девяти книгах / пер. с греч. и коммент. Г.А. Стратановского. М.: Олма-Пресс Инвест, 2004. 640 с.

*Голдина Р.Д.* Древняя и средневековая история удмуртского народа. Ижевск: Изд-во Удм. гос. ун-та, 1999. 464 с.

*Голдина Р.Д., Берну В.А.* Тураевский I могильник — уникальный памятник эпохи Великого переселения народов в Среднем Прикамье. Ижевск: Изд-во Удм. гос. ун-та, 2010. 499 с.

*Грязнов М.П.* Аржан. Л.: Наука, 1980. 62 с.

*Дёрфер Г.* О языке гуннов // Зарубежная тюркология. Вып. 1. Древние тюркские языки и литературы. М., 1986.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. М.: Инсан, 1998. 624 б.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы тарихы: этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 544 б.

*Зәкиев М.З.* Хәзерге татар халкының тирән тамырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 359 б.

*Зубов С.Э.* Воинские миграции римского времени в Среднем Поволжье (I—III вв.). Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2011. 136 с.

История татар с древнейших времен: в 7 томах. Казань: Рухият, 2002. Т. I: Народы степной Евразии в древности. 551 с.

*Казаков Е.П.* К вопросу о турбаслинско-именьковских памятниках Закамья // Культуры Евразийских степей второй половины I тысячелетия н.э. Самара, 1996. С. 40—57;

*Казаков Е.П.* Коминтерновский II могильник в системе древностей эпохи Тюркских каганатов // Культуры Евразийских степей второй половины I тысячелетия н.э. (вопросы хронологии). Самара, 1996. — С. 97—150;

*Казаков Е.П.* Новые материалы к проблеме интерпретации именьковских древностей // Вопросы археологии Урала и Поволжья. Вып. 2. Самара, 2004. С. 280—284.

*Казаков Е.П.* К проблеме выявления древностей средневековых сармат // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала. Казань, 2006. С. 155—162.

*Казаков Е.П.* Этнокультурная ситуация IV—VII вв. н.э. в Среднем Поволжье // Finno-Ugrica. 2011. № 12—13. С. 8—39.

*Калинин Н.Ф.* К вопросу о происхождении казанских татар // Происхождение казанских татар. Казань, 1948. С. 90—107.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Именьковское городище // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1960. № 80. С. 226—250.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ 1945—1952 гг. // Тр. КФАН СССР. Сер. гуманит. наук. Казань, 1954. 126 с.

*Каховский В.Ф.* Происхождение чувашского народа. Основные этапы этнической истории. Чебоксары: Чув. кн. изд-во, 1965. 483 с.

*Кляшторный С.Г., Старостин П.Н.* Праславянские племена в Поволжье // История татар с древнейших времен: в 7 томах. Казань, 2002. Т. I: Народы степной Евразии в древности. С. 210—217.

*Коновалов П.Б.* Некоторые итоги и задачи изучения хунну // Древние культуры Монголии. Новосибирск, 1985. С. 41—50.

*Кузеев Р.Г.* Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: этногенетический взгляд на историю. М.: Наука, 1992. 347 с.

*Малов С.Е.* Выступление на сессии Отделения истории и философии АН СССР и ИЯЛИ КФАН СССР // Происхождение казанских татар. Казань, 1948. С. 116—119.

*Матвеева Г.И.* О происхождении именьковской культуры // Древние и средневековые культуры Поволжья. Куйбышев, 1981. С. 52—73;

*Матвеева Г.И.* Среднее Поволжье в IV—VII вв.: именьковская культура. Самара: Изд-во СГУ, 2004. 168 с.

*Приходнюк О.М.* Пеньковская культура. Культурно-хронологический аспект исследования. Воронеж: Изд-во Воронеж. гос. ун-та, 1998. 256 с.

*Седов В.В.* Славяне в древности. М.: Наука, 1994. 344 с.

*Седов В.В.* К этногенезу волжских болгар // Российская археология. 2001. № 2. С. 5—15.

*Седов В.В.* Славяне: историко-археологическое исследование. М.: Языки славянской культуры, 2002. 624 с.

*Смирнов А.П.* Введение // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1960. № 80. С. 5—9.

*Смирнов А.П.* Волжские булгары. Тр. ГИМ. Вып. XIX. М., 1951. 275 с.

*Смирнов А.П.* Некоторые спорные вопросы истории волжских болгар // Историко-археологический сборник. М., 1962. С. 160—174.

*Старостин П.Н.* Памятники именьковской культуры. САИ. Вып. Д 1-32. М.: Наука, 1967. 97 с.

*Степанов П.Д.* Памятники угро-мадьярских (венгерских) племен в Среднем Поволжье // Археология и этнография Башкирии. Уфа, 1964. Т. II. С. 136—148.

*Степанов П.Д.* Ош Пандо. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1967. 211 с.

*Сунгатов Ф.А.* Гунны в Волго-Уральском регионе // История татар с древнейших времен: в 7 томах. Казань, 2002. Т. I: Народы степной Евразии в древности. С. 153—155.

*Тумэн Д.* Антропологическая характеристика хунну Монголии // Древние культуры Монголии. Новосибирск, 1985. С. 87—96;

*Федоров-Давыдов Г.А.* Некоторые проблемы археологии Поволжья железного века // Археология и социальный прогресс: материалы конференции. М., 1991. Вып. 2. С. 72—83.

*Фирсов Н.Н.* Чтения по истории Среднего и Нижнего Поволжья. Казань, 1919. Вып. II. 136 с.

*Халиков А.Х.* Истоки формирования тюркоязычных народов Поволжья и Приуралья // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 7—36.

*Халиков А.Х.* Об этнокультурной ситуации в Среднем Поволжье и Приуралье в I тысячелетии н.э. // Культуры Восточной Европы I тысячелетия. Куйбышев, 1986. С. 73—90.

*Халиков А.Х.* Памятники писеральско-андреевского типа в Волжском правобережье и их этнокультурная интерпретация // Археология и этнография Марийского края. Йошкар-Ола, 1987. Вып. 12. Древности Волго-Вятского междуречья. С. 8—24.

*Халиков А.Х.* К вопросу об этносе именьковских племен // Памятники первобытной эпохи в Волго-Камье. Казань, 1988. С. 119—126.

*Халиков А.Х.* Основы этногенеза народов Среднего Поволжья и Приуралья. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2011. 336 с.

*Худяков М.Г.* К вопросу о происхождении чуваш // Изв. Об-ва обследования и изучения Азербайджана. 1927. № 4. С. 135—146;

*Хузин Ф.Ш.* Узловые проблемы изучения средневековой тюрко-татарской цивилизации // Средневековая археология Евразийских степей. Т. I. Казань, 2007. С. 26—37.

*Хузин Ф.Ш.* У истоков тюрко-татарской цивилизации // Татарстан: из века в век. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. С. 7—32.

*Чижевский А.А.* Погребальные памятники населения Волго-Камья в финале бронзового — раннем железном веках (предананьинская и ананьинская культурно-исторические области). Казань: Ин-т истории АН РТ, 2008. 172 с.

*Щукин М.Б.* Готский путь: готы, Рим и черняховская культура. СПб: Изд-во СПбГУ, 2005. 576 с.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*А.Х. Халиков исем. Археология институтының*
*Урта гасырлар археологиясе бүлеге мөдире*
*e-mail: khuzinfayaz@mail.ru*

УДК 94

***А.Х. Мәхмүтова***

# КАЗЫЯ МӨХЛИСӘ БУБЫЙ

Статья раскрывает становление Мухлисы Буби как педагога и общественного деятеля, ее усилия по развитию системы женского национального образования, деятельности в качестве казыя в Центральном духовном управлении мусульман внутренней России и Сибири. В конце статьи приводятся тексты ее выступления при открытии женской школы Яушевых в Троицке в 1914 г. и двух статей, посвященных роли женщины в семье и обществе, которые были опубликованы в «Исламском журнале» ЦДУМ в 1924 и 1925 гг.

**Ключевые слова:** Мухлиса Буби, медресе Иж Буби, новометодное образование, Центральное духовное управление мусульман внутренней России и Сибири, III съезд мусульманского духовенства ЦДУМ, «Исламский журнал» ЦДУМ.

Атаклы мәгърифәтче Бубыйлар нәселенең мәшһүр бер әгъзасы Мөхлисә Габделгалләм кызы Нигъмәтуллина-Бубый 1869 елның 21 февралендә (5 мартында) дөньяга килгән. Россиянең караңгы почмагы саналган Вятка губернасының Сарапул өязе, Иж-Бубый авылында (хәзер Татарстанның Әгерҗе районында) туып үскән татар кызы ике дистә ел кызлар укыткан-тәрбияләгән (1896/97—1917), егерме ел (1917—1937) Русия мөселманнарының диния идарәсе әгъзасы, ислам тарихында бүгенге көнгә кадәр бердәнбер булып калган казыя, ягъни шәригать кануннарын яхшы белүче хөкемдар булган. Ул ничек бу дәрәҗәгә җиткән соң? Кайда белем алган, нинди университетлар, академияләр яки мәдрәсәләр тәмамлаган, карашлары кайда һәм ничек формалашкан?

Мөхлисә Иж-Бубый авылы имамы һәм мөдәррисе Габделгалләм хәзрәт Нигъмәтулла углы (1834—1903) һәм аның җәмәгате Бәдрелбәнат абыстай (1838—1922) гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килгән. Бу гаиләдә балалар ислам кагыйдәләренә туры китереп тәрбияләгәннәр, аларны яшьтән үк хезмәткә, укуга ихтирам белән карарга, үзләренә карата таләпчән булырга өйрәткәннәр. Үз чоры өчен яхшы белемле Бәдрелбәнат абыстай, Минзәлә өязе Чебенле авылында имам вә мөдәррис Иманкол Мәхмүд углының кызы, Габделгалләм хәзрәткә кияүгә чыкканда ук «галимә вә гарәпчә белән фарсычадан да яхшы ук хәбәрдар» [Бубый, б. 9] булган, кияүгә чыккач та белемен арттыруын дәвам иткән, Габделгалләм хәзрәттән балаларны укыту серләренә өйрәнгән, өенә авыл кызларын җыеп, аларны укыткан, авыл хатын-кызларына дини-әхлакый тәрбия бирү юлында да зур тырышлык күрсәткән. Табигый ки, гел әнисе янында булган Мөхлисә бик кечкенә (өч-дүрт яшьлек) чагында ук хәреф таный башлаган, укырга гына түгел, язарга да өйрәнгән. Кызы бераз үсә төшкәч, абыстай аны һәм тагын берничә укуга һәвәс кызны гарәп-фарсы телләре белән дә таныштыра башлаган.

Сабый чактан ук Мөхлисә китап укырга яраткан. Әлбәттә, кечкенә Мөхлисә «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Мөхәммәдия», «Бәдәвам» кебек төрки классик әсәрләрен би-

релеп укыган, «Сак-Сок» кебек бәет-мөнәҗәтләрне яттан белгән. Гарәп-фарсы телләре белән таныша башлагач, аның күңелен Шәрекъ классикасы биләп алган. Сабый чагыннан ук белемгә тартылган Мөхлисә этисе мәдрәсәдә укыта торган фәннәр белән дә кызыксынган.

1887 елда 18 яшьлек Мөхлисәне Минзәлә өязе мулласы Җәләледдин Әхмәтҗан углына кияүгә биргәннәр. Инде берничә ел әнисенә кызлар укытуда ярдәм итеп килгән Мөхлисә да, үз эти-әнисе кебек, ире белән бергә кулга-кул тотышып, авыл халкын агарту, мәгърифәтле итү турында хыялланган. Ләкин бу өметләр, хыяллар бик тиз чәлперәмә килгән. Дуамал, бозык фигыльле, каты күңелле, укыту эшен бер дә яратмаган хәзрәт яшь абыстайның кызлар укыту теләгенә катгый каршы килгән. Аның көннән-көн караңгылана барган тормышында ике кечкенә кыз — ире сүзенә карамастан тәрбиягә алган ятимә кыз Наҗия (1894—1967) һәм үз кызы Мөнҗия (1895—1919) генә юаныч булган. Ихтимал, абыстайның язмышы да, башка күп кенә авыл муллаларының хатыннары язмышы кебек, аяусыз булган булыр иде, ләкин кызга туганнары — абыйсы һәм энесе ярдәмгә килгән. Мөхлисә абыстайның аһзарларын ишеткән туганнары аны үзләренә алып кайтып киткәннәр. Бубыйларның бу тәвәккәл адымына исе киткән хәзрәт, ачуы килсә дә, хатынын азәрлекләмәгән, ләкин рәсми аермаган да. Әлеге вакыйгадан соң ике дистә ел үткәч кенә, казый Ризаэддин Фәхретдин биргән фәтва нигезендә 1917 елда бу аерылышу рәсми төс алган.

1895 елда башлап җибәргән ирләр мәдрәсәсен үзгәртүдәге уңышлар агалы-энеле Гобәйдулла (1866—1938) һәм Габдулла (1871—1922) Бубыйларда кыз балаларга да нигезле белем бирү өчен яңа типтагы кызлар мәктәбе төзү фикерен уяткан. Хатын-кызларга тирән белем, яхшы тәрбия, белемнәрен арттыру өчен мөмкинлекләр бирү, бертуган Бубыйлар фикеренчә, милләтне алга җибәрү шартларының иң мөһимнәреннән саналырга тиеш. Хатын-кыз бала тәрбияләүдә беренче һәм төп роль уйный торган шәхес; нәкъ менә ул баланың табигатен, характерын формалаштыра, аның акылын һәм хиссиятен тәрбияли, аңа беренче әхлакый төшенчәләрне сеңдерә. Димәк, хатын-кызга бу вазифасын тиешле дәрәҗәдә башкарырлык белем һәм тәрбия бирү зарури. Хатын-кызларны яхшы тәрбияләр өчен һәр җирдә кызлар мәктәпләре ачу тиеш; моның өчен беренче адым — бу мәктәпләргә белемле мөгаллимәләр тәрбияләүче кызлар мәдрәсәсе — дарелмөгаллимәт булдырырга кирәк. Шулай XIX гасыр азагында бертуган Бубыйлар, этиәниләренең ризалыгын алып, милләт өчен зарури булган эшкә — кызлар мәдрәсәсен оештыруга керешкәннәр.

Яңа кызлар мәктәбен оештыруда иң актив хезмәт итүчеләр, һичшиксез, гаиләнең яшь буын хатын-кызлары — туганнары Мөхлисә абыстай, Гобәйдулла әфәнденең хәләл җефете — Нәсимә Шакирҗан кызы Фәйзуллина һәм Габдулла Бубыйның җәмәгате — фикердәше һәм мәдрәсәнең төп иганәчесе булган Мөхәммәдҗан Әхмәтҗановның балдызы, Пермь сәүдәгәрләре Гыйззәтуллиннар нәселеннән булган Хөснефатыйма (1873—1941) булган. Бертуган Бубыйлар күңелләрендә туып килгән яңа төр (җәдиди) кызлар мәктәбендә укыту өчен бе-

лемле мөгаллимәләр әзерләүне үз гаиләсендәге яшь абыстайлардан башлаганнар. Алар исә, җиң сызганып, яңа эшкә өйрәнергә һәм җәдид ысулы белән кызларны укыту-тәрбия эшенә керешкәннәр.

«Без үзебез дә бу мәктәптә тәртип күрсәттек, интизам [рәткә салу, төзү] вә ысулларны карадык. Һәм көнгә икешәр сабак та бирдек. Ләкин бу мәктәптә тәмам җаннарытәннәре белән эшләүчеләр, һәрбер рәхәтләрен шушы мәктәпнең тәрәккъыйсы өчен фида кылучылар безнең ата-ана бертума кардәшебез Мөхлисә Бубый белән абзыйның әһлиясе Нәсимә вә минем әһлиям Хөснефатыйма булдылар. Болар өчесе дә кич буенча бездән укып, көн буенча мәктәптә укытырлар вә күрмәгән кеше бер дә ышанмаслык мәшәкатьләр йөкләрләр иде. Болар, Русия мөселманнарының хатын-кызларын гыйлем вә мәгариф юлына кертү өчен иң начар вә иң кабахәт сүзләр ишетә-ишетә, һәрбер төрле бәла вә авырлыкларны йөкләделәр, вә бер тиен айлыксыз, фәкать милләт өчен дип, бик зур адәмнәр кыла торган хезмәт вә иҗтиһадларны кылдылар» [Бубый, б. 34—35], — дип тасвирлаган Г. Бубый.

Беренче көннәрдән үк яңа төр кызлар мәдрәсәсен оештыру эшенә Мөхлисә абыстай җаны-тәне белән бирелгән. Бу елларда ул ир туганнары ярдәме белән ирләр мәдрәсәсе программасының нигезен тәшкил иткән дини тәгълиматны өйрәнүне дә дәвам иткән. 1905 елга, ягъни Бубый мәдрәсәләре киң колач белән эшли башлаган вакытка, Мөхлисә абыстай ислам тәгълиматын яхшы белгән галимә булып җитешкән инде. Мөгаллимәләр әзерли торган дарелмөгаллимәт булып өлгергән кызлар мәдрәсәсе белән җитәкчелек итүне дә туганнары аңа тапшырганнар.

1908 елда Сарапул өяз земствосы бертуган Бубыйларның татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү эшен башкаруларын рәсми рәвештә таныган: аларга «татар мәктәпләрендә укытучы-мөгаллим» һәм «укытучы-мөгаллимә» исеменә имтихан алу һәм таныклык бирү хокукы бирелгән. Габдулла Бубый сүзләре белән әйтсәк, Русиядә иң элек ислах кылынган вә иң элек мөгаллимәләр чыгара башлаган кызлар мәктәбе — менә шушы Бубый кызлар мәктәбе [Шунда ук, б. 34]. Беренчеләрдән булып, «укытучымөгаллимә» таныклыгы Мөхлисә ханымга һәм кызлар мәдрәсәсенең башка мөгаллимәләренә тапшырылган. Таныклыклар, рәсми документ буларак, барлык административ оешмалар тарафыннан кабул ителергә тиеш булуын да ассызыклыйк.

1908 елда Бубыйда мөгаллимнәр һәм мөгаллимәләр өчен аерым-аерым махсус җәйге өч айлык курслар эшли башлаган. Бик зур саклык белән эшләгән бу рәсми булмаган курсларда 1908 елда барысы 6 мөгаллимә укыса, 1909 елда — 42, 1910 елда 58 мөгаллимә белемен арттырган. «Болар ысуле тәгълим күрүдән башка фөнүне җәдидә [яңа фәннәр] укып та бик истифадә кылдылар, килгән мөгаллим вә мөгаллимәләр һәммәсе бик разый вә бик мәмнүн булып киттеләр, — дип ассызыклаган Г. Бубый. — Бәс, бара-бара Бубыйның бу җәйге сыйныфы дәхи дә куәтләнәчәк иде, ләкин 1911 елны без дә тотылдык, мәдрәсә дә ябылды. Шулай да башка җирләрдәге җәйлек мөгаллимнәр сыйныфы хөкүмәт тарафыннан ябылдыгы вә рөхсәт сораган адәмнәргә рөхсәт бирелмәгәнлеге хәлдә, Бубыйныкы,

без бер дә рөхсәт сорап азапланмадыгыбыздан вә хөкүмәт күзеннән мөмкин кадәр яшеренергә тырышканыбыздан, өч җәй мөттасил [тоташ] дәвам кылды» [Бубый, б. 34].

Мөгаллимәләр өчен ачылган курслар Мөхлисә абыстай һәм башка мөгаллимәләрнең тырышлыгы белән 1911 елның җәендә дә, ирләр мәктәпләре ябылып, бертуган Бубыйлар кулга алынгач та, эшен дәвам иткән әле. «В мире мусульманства» газетасының 1911 ел 5 (18) август санында ул җәйдә монда 60 ка якын мөгаллимә белем арттыруы хакында хәбәр бирелгән. Шулай итеп, бу курсларда гына да дүрт җәй эчендә 170 кә якын мөгаллимә өстәмә әзерлек алып чыккан. Иң мөһиме — курсларда белем алган мөгаллимәләр кулларына рәсми таныклык та алып киткәннәр. Димәк, җәдид мәктәпләренә һөҗүм башлангач, ган чорда шул кадәр мәктәп ябылмыйча калган, дияргә дә нигез бар. Бу курсларга килгән укучылар, педагогик һәм методик әзерлектән тыш, кызлар мәктәпләрен оештыру эшенә дә өйрәнгәннәр, үрнәк программалар һәм уку планнары, дәреслек-кулланмалар исемлеген дә алып киткәннәр.

Бертуган Бубыйларның кызлар өчен махсус педагогик урта белем бирә торган уку йортын төзүдәге уңышларын ачыграк күрсәтер өчен, чагыштырма таблицага игътибар итик. Бу таблицага өч уку планы — 1910 елгы Бубый дарелмөгаллимәте, 1914 елда «Сөембикә» журналында үрнәк итеп бирелгән рөшди [урта] кызлар мәктәбе һәм 1918 елга кадәр гамәлдә булган Мәгариф министрлыгы карамагындагы рус кызлар гимназиясе планнары алынды. Өч мәктәптә дә укыту вакыты сигез ел.

Укытылган фәннәр (гомум атналык сәгатьләр саны белән) [Махмутова, с. 228]

| Дәрес исемнәре | Бубый мәдрәсәсе (1910) | «Сөембикә» (1914) | Рус кызлар гимназиясе |
|---|---|---|---|
| Дин гыйлеме | 33 | 48 | 16 |
| Татар теле һәм әдәбияты | 54 | 45 | — |
| Рус теле һәм әдәбияты | 36 | 30 | 23 |
| Математика | 27 | 20 | 23 |
| Тарих | 10 | 16 | 12 |
| География | 7 | 8 | 10 |
| Табигать белеме | 10 | 8 | 12 |
| Гарәп теле | 16 | 10 | — |
| Педагогика һәм методика | 4 | 4 | 5 |
| Каллиграфия | 11 | 11 | 6 |
| Рәсем | 9 | 4 | 14 (факульт.) |
| Гигиена | 3 | 2 | — |
| Идарәи бәйтия | 3 | 2 | — |
| Кул эшләре | 5 | 7 | 9 |
| Алман теле | — | — | 26 (факульт.) |
| Француз теле | факультатив | — | 26 (факульт.) |
| Атналык сәгатьләр | 228 | 215 | 182 |

Беренче ике графага кертелгән фәннәрне чагыштыру ике уку планының бер-берсенә охшашлыгын күрсәтә. Беренче һәм өченче графалардагы мәгълүмат шулай ук бу ике планның да гомуми сыйфатлары булуын күрсәтә. Ике уку йорты да кызларны мөгаллимәлеккә дә, яхшы йорт хуҗабикәсе һәм ана булырга да әзерләгән. Бубый мәктәбе уку планыннан, таблицага кертелгән башка планнардагы кебек, берничә телне һәм кызлар мәктәбенә хас фәннәрне өйрәтүдән тыш, кызларга киң белем һәм төпле тәрбия бирергә тырышу сизелә. Бу төгәл фәннәрне мөмкин кадәр тулырак бирүдән дә күренә. Бу безгә әле тернәкләнеп кенә килгән Бубый кызлар мәктәбенең, дәвамлы булган очракта, Русиядә иң алдынгылардан саналган рус кызлар гимназиясе белән чагыштырганда да, шактый алга китүен фаразларга мөмкинлек бирә. Әгәр дә патша хакимияте Бубыйларның эшчәнлеген шул кадәр тупас рәвештә бүлдермәгән булса, татар яшьләрен укыту эше нинди югарылыкларга күтәрелер иде дип, көрсенергә генә кала!..

Кайгы һәрвакытта көтмәгәндә килә. Бубыйлар гаиләсенә генә түгел, барлык тирә-юньгә, юк, бөтен татар халкына ул 1911 елның 30 гыйнварына каршы төндә жандарм ротмистры Будогоский җитәкчелегендәге йөзләгән полиция стражниклары белән бергә килгән. Өч көн, өч төн буена авылда тентүләр һәм сорау алулар барган, агалы-энеле Бубыйлар һәм ирләр мәдрәсәсе мөгаллимнәрен кулга алганнар һәм Сарапул төрмәсенә алып киткәннәр... Ирләр мәктәпләре комплексы тулысынча ябылган. Иж-Бубый мәгърифәт учагын тар-мар итү шулай башланган.

Бубыйлар гаиләсе өчен кайгылы көннәр килгән. Бар авырлык һәм, иң йөрәккә үткәне, билгесезлек авылда калган хатын-кызлар җилкәсенә төшкән. Бу каһарман хатын-кызлар билгесезлек шартларында да төшенкелеккә бирелмәгәннәр, бар авырлыкны үз җилкәләренә алганнар. Үрнәкне әниләре Бәдрелбәнат абыстай күрсәткән. Мөхлисә ханым һәм аның ярдәмчеләре кызлар мәдрәсәсен саклап калу өчен бар көчләрен, бар тырышлыкларын куйганнар. Җирле хакимият, төрле куркыту чаралары кулланып, бу уку йортын да яптырырга тырышкан. Авылда, әгәр Бубыйлар кызлар мәдрәсәсен үз теләкләре белән таратмасалар, гаиләнең хатын-кызларын да төрмәгә илтеп ябачаклар, дигән имеш-мимешләр йөри башлаган. Бу имеш-мимешләр үзләре генә калган гаилә хатын-кызларын да, мөгаллимәләрне дә пошаманга салган.

Хакимият әһелләре «кызлар мәктәбен сүз белән куркытып яптыртмакчы булганнар иде. «Безнең кыз кардәшебез Мөхлисә Бубый белән безнең җәмәгатьләребез бу хосуста киңәш өчен безнең янга төрмәгә килделәр. «Ни эшлибез? Кызлар мәктәбен дәвам кылдырсак, безне дә ябарлар дип куркыталар». Без әйттек: «Яман исем белән мәктәп ябудан яхшы исем белән төрмәгә ябылу артыграк». Шуннан соң алар, безнең сүз белән канәгатьләнеп, ныгып киттеләр, кызлар мәктәбе дә Вятка директорының 1912 елда 18 гыйнварда 47 номердагы әмере белән ябылды, сүнде. Бубыйның ирләр һәм кызлар мәктәбе заманында тантана белән дәвам кылды, мөкатдәс хезмәтләрен итте, ябылган вакытта да безнең тарафтан бер гаеп белән түгел, бәлки залим хөкүмәтнең золымы, әмере белән, безгә шәрәф бер ябылу белән ябылды» [Бубый, б. 94—95], — дип тас-

вирлап калдырган Габдулла Бубый бу вакыйгаларны.

1912 елның көзеннән Мөхлисә абыстай Уралда, Троицк шәһәрендә кызларны укыта башлаган. Ул монда Бубыйларның фикердәше, татар милли хәрәкәтенең актив әгъзасы Габдрахман Әхмәрев чакыруы белән күчеп килгән һәм аның тарафыннан 1910 елда ачылган кызлар башлангыч мәктәбен Бубый мәдрәсәсе үрнәгендә үзгәртү эшенә тотынган. Бу эшнең күпме чыгым таләп иткәнен яхшы белгән Мөхлисә абыстай шул ук вакытта Троицкиның атаклы сәүдәгәрләре Яушевларны эшне үз кулларына алырга, кызлар өчен мәдрәсә яки дарелмөгаллимәт ачарга үгетләгән. Һәм морадына ирешкән: 1914 елда Яушевлар нәселенең бер тармагы кызлар мәдрәсәсе ачкан, ә бер елдан соң икенче тармагы, Петербургтан рәсми рөхсәт алып, мөгаллимәләр әзерләү өчен семинариягә (дарелмөгаллимәткә) нигез салган. Мөхлисә Бубый бу уку йортының мөдире итеп билгеләнгән.

Троицкида кызларны укытуны Бубыйдагы югарылыкка җиткерү өчен Мөхлисә абыстай бар мөмкинлекләрдән дә файдаланырга тырышкан. Бу елларда Троицкиның, мәгариф учагы буларак, даны барлык татар дөньясына таралуында да аның роле аз булмагандыр. Төрле мәҗлесләрдә, мәктәптә уздырылган кичәләрдә ул ялкынлы чыгышлар ясаган, үгет-нәсыйхәт кылган. Бу хакта аның Яушевлар мәктәпләрен рәсми рәвештә ачу тантаналарында сөйләгән нотыклары да ачык сөйли. Шул нотыкларның берсен мәкалә азагында укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

Мөхлисә Бубыйның тормышы 1917 елда Беренче Бөтенрусия мөселман съездында тагын бер тапкыр кискен үзгәреш алган. 1917 елның 1—11 маенда Мәскәүдә эшләгән бу корылтайда, Россия мөселманнары тормышында беренче мәртәбә буларак, делегатлар үзләре мөфти һәм дин эшләре үзәк идарәсенә алты әгъза — казыйлар сайлап куйганнар. Ул гына да түгел! Көн үзәгенең тагын бер мөһим соравы — хатын-кыз мәсьәләсен дә тикшерә корылтай, һәм, шәригать хатын-кызларны ирләргә тиң таба, димәк, мөслимәләрнең дә Дини идарәдә үз вәкиле булырга тиеш, дигән карарга килә. Сайлау барышында казыя хезмәтенә тәкъдим ителгән өч мөслимә (Фәхрелбәнат Акчурина, Мөхлисә Бубый һәм Мәрьям Паташова) арасыннан иң күп тавыш белән (307 делегат аны яклап, 280 — аңа каршы) съезд эшенә катнашмаган Мөхлисә Бубый казыя итеп сайланган. Бу хәлне анализлап, «Сөембикә» журналының нашире һәм мөхәррире Якуб Хәлили түбәндәге сүзләрне язган: «Идарәи диниягә биш казыйның берсе хатыннардан сайланды. Без ислам галәмендә мөслимә казыяның барлыгын белмибез. Ислам мәмләкәте булган Төркиядә дә хатыннардан казыя барлыгын ишеткәнебез юк. Менә бу, мөслимә казыя сайланып куелу, хатыннар съезды, хатыннар тавышының тәэсире белән булган эштер. Менә бу гамәлдә үк хиҗапның беткәнлеген, ир белән хатынның эштә, хокукта тигезлеген күрсәткән бер фактты» [Сөембикә, б. 277].

Гомеренең Троицк чорын тәмамлап, 1917 елның җәендә Мөхлисә Бубый Уфага күченгән. «Вакыт» газетасының 11 июнь санында казыйларның Уфага килеп җитүе, мөфти һәм М. Бубыйның да шушы арада күтелүе хакында бирелгән хәбәрдә: «Мәхкәмәи шәргыягә гариза биреп мөгаллимәлеккә имтихан кылыныр-

га сораучы туташлар да булгалап тора. Ләкин илтимаслары [үтенечләре] үтәлмәенчә тора. Ихтимал, Мөхлисә ханым килгәч, имтихан кыла башларлар», — дигән сүзләр игътибарны җәлеп итә.

Мәхкәмәи шәргыяда казыя вазифасын М. Бубый 19 июньнән башкарырга керешкән. Хатын-кызларның хокукларын яклаучы казыяның беренче адымнары да бик табигый булган: эшен ул мөслимәләргә мөрәҗәгать әзерләүдән башлаган. Күпхатынлылык мәсьәләсен хәл итүне Казанда узган II мөселман корылтае Мәхкәмәи шәргыя карамагында калдырган булган. «Шушы мөнәсәбәт белән казыя Мөхлисә Бубый, ханым вә туташларны икенче хатынлыкка бармаска өндәп, бер хитапнамә таратты, — дип язган Я. Хәлили. — Соңгы көннәрдә идарәи диния тарафыннан күп хатын алуны берничә шартлар тәхетенә алган «карарнамә» таратылды». Бу «Бердән артык хатын алу хакында карарнамә»нең авторы да Мөхлисә Бубый булган. Мөфти һәм барлык казыйлар имзасы белән ул матбугатта да басылган [Сөембикә, б. 270—280].

Мәхкәмәи шәргыяда эшне башлап җибәргән көннәрдә үк Мөхлисә Бубый Уфада дәүләти рус гимназиясенең хокукларына ия булган һәм укыту программасы да русныкына тәңгәл килгән милли татар гимназиясе ачу эшенә дә актив катнашкан. «Тормыш»ның 1917 елгы 23 сентябрь, 27 октябрь һәм 7 ноябрь саннарында урнаштырылган хәбәрләрдән милли гимназиянең 15 октябрьдән эшли башлавы һәм анда 107 укучы булуы аңлашыла. Укытуны ике телдә — татар һәм рус телләрендә — махсус белемле укытучылар алып барган. Мөгаллимнәр арасында без Мөхлисә ханымны да күрәбез — ул дин дәресләрен алып барган. Моның татар тормышында тагын бер яңалык булуына игътибар итик: ир балаларга дин дәресләрен хатын-кыз укыта башлаган!

«Йолдыз» газетасының 1917 ел 26 июнендә урнаштырылган игъланнан без Мөхлисә Бубыйның тагын бер башлангычы хакында беләбез. «Уфадагы Госманов кызлар мәктәбе бу ел дарелмөгаллимәт исеме илә Габдулла Бубый тәхете нәзарәтендә [җитәкчелегендә] ачыла икән. Ул хакта казыя вә мөгаллимә Мөхлисә Бубый җәнаблары ошбуны игълан итә», — дип башланган хәбәр. «Дарелмөгаллимәткә кабул имтиханнары август 15 дә ачылып, август ахырына кадәр дәвам итәчәк. Беренче сыйныфка 6 сыйныф тәмам иткән туташлар имтихансыз кабул ителәчәкләр, ләкин хәзергә андый мәктәпләр булмаганлыктан, дарелмөгаллимәт янында әзерлек сыйныфлары ачыла һәм аңа ысулы җәдидә илә 4 сыйныф ибтидаи тәмам иткән кызлар кабул ителә. Килүчеләрнең, әгәр дә булса, ибтидаи бетергәнлеккә даир бирелгән шәһадәтнамәләрен алып килүләре лязим. Аның өстенә русча укыйяза белү, кыска вә ансат хикәяләрне сөйли алырлык булу лязим, — дип язылган Мөхлисә ханым исеменнән бирелгән игъланда. — Читтән килгән туташлар өчен дарелмөгаллимәт янында әмин [тыныч, ышанычлы] вә әхлакый тәҗрибә илә күрелгән назир вә назирәләр карамагында пансион ачыла. Мәктәпкә керү өчен сәнәви 35 сум хак алына. Тәхзирия [әзерлек] сыйныфына 12 яшьтән ким балалар кабул ителми».

Дарелмөгаллимәтне ачып, Бубыйлар гаиләсе, күрәсең, патша хакимияте тарафыннан ябылган мәшһүр Бубый кызлар мәдрәсәсен яңа

урында торгызырга уйлаганнар. Әгәр дә бу идея тормышка ашса, Бубыйлар, яңадан барысы бер урынга җыелып, яңа шартларда мөгаллимәләр әзерләү эшен дәвам итмәкче булганнар, дип фаразларга да мөмкин. Ләкин дарелмөгаллимәт ачылмаган. Габдулла Бубый Троицкига эшкә киткән, ә Уфада төпләнгән Мөхлисә һәм Гобәйдулла Бубыйлар татар милли хәрәкәтенең нәкъ үзәгенә эләккәннәр.

Татарларның сәяси-иҗтимагый тормышы 1917—1918 елларда, һичшиксез, Милләт мәҗлесенең эшчәнлегенә бәйләп каралырга тиеш. Яңа чорда татар халкының парламент тибындагы оешмасы булган Милләт мәҗлесе өч нәзараттән торган Милли идарә, ягъни башкарма комитет ролен үтәгән орган да сайлаган. Мөхлисә Бубый диния нәзарәте әгъзасы, ә аның абыйсы Гобәйдулла — малия [финанс] нәзарәте әгъзасы итеп сайланганнар. Сайлаулар бик җитди үткәнен раслаучы мондый дәлил китерергә була: нәзарәт әгъзалары ике «иләк» [ябык тавыш бирү] аша үткән — башта кандидатлар исемлегенә кертелү өчен күпчелек тавыш җыярга кирәк булган һәм шуннан соң гына алар нәзарәткә сайлау исемлегенә кертелгәннәр. Мөхлисә Бубыйның ике баскычны да уңышлы үтүен саннар күрсәтә. Ул сайланучылар арасында өченче урынга чыккан. Иң күп тавыш Р. Фәхретдингә (исемлеккә керткәндә 65, сайлау барышында 76 — яклап һәм 10 тавыш каршы) бирелсә, икенче урында С. Урманов (64/64 — 12), ә өченчедә М. Бубый (51/60 — 16) була. Мәшһүр мөдәррис һәм дин белгече Зыяэддин Камали, мәсәлән, шул ук вакытта исемлеккә кертелгәндә 35 тавыш кына җыйган була (ә сайлаулар барышында аннан да азрак).

Гражданнар сугышы елларында, бигрәк тә Уфа шәһәре кулдан-кулга күчеп торган чакта, Мөхлисә Бубыйның нинди позициядә булуы анык кына мәгълүм түгел. Аның 1918—1919 елларда Уфада булуы гына билгеле. Шулай да ул мөмкинлеге булган кадәр дини идарәдә үз эшен башкарырга тырышкандыр, дип фаразлый алабыз. Дини идарә әгъзаларының иң абруйлы өч казые — Р. Фәхретдин, К. Тәрҗемани һәм М. Бубый — Колчак армиясе белән бергә китмәгән, Уфада калганнар. Бу адымнары аларга соңрак Дини идарәне милли оешма буларак саклап калырга ярдәм иткәндер, дип фаразлыйсы килә. Аларның бу адымы үзләренең дәһрилеге белән горурланучы комиссарларга Дини идарәне юкка чыгарырга комачаулагандыр, дигән нәтиҗә ясарга да мөмкинлек бирә.

Төбәктә Советлар хакимияте ныгый барган чорда мөфтият әгъзаларына аның эшчәнлеген оештыру, яңа шартларга яраклашу кебек җитди мәсьәләләрне чишү кирәк булганы көн кебек ачык. Яңа вазгыять шартларында да халыкның дини һәм рухи тормышы белән җитәкчелекне оештыруны үз өстенә алырга өметләнеп, мөфтият руханилар съездларын уздырган, имам-мөхтәсибләргә тиешле киңәш-күрсәтмәләр биргән, халыкның уй-фикерләре белән танышкан. Эшнең шулай булуын 1920 елның 16—25 сентябрендә узган съездда каралган мәсьәләләр дә раслый: Дини идарәнең башкарылган эшләр хакында отчеты, Дини идарәнең һәм мөхтәсибләрнең эш күләмен һәм бурычларын билгеләү, мәхәлләләрне оештыру һәм руханиларның матди хәле хакында сөйләшү, мәхәлләләрдә эшләү өчен рухани кадрлар

әзерләү, мөселманнарга дини тәрбия һәм белем бирү, Совет хакимиятенең дингә карата чыгарылган декретлары белән танышу, Дини идарәнең яңа составын сайлау һ.б. [Баруди, с. 123—124]. Съездны әзерләүдә Мөхлисә абыстайның өлеше дә шактый.

Гомумән, бөтен көчен мөфтият эшенә җиккән М. Бубый казыйлар арасында югалып калмаган, дин белгече буларак, тиз арада халык алдында абруй һәм дан казанган. Аның белеме, гаделлеге, намуслылыгы, ярдәмчеллеге хакында халык арасында риваятьләр таралган. Изелгән, җәберләнгән йөзләгән хатын-кыз, яклау һәм гаделлек эзләп, төрле төбәкләрдән Уфага, казыя янына агылган. Һәм аларның һәркайсы монда ачык ишек, якты йөз, аңлау һәм ярдәм тапкан. 1920, 1923 һәм 1926 елгы руханилар съездларында Мөхлисә ханымның кабат казыя итеп сайлануы да бу хакта сөйли. Ул егерме ел буена бу авыр һәм катлаулы эшне башкарган, мөфтиләрнең, бигрәк тә Р. Фәхретдиннең, ышанычлы ярдәмчесе булган.

Мөхлисә Бубыйның Дини идарәдә нинди эшләр белән мәшгуль булуын соңгы елларда «Гасырлар авазы» журналында басылган материаллардан белеп була. Беренче елларда ул идарәнең гаилә бүлеген җитәкләгән булса, соңрак Дини идарәнең сәркатибы вазыйфасын үтәгән. «Гаилә бүлегендә эшләдем, ягъни гаилә-көнкүреш мәсьәләләрен тәртипкә салырга тырыштым, мөфтият билгеләгән юнәлешне алып бардым, күпхатынлылык белән көрәштем, хатын-кызлар арасында аларның ирләр белән тигез хокуклылыгы хакында аңлату эшләре алып бардым. Октябрь революциясе көннәрендә һәм аннан соң да Дини идарәдә булдым» [Рахимов, с. 221], — дип җавап биргән эшләгән эшләре хакында Мөхлисә Бубый тикшерүчеләргә, 1930 елның 21 сентябрендә беренче тапкыр хөкемгә тартылгач.

Мөхлисә Бубый җитәкләгән бүлекнең эшләре Эчке Русия һәм Себер мөселман руханиларының 1926 ел азагында узган III съезд материалларында да чагылыш тапкан. «Бүлек башкарган эшләр:
1. Метрика кенәгәләрен алып бару.
2. Гаилә эшләрен тәртипкә салу.
3. Исламга тарту эшләрен башкару.
4. Фәтвалар әзерләү.
5. Протокол дәфтәрен алып бару.
6. Төрле рәсми кәгазьләрне теркәү һәм тарату.
7. Рәсми кәгазьләрне тикшерү һәм бүлекләргә юнәлтү.
8. Китапханә эшләрен тәртипкә салу» [Багавиева, с. 107—118], — дип күрсәтелгән.

1924—1927 елларда Дини идарә «Ислам мәҗәлләсе» исемле журнал нәшер иткән. Мөхлисә ханым анда мәкаләләр белән дә катнашкан, төрле дини мәсьәләләргә кагылышлы фәтвалар да язган, бәхәсле гаилә мәсьәләләрен хәл иткәндә хөкемдар да булган. Аның моннан сиксән ел элек басылган мәкаләләрендәге фикерләре бүген дә үзенең актуальлеген югалтмаган.

XX гасырның егерменче-утызынчы елларында татар зыялыларына кагылган эзәрлекләүләр Дини идарәдә хезмәтен дәвам иткән Мөхлисә ханымны да, өлкән яшьтә булуына карамастан, читләтеп үтмәгән. НКВД органнары тикшерүчеләре алдына ул 1930 елның 21 сентябрендә беренче мәртәбә килеп баскан. Бу көнне аны, Җинаять кодексының 59 статьясы буенча, алтын акча һәм кыйммәтле әйберләрне законсыз саклауда гаепләп, сорау алуга тартканнар. Мөхлисә ханымның

Мәккәгә хаҗ кылу ниятеннән җыеп килгән барлык «байлыгы» тартып алынган. Шулай да бу юлы ул үзе иректә калган. Икенче юлы Мөхлисә ханым, 1930 елдагы кебек, «җиңел генә» котыла алмаган...

«1937 елның ноябрь башында НКВД дәүләт иминияте идарәсе бүлекләренең берсендә Башкортстан буенча яшерен белешмә әзерләнгән. «Бобинская контрреволюцион буржуаз-милләтчел баш күтәрүчеләр оешмасында катнаша. Ул актив рәвештә контрреволюцион милләтчелек эшен алып бара, контрреволюцион оешманы чит ил разведкалары белән бәйләп тора... Бобинская кулга алынырга һәм РСФСР җинаять кодексының 58 статьясының 2, 6, 10, 11 маддәләре буенча җавапка тартылырга тиеш», — дип күрсәтелгән була анда. «Төрмә камерасының ишекләре аның алдында инде ачылган, язмышы да алдан билгеләнгән була», — дип яза Мөхлисә Бубыйның тикшерү эше материалларын әзерләп «Гасырлар авазы» журналында бастырган С. Рәхимов (2000, № 1—2).

Мөхлисә Бубыйдан «сорау алу протоколлары, мәгълүмати яктан караганда, бик ярлы. Үзенә ягылган барлык коточкыч гаепләрне ул катгый рәвештә кире каккан. Сорау алуларда Мөхлисә үзен кыю һәм горур тоткан, аның авызыннан бер исем дә чыкмаган. Ләкин Казан, Уфа, Мәскәү, Ташкент, Баку һ.б. шәһәрләрдә кулга алынган һәм хөкемгә тартылган башка кешеләрнең күпсанлы протоколларында аның намуслы исеменә нинди генә нахак гаепләр ягылмаган. СССР мөселманнары арасында М. Бобинская шул кадәр билгеле һәм абруйлы шәхес булган ки, тикшерүчеләр, үзләренең чираттагы канлы «детектив»ларын ышандырырлыграк нигезләр өчен мөселманнарның үзәк дини идарә секретаре М. Бобинскаяны «баш күтәрүчеләрнең контрреволюцион оешмасы»н оештыручыларның берсе итеп күрсәткәннәр», — дип ассызыклый автор.

Бу бәяләмәнең дөреслеген С. Рәхимов әзерләп бастырган сорау алу материаллары раслый. Шулардан ике өзек.

1) 1937 елның 21 ноябрендә теркәлгән беркетмәдән: «*Сорау*: Уфа шәһәрендә яшәүче барлык танышларыгызны санап чыгыгыз.

*Җавап:* Минем Уфада бер танышым да юк. Минем фатирыма беркем дә килми, үзем дә беркемгә дә йөрмим. Мин бары тик Идарәгә мәхәлләләрдән акча алып килгән муллалар белән генә Идарә бинасында очрашкалыйм. Мин секретарь вазыйфасын башкарганга, алар миңа акча тапшыралар. Бу муллаларның беркайчан да минем фатирымда булганнары юк. Башка беркем белән дә Уфада нинди булса да элемтәдә тормыйм».

2) 1937 елның 28 ноябрендә язылган беркетмәдән: «*Сорау*: Сез буржуаз-милләтчел баш күтәрүчеләр оешмасында катнашасыз. Тикшерү органнарына сезнең бөтен контрреволюцион эшчәнлегегез билгеле. Сезгә бу сорау буенча мәгълүмат бирергә тәкъдим итәбез.

*Җавап:* Мин бернинди контрреволюцион оешмада катнашмадым һәм катнашмыйм.

Протокол минем сүзләр буенча дөрес язылган. Аны укып чыктым һәм имзам белән раслыйм»...

* * *

Егерме елдан артык гомерен Русия мөслимәләре арасында мәгърифәт таратуга багышлаган сәләтле

педагог, тагын шул кадәр үк гомерен Русия мөселманнарының үзәк дини идарәсендә эшкә биргән абруйлы казыя, Мөхлисә ханым Бубый 1937 елның 30 ноябрендә Башкортстан АССР НКВД сы «өчлеге» утырышында «Башкортстанда контрреволюцион баш күтәрүче милләтчеләр оешмасы»нда катнашуда гаепләнгән һәм атарга хөкем ителгән. 68 яшьлек Мөхлисә абыстай һәм тагын алты мөселман рухание 1937 елның 23 декабрендә атылганнар. Башкортстан АССР Югары суды президиумының 1960 ел 23 май карары белән аларның барысы да гаепсез дип табылган һәм акланган.

Менә бу искиткеч ханым — Мөхлисә Габделгалләм кызы Бубый, ир туганнары кебек үк, үзенең фидакарь хезмәтен халкына, аны агартуга багышлаган шәхес. Гомумән, тормыш Бубыйлар гаиләсенә, илгә нинди генә сынаулар алып килсә дә, Мөхлисә ханым төшенкелеккә бирелмәгән, яшьлегендә сайлаган юлдан тайпылмаган, соңгы сулышына кадәр бөек максатына тугры булып калган. Бу фидакарьлекне ничек аңлатырга соң? Мөхлисә Бубый шәхесенең үзенчәлекләре беләнме? Яки моны татар җәдидчелегенең бер күренеше буларак кабул итәргәме? Революцияләр шартларында яңа җәмгыять, яңа дәүләт төзү хыялы белән яшәгән, җәдидчелек идеалларын тормышка ашырырга тырышкан барлык фидакарьләр дә аңа ошаганмы? Сораулар, сораулар... Ничек кенә булмасын, безгә Мөхлисә ханым кебек шәхесләр, аларның якты истәлеге алдында баш ияргә генә кала.

**Троицкида, Яушевларның кызлар мәктәбе рәсме кәшадында** [ачу, ачылу]
**Мөхлисә Бубый тарафыннан сөйләнгән нотык**

*1914 ел, 7 август*

Хөрмәтле ханым вә туташлар!

Менә, Аллага шөкер, минем ничә елдан бирле көтдегем бу яхшы мәктәп тә вөҗүдкә килеп чыкты. Милләтебезнең алга китүе, милләтебезнең башка милләтләр арасында кадерле вә хөрмәтле булуы, милләтебезнең һәрбер җиргә кереп чыгуы, вә һәрбер урында сүзе үтүе, бездән туган балаларның җәсүр [гайрәтле, кыю], миллиятне сөяр, вә һәрбер шәйдән хәбәрдар булып җитешүләрендә күренгәнлектән, вә боларның болай җитешүләре, безнең хатын-кызларыбызның уку-тәрбияләре, гыйлем вә мәгърифәтләре белән кулга кул тотаклашып бардыкларыннан, безгә милләтебезне саклау тарафыннан иң лязим вә динебезне куәтләү тарафыннан иң фарыз булган нәрсә, хатын-кызларыбызны укыту вә аларны голүм вә мәгариф белән зиннәтләү икәнлегендә бүген һичкемнең шөбһәсе булырга тиеш түгел. Безнең балаларыбызның тәрбияләре ким, әхлаклары начар, куәт вә җәсарәтләре [батырлык] юк, дин вә миллиятләре зәгыйфь буладыр; менә без — аларның аналары — голүм вә мәгарифтән ялангач, әхлак вә тәрбиядән мәхрүм, дин вә диянәттән хәбәрсез булдыгымыз өчен. Бала бит, һәркемгә дә мәгълүм, аталар кулында түгел, аналар кулында үсә, алар кочагында тәрбияләнә, алардан һәрбер төрле гадәтне вә һәрбер төрле әхлак вә диянәтне ала, шулай итеп, анасының күзгә күренгән бер охшашы була да китә. Аталар көне буенча тышта, кәсептә, эштә йөреп тордыкларыннан, аларның ба-

ла тәрбиясендә бер эшләре дә юк. Аларның бик күбесе балаларын, хәтта хатынын, бер мәртәбә генә булсын, аш янында күрү сәгадәтеннән дә мәхрүм калалар. Шуңа күрә аларга, кая балаларын тәрбия дә, кая үзләренең холык вә гадәтләрен аларга йоктыру!..

Аналарның эшләре бөтенләй башка: алар һәрвакыт өйдә, һәрвакыт баланың янында, һәрвакыт аны карауда, тәрбиядә. Әгәр без кызларыбызны укытмасак, әгәр без аларны дин вә диянәт белән, голүм вә мәгариф белән зиннәтләмәсәк, рухландырмасак, ул вакытта алар, үз кулларына Алла тарафыннан әманәт тапшырылган ул мәгъсүм балаларны, нидәен туры дин вә диянәт белән тәрбияләсеннәр дә, нидәен яхшы әхлак вә гадәтләр биреп үстерсеннәр!..

Үзеңнең дин вә диянәттән хәбәрең булмаса, үзеңнең яхшы әхлак вә яхшы гадәтләрдән нисабың [нигез, башлангыч], мәгълүматың юк икән, ул вакытта ничек итеп балаларны яхшы юл, вә тугры, вә ышанычлы бер максат астында тәрбия кылмак кирәк?!.

Тәрбияле, дин вә диянәтле, дөньядан һәм ахирәттән хәбәрдар аналар кулында үскән балалар, шөбһә юк, мөгаен, тәрбияле үсәр, динедиянәте җирендә, әхлагы яхшы, хиссияте миллиясе мөкәммәл булыр, «әгузе» белән «бисмилла»ны бәләкәеннән төзек өйрәнер, Аллаһның берлеген вә Мөхәммәд галәйһевәссәләмнең рисаләтен [пәйгамбәрлеген] бәләкәеннән белеп үсәр, яхшылыкның яхшылыгын, яманлыкның яманлыгын бәләкәеннән аңлар: яман сүз сөйләмәс, начарлыктан качар, дinenә, миллиятенә тигән кешеләргә мокабәлә [каршы тору] нык лөзүмен [тиешлек] йөрәге типкән саен хис кылыр... Аллаһ белә, ул балалар кулыннан тагын ниләр-ниләр эшләмәгә мөмкин булмас...

Менә безнең милләтебезнең бәхете, сәгадәте әнә шундаен балалар кулында: шул балалар аркасында безнең милләт алга китәр; истикъбальнең киң ишекләре шул балалар аркылы, алар кулы белән ачылыр; бәхет вә дәүләт кошлары шул балалар иҗтиһады белән тотылыр; Аллаһының ниһаясе юк җәннәтләренә, хисабы юк рәхәт вә сәгадәтләренә шулар аркылы ирешелер.

Күрәсез: аналар кулында ниндәен зур куәтләр, вә ниндәен мөкаддәс вазыйфалар бар. Балаларыбызны гыйлем, мәгърифәт даирәсендә тәрбияләп, милләтебезне киң сәгадәт ишекләреннән кертү дә безнең кулыбызда; аларны мондаен бер тәрбиядән мәхрүм куеп, милләтебезне сәфаләт [хурлык, түбәнлек] чокырларында, бәхетсезлек эчләрендә батыру да безнең ихтыярыбызда. Шуңа күрә пәйгамбәр саллаллаһу галәйһевәссәләм дә... [гарәп телендә китерелгән бу һәм алдагы аять һәм риваятьләр төшереп калдырылды] диеп, бу хакыйкатьне аңлаткан. Ягъни, «Оҗмах аналар аяклары астында, алар тәрбиясендә» дигән сүз. Ягъни, балаларыбызга яхшы тәрбия биреп, милләтебезне оҗмахлык кылучы да без; аларны тәрбиясез куеп, милләтебезне җәһәннәмгә, тәмугка кертүче дә без, хатыннар.

Алай булгач, күренеп тора: безгә, хатыннарга, ирләрдән артык уку, алардан артык гыйлем-мәгърифәт өйрәнү лязим икән. Менә шуны Яушев... [текстта шулай бирелгән] әфәнделәр белән... ханымлар аңладылар да, бу ел кызларга махсус менә бу мәдрәсәне, менә бу гыйлем йортын салдырдылар. Мин өмет итәм һәм ышанам, бу мәдрәсәдә укып чыккан тәрбияле кызлар белән якын

бер истикъбальда [киләчәк] бик тәрбияле балалар җитешер; аннан туган мәгариф кояшы бөтен ислам галәмен яктыртыр, җылытыр; шуның аркасында безнең милләтебез дә бу хурлык вә бу начар хәленнән котылыр; без дә, башка милләтләр белән бәрабәр, мәгариф, мәдәният, байлык мәйданнарында ярышырбыз.

Рәхмәт Муллагали әфәнде белән Мөхәммәтгали әфәнделәргә! Рәхмәт Хәдичә ханым белән Әсма ханымнарга!

Рәхмәт шушы кызлар мәктәбе өчен хәерхаһ булган, безнең хатын-кызларыбызны укыту юлында иҗтиһад иткән һәрбер кешегә!

Йа Рабби, син бу мәдрәсәне залим дошманнарның ерткыч тырнакларыннан үзең нык хафиз [саклаучы] вә химаяндә кыл! Кызларыбызга шушы мәдрәсә эчендә яхшы гыйлемлекләр, файдалы һөнәрләр өйрәнмәгә җиңеллек бир! Коткар безне бу наданлык вә бу сәфаләтләрдән! Коткар безне бу мескенлек вә бу хурлыклардан! Яшәт безнең милләтебезне, мәсгуд ит! Яшәт безне, йа Рабби, яшәт безнең шушы хөрмәтле, сөекле милләтебезне!

*Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кульъязма һәм сирәк китаплар бүлеге. № 208т. Т. 2. Б. 204а —206б.*

**Ислам дөньясында хатыннар**

Бу кадәр күп еллардан бирле ислам диненең сәламәт сакланып торуында вә һич үзгәрми вә имгәнми безләргә килеп җитүендә ирләрнең зур хезмәтләре булды. Монда шөбһә юк. Мондый ирләр берлә бу көнге ислам дөньясының ифтихар кылуы [горурлану], әлбәттә, урынлы. Ләкин ислам диненең дәвам итүе вә дөньяга җәелүе хакында ирләр берлә бер сафта торып хезмәт итүче хатыннар да булды. Болар берлә дә ифтихар кылу урынсыз түгел.

Рисаләт вазыйфасын йөкләве сәбәпле, кавем-кабиләсе хәтта бәгъзе бер мәхрәм [якын] карендәшләре тарафыннан кимсетелгән вә арадан чыгарылган рәсулуллаһ хәзрәтләре гакыллы вә гафиф [саф, пакь], сабырлы вә ләтыйф [гүзәл, мөлаем] булган хатыны хәзрәти Хәдичәнең әсәрле вә мәгънәле тәслияләре [юату] берлә юанадыр вә үзенең вазыйфасын үтәү тугрысында моның ярдәме вә моның булышлыгы берлә файдаланадыр иде.

...Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы ихтыяҗга карап йөри. Дөньяда шундый урыннар вә шундый вакытлар була — башка бер урында вә башка бер заманда санга алынмый торган бер хезмәт бик кирәкле вә бик файдалы булып чыгадыр.

Безнең шушы өлкәбездә вә шушы көннәребездә хатыннарга йөкләнә торган авыр түгел, әмма үзләре бик кирәкле вә файдалы хезмәтләр бар. Шул хезмәтләрне итү алар өстенә төшкән бер бурыч. Әмма бурычны түләү чиксез рәвештә садакалар өләшүгә күрә дә файдалы вә савaплы булуында шөбһә юк.

Ул бурычлардан берсе — үзебезнең дини гадәтләребезне вә мәрасимнәребезне [рәсмиләшкән гадәтләр, йолалар] саклаудыр.

Үзебезнең дини бәйрәм көннәребезне, җомга, динебездәге ел башы һәм дә мәүлед көннәрен гаилә башлыгы булган хатыннар вакытларыннан элек белеп торырга, көч җиткән кадәр шул вакытларда өй эчендә

булганнарның күңелләрен ачарлык итеп иркенлек бирергә кирәк буладыр. Моның өчен зур мәсрафлар [чыгым] хаҗәт түгел...

Ул бурычлардан икенчесе — тел саклау. Бу көн безнең юлга салынган вә дөньяви йомышларын гына түгел, хәтта дин вә гыйлем тугрысындагы йомышларыбызны үтәрлек үз арабызда куллана торган телебез бар.

Гәрчә арада читләрдән кергән сүзләр күп булса да, ул сүзләр инде үз малыбыз булып киткән, төркичә булып саналу тиешле күрелгән.

Димәк, бик яхшы вә җитеш телебез бар. Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торырлык түгел. Эш шулай була торып, авылларда кирәгеннән артык, хәтта бөтенләй кирәкми вә килешми торган урыннарда рус сүзе истигъмаль ителенә башлаганлыгы күреләдер.

Бер кеше: «Дим буенда «...» авылында булдым. Рус мәктәпләрендә укып чыккан ике яшь егет озын вакыт сөйләшеп утырдылар. Сүзләре бөтенләй нур кичә дисәм, урынлы. Шул урында ике авыл агаеның сөйләшеп утырганда ватып-җимереп катнаштырган русча сүзләре өчтән бере булды дисәм, арттырып сөйләү булмас», — диде.

Халкыбыз русча белсен, кулыннан килсә, башка телләр берлә дә ашна булсын, белү бик кирәк, әмма үз сүзебез арасына урынлы-урынсыз, кирәкле-кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми.

Мондый эш үз телебез юлга салынмастан борын ярыйдыр иде, хәтта инде үз ана теле мәктәпләрдә генә түгел, хөкем йортларында вә хөкүмәт даирәләрендә рәсми вә кануный тел булып йөртелә башлады.

Инде бик тәртипле телебез бар. Моннан соң бу эш ярамый.

Үзенең өендә бик күп русча сүз катнаштырып сөйләп тә, руска йомышы төшкәч, тылмач аркылы сөйләү һөнәр булмаса кирәк.

Бу көнге безнең бу өлкәдәге, бигрәк тә башкорт хатыннарының беренче вазыйфалары — үзләренең ана телләрен саклау, оныттырмау, өй эчендә тел хуҗасы булып торудыр. Бу хезмәт аның өчен авыр түгел.

Дөньяда булган һәр төрле кавемнәрнең телләрен саклаучылар шул кавемнәрнең аналары вә телләре булган хәлдә, безнең халкыбызның телләрен саклаучылар да үзләренең аналары вә хатыннары булырга тиешле. Безнең халкыбызның аналары, хатыннары зирәклек вә һиммәт тугрысында башкалардан ким түгел.

*Мөхлисә Бубый.*
*Ислам мәҗәлләсе. 1924. № 1. Б. 28—30.*

**Хатын-кызларга гаид** [караган, бәйләнешле]

Хөрмәтле җенестәшләрем хатын-кызларга каратып берничә сүз.

Аллаһы тәгаләнең җир йөзендә яраткан һәм җир йөзенә хуҗа булган кешеләренең яртысы хатын-кызлардыр. Шул сәбәпле мин гаҗизә җенестәшләремә карап, әхлакый вазыйфалардан берничә генә сүз сөйләп узуны үземә бурыч санаймын.

Кешеләрнең чын мәгънәсе илә кеше булулары күркәм холык сәбәбеннән булуы һәркемгә мәгълүм. Күркәм холыклы булу кешенең үзенә йөкләнгән бер мөкаддәс бурычтыр. Ягъни бер кеше әхлагын төзәтергә, күркәм холыклы булырга гайрәт итсә, шөбһәсез, тәрбияле вә әхлаклы була аладыр.

Күркәм холыкларның бүлемнәре күп. Ләкин мин монда гаилә төзү өчен хатын-кызларыбызга иң хаҗәт булганнарыннан берничәсен генә әйтеп узамын.

...Бу көндә бөтен җир йөзендәге милләтләрне тәфтиш итеп [тикшереп] карасак, һәрбере гаилә төзиләр вә гаиләви тормыш илә яшиләр, хайваннарча яшәгән милләт бер дә юк.

Гаилә төзү нәсел саклауга һәм адәмнәрнең бәхет вә сәгадәтле булуына иң куәтле сәбәп булганлыктан, безнең ислам динебез дә гаилә төзүгә зур кыйммәт бирәдер. Коръәни кәримдә һәм хәдисе шәрифләрдә ир, хатын, бала вә ата-аналар, вә кабиләләр хакында ачык бәян кылынган...

Гаиләләрнең төзек вә тәртипле булуы бөтен өммәтнең низамлы вә төзек булуына сәбәптер. Бер милләтнең урын тотуы һәм бәхет вә сәгадәтле булуы өчен ул милләтнең балалары вә гаиләләре тәрбияле булулары ляземдер.

Гаиләләрнең тәрбия вә әхлаксыз булулары милләтнең тамыры бозык вә черек булуга беренче сәбәптер, чөнки милләт шул гаиләләрдән төзелгән вә оешкандыр.

Гаилә дигән кечкенә оешма ир илә хатынның кушылуыннан (издиваҗыннан) башлана. Ир илә хатын хилкать [яратылыш] вә табигатьтә дә бер-беренә кушылырга мәҗбүрдер...

Кирәк ир, кирәк хатын булсын, өйләнмәй ялгыз торулары табигатькә муафыйк тормыш түгелдер... Гаилә тәшкил итү (өйләнү) кешенең яшәү тарихында бик зур алмашыну булганга, бик яхшы тикшереп вә уйлап эш йөртергә кирәк. Өйләнү кешенең гомерлек иптәшлеккә берәүне алуы, яхуд берәүнең баруы дигән сүз. Безнең ислам дине бу хакта ошбу биш төрле шартны ригая итәргә [игътибарга алу] кушкан:

1) ир илә хатын бер-беренә әхлак вә тәрбиядә муафыйк вә көфу [тиң, пар] булсын;
2) алачак иптәшен дә тәрбия итәрлек байлыгы вә икътисадый җитешлеге булсын;
3) боларның бере тәрбия җәһәтендә түбәнрәк булып чыкса, югарырак булганы түбәнрәк булганына күркәм юлдашлык итеп өйрәтергә тырышсын;
4) ир илә хатын яшь ягыннан бер-беренә якын булсын;
5) кушылачак ир илә хатын һәр икесе тышкы (төс) матурлыгыннан бигрәк, мәгънәви, рухани яктан булган (әдәп, тәрбия, хөсне әхлакый яктан булган) матурлыкларны алда тотарга кирәк. Төс никадәр матур булса да, әхлаксыз вә тәрбиясез иптәштә бер файда да юк... ир илә хатынның бер-беренә каршы әхлакый бурычларының иң кирәклесе дүрттер:
1) садакать (бер-берсенә ышанычлы булу). Иргә йортның тышында хезмәт кылып, гаиләсен туйдырырга тугры килгәне кеби, хатынга да йорт эчендә хезмәт кылып, гаиләдәге әгъзаларын тәрбияләргә тугры киләдер. Димәк, ир илә хатын бере йортның эчендә вә бере тышында хезмәт кыла. Бу вакытларда боларга бере-береннән ничә көннәр вә атналар аерылып торырга тугры килә. Менә ошбу вакытларда ир вә хатын һәр икесе берсе берсенә аз гына да хыянәт кылмавы, ир хатынын вә хатын ирен күңеленнән чыгармавы тиеш вә лязимдер. Әгәр ир илә хатын икесе бер әгъза булып, бере икенчесен кайгыртса, вә күңелләре дә бер булса, менә шул гаилә бәхет вә сәгадәтледер. Чөнки болай булганда, бере икенчесеннән аслан [һич, бер дә] шөбһәләнмәй, камилән бере-беренә ышана вә һәр икесенең дә җаннары рәхәт булып, мәхәббәт илә гомер кичерүгә сәбәп була. Әгәр дә боларның ара-

сында аз гына хыянәт булса, ир илә хатынның арасы бозылу вә салкынлануга сәбәп булып, бөтен гаиләнең бәхете вә сәгадәте җимерелә, чөнки никахның төп мәгънәсе дә бер-беренә садакатькә гаһед [килешү] алышудан гыйбарәттер;
2) әминият [ышаныч]. Ир илә хатын бере береннән камил әмин булырга кирәк, әгәр ир хатыннан, хатын ирдән әмин булмаса, арада бер төрле дә өлфәт [бердәмлек] вә мәхәббәт дигән нәрсә урнаша алмай, билгакес [киресенчә], ике арада төрле фетнәләр чыгуга вә гаилә бозылуга зур сәбәп була;
3) хәтер саклашу. Ир илә хатын һәрвакыт бер-берен ригая кылырга [игътибар итү] вә хәтерләрен калдырырлык бер кәлимә сүз вә бер эш кылмаска тиеш. Әгәр, Аллаһы сакласын, бере берен ригая кылмасалар вә хәтерләрен калдырырлык сүздә вә фигыльдә булсалар, ул вакыт гаилә тормышының тәме вә ләззәте китеп, ул гаиләнең рәхәте китәчәгендә шөбһә юктыр;
4) могавәнәт [ярдәмләшү]. Никах дигән гакыдның [сүз бирешү, килешү төзү] иң кадерле җимеше дә ир илә хатынның кай урында вә кай вакытта гына булса да, бер-беренә җиңеллек кылулары вә ярдәмләшүләредер. Әгәр ир хатын эшенә, хатын ир эшенә бер дә ярдәмләшмәй, бу минем эш түгел, дип торса, боларның арасында өлфәт вә мәхәббәт дигән нәрсәнең бөртеге дә булмас. Киресенчә, араларында гадавәт [дошманлык, нәфрәт] вә салкынлык заһир [пәйда] булыр.

Хатын илә ирнең берсенең икенчесе өстендә аерым бурычлары да бар. Ирнең хатынга эшләргә тиешле булган бурычлары. Табигать ягыннан ир хатыннан куәтле булып яратылган. Шуның өчен ирнең өстенә күп кенә авыр эшләр йөкләнә. Боларның берсе ир хатынының ашау-эчүен, кием-салымын, тора торган урынын тәэмин итәргә тиеш. Боларны эшләй алмаганда, шәрган вә низамән [шәригать буенча һәм рәсми рәвештә] өйләнүдә мәгънә юк.

Икенчесе: ир рафикасының [мәңгелек иптәшенең] намус вә вөҗүден [яшәеш] үз намусы вә үз вөҗүде кеби күреп сакларга, гүзәл нәсыйхәтләрдә булырга һәм Аллаһы тәгаләнең «Хатыннарга күркәм мөгамәләдә булыгыз!» дигән сүзен онытмаска тиеш. Дәхи дә Кәләме шәрифтә «Ирләр хатыннарның һәрбер әмерендә эш башкаручылардыр» диелгән. Чөнки бәдән куәте ягыннан ирләр хатыннардан артыктыр. (Нәзакәт вә хис ягыннан хатыннар ирләрдән артыграк) һәм дә хатыннарга нәфәка [алимент] бирү дә ирләр өстендәдер

Хатыннарның иргә эшләргә тиешле бурычлары.

1. Хатыннар ирләре табып китергән ашау, эчү вә башка кием вә йорт нәрсәләрен исраф кылмаска, ватмай вә чәчмәй саклап тотарга тиеш. Ирләрнең маңгай тирләре илә хезмәт кылып эшләп тапкан акча вә башка нәрсәләрен кирәксез кием-салымга вә башка бик хаҗәт булмаган урыннарга тоту хатыннарның нәзакәт вә тәрбиясезлеге саналып, идарәсез [йорт тота белмәгән] хатын хисапланадыр вә бу эш шәригать һәм халык кашында мәзмүм [начар, бозык күрелгән] бер сыйфат. Күбесенчә андый хатыннарның гомерләре фәкыйрь вә мохтаҗлыкта үтә вә бөтен гаиләне бәхетсез кылуга сәбәп буладыр. Матди яктан ир хатынның ярдәмчеседер. Ошбуларны уйлап, хатын да иренә чын иптәш булып, күңеле ирендә вә гаиләсендә генә булырга тиеш.

2. Ир илә хатын арасында аз гына өлфәт китү [салкынлык булу] илә аерылуны сорамаска кирәк, чөнки бу ае-

рылу гаять күңелсез фаҗигадер. Мондый вакытта ике араны төзәтерлек карендәшләргә мөрәҗәгать итәргә тиеш...

Менә минем җенестәшләрем хатын-кызларга карап әйтә торган нәсыйхәтләремнең бер кыйсеме ошбулардыр. Тәүфыйк Аллаһыдан.

Диния нәзарәтендә әгъза Мөхлисә Бубый.

*Ислам мәҗәлләсе. 1925. № 11—12, Б. 438—442.*

**Әдәбият**


*Баруди Г.* Памятная книжка (Хәтер дәфтәре). Казань: Иман, 2000.

*Бубый Г.* Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы // Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кулъязма һәм сирәк китаплар бүлеге. № 207т.

*Рахимов С.* Виновной себя не признала // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2000. № 1—2.

*Махмутова А.Х.* Лишь тебе, народ, служенье! Казань: Магариф, 2003.

*Багавиева С.* Религия ваша осталась только в вашей воле // Гасырлар авазы=Эхо веков. 1999. № 1—2.

Сөембикә. 1917. № 18. Б. 270—280.



***Мәхмүтова Альта Хаҗи кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 94

***А.М. Ахунов***

# 1936 ЕЛДА ТӨРКИЯГӘ «МИЛЛИ БАЙРАК» ГАЗЕТАСЫН КЕРТМӘҮ ТАРИХЫННАН

В статье рассматриваются предпосылки создания и история тюрко-татарской газеты «Милли байрак» (1935–1945) — органа Национально-религиозного комитета Идель-Урал тюрко-татарских мусульман Дальнего Востока. Предлагаемые вниманию читателей документы обнаружены автором статьи в Республиканском архиве Анкары (Турция).

**Ключевые слова:** история, запрет газеты, Милли байрак, Гаяз Исхаки.

Мәгълүм булганча, Төркия Республикасы төзелгән еллар — иске тәртип-кыйммәтләрне тамырдан җимергән дәвер ул. Әлеге чорларда көчле дәүләт төзү хакына ил җитәкчелеге халык өнәмәгән шактый чараларны куллана. Бүгенге сәясәтчеләр теле белән әйткәндә, алар «шок терапия»се уздырганнар. Яңа Төрек дәүләте XX гасырның 20 нче еллары башында әле бик зәгыйфь була, элекке дәверләрдәге шикелле бөтендөнья мәйданында үзе хакында шәрран ярып әйтә алмый. Ул әлегә көнбатыштан яки күрше илләрдән бәреп керүе ихтимал булган интервенцияне кире кагарга әзер булмый. Моның өчен төрекләргә, иң башлап, үз дәүләтләрен эчтән яхшылап ныгытырга һәм сугышырга сәләтле армия төзергә кирәк була. Бу мәсьәләдә Мостафа Кәмал Ататөрек [Ататөрек (төрекләр атасы) Мостафа Кәмал (1881, Салоники, Греция — 10 ноябрь 1938, Истанбул, Төркия) — төрек сәяси эшлеклесе, 1918—1923 еллардагы милли-азатлык революциясе җитәкчесе, Төркия Республикасының беренче президенты (1923—1938)] иң зур таяныч итеп совет дәүләтен таный, аның белән хезмәттәшлек итү аркасында ул гуманитар һәм хәрби ярдәм алуга ирешә.

Фәкыйрьлеккә карамастан, бөтендөнья революциясе идеясе һәм шулай ук көньяк чикләрнең куркынычсызлыгы большевиклар өчен көндәлек мәсьәләләрдән өстенрәк булып санала, шуңа күрә дә Советлар үзләренең хәрби запасларын төрекләр белән юмарт бүлешәләр.

Бу шартларда Ататөреккә шушы гамәлләрне файдаланудан гайре чара калмый. Әлбәттә, ул Ленин шикелле кубып, Төркиядә социалистик революция ясарга җыенмый, әмма барыбер дә беркадәр большевиклар уңаена авыша төшә. Икенче бөтендөнья сугышы башланып киткәнгә кадәр төрек матбугатында Советлар иленә карата дошманнарча әйтелгән бер генә фикер дә хупланмый, Россиянең эмиграция оешмалары да бар куәтләренә канат җәя алмый. Совет хакимияте дә үз күршесендә, яңа сугыш уты чыкмасын өчен, ышанычлы партнер булуын тели. Бу аңа илнең көньягында гражданнар сугышында җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу өчен азмы-күпме вакыт бирә.

Советлар хәтта Төркиядә Совет тибындагы һәм рәвешендәге коммунистлар партиясе төзергә дә тырышып карыйлар, һәм шул максат белән илгә Шәриф Манатов, Зиннәтулла Нәүширванов кебек татар агентла-

рын җибәрәләр. Бу омтылышларның уңышсыз тәмамлануы турында әйтеп торуның кирәге юктыр мөгаен. Ататөрек хәтта үз иле коммунистларын, һич тә кызганып тормыйча, төркеме-төркеме белән диңгездә батырып үтергән чорда тагын ни көтмәк кирәк? Дөреслек хакына шунысын да әйтергә кирәк, татар коммунистларына Мостафа Кәмал алай ук шәфкатьсез булмаган. Ул аларның кайберләренә аерым хөрмәт күрсәткән. Кайбер мәгълүматларга караганда, үз вакытында ул Төркиягә атаклы татар сәясәтчесе Мирсәет Солтангалиевне чакырган. Әмма соңгысы барудан баш тарткан, диләр. Төрек галиме Халит Какынч М. Солтангалиевнең мондый җавабын мисал итеп китерә: «Мин сезнең үрнәккә иярәчәкмен: үз илемне илем эчендә булган килеш азат итәргә тырышачакмын» [Атилла Ильхан... с. 55].

1933 елда, Төркия Республикасының 10 еллыгы бәйрәм ителгәндә, совет җитәкчелеге Төркиягә Ворошилов [Ворошилов Климент Ефремович (1881—1969) — совет хәрби һәм дәүләт эшлеклесе], Кржижановский [Кржижановский Глеб Максимилианович (1872—959) — совет дәүләт эшлеклесе], Будённый [Буденный Семен Михайлович (1883—1973) — совет хәрби начальнигы] һәм дәрәҗәле башка түрәләр рәислегендә бик абруйлы делегация җибәрә. Бер үк вакытта Әнкарә белән Мәскәү күпләгән котлау телеграммалары алмашалар, бер-берсенә карата хөрмәт һәм ихтирам белдерәләр. Ул чактагы газеталар болай дип яза: «Төркия Республикасының 10 еллыгын бәйрәм итү тантанасында Әнкарәдә совет делегациясенең катнашуы һәм аларның үзара дусларча мөнәсәбәте төрек халкының куанычын аерата көчәйтеп җибәрде. Шушы бәйрәм көннәрендә төрек һәм совет дәүләт эшлеклеләре һаман тирәнәя барган әлеге дуслыкның зур әһәмиятен һәм матурлыгын аерата көчле тойдылар. Бу хәл карашларның тулысынча уртак икәнен раслады» [В последний час].

«Карашлар берлеге» озак яшәмәгән, Төркиянең гитлерчылар Германиясе белән якынаеп китүе Әнкарә белән Мәскәүнең арасын нык кына боза. 1939 елда ук инде Төркиянең тышкы эшләр министры Шөкерү Сараҗоглы Союздан куыла. Бу хәл төрек-совет мөнәсәбәтләренә тискәре йогынты ясый. Әмма 1943 елда, Икенче бөтендөнья сугышы фронтларында немецларның һөҗүмнәре туктатылгач һәм алар чигенә башлагач, Төркия җитәкчелегенең фикере үзгәрә. Әле кичә генә «совет дошманнарын» һич тә җәлләмәүче һәм милләтчелек рухлы матбугат өстеннән күзәтчелек итүче көчләр акрынлап уңга авыша башлыйлар. Алар тиздән җиңәчәге сизелеп торган Советлар Союзы ягынарак елышырга омтылалар. Төркия Республикасының Исмәт Инёню [Иненю Исмет (1884—1973) — төрек дәүләт эшлеклесе, 1938—1950 елларда — президент, 1923—1937 һәм 1961—1965 елларда — премьер-министр, 1938—1972 елларда — Халык-республика партиясе лидеры] җитәкчелегендәге идарәче даирәсе шулай ук Советлар иле тарафыннан яналган куркынычны сизенәләр. Аның Төркияне оккупацияләп алуы бар лабаса! Шунысы гаҗәп, 1944 елда, илдә нәкъ менә шундый хәлләр вакытында, Төркиядә мәшһүр тюрколог-галим Зәки Вәлиди Тоган кулга алына [Тунджер, с.41]. Суд булып, мәхкәмә аны Төркиядә советка каршы эшчәнлек алып барганы өчен һәм туранчылык идеясе өчен гаеп-

ли. Гаепләү карарында әйтелгәнчә, Зәки Вәлиди Тоган «Төркиянең күршеләре белән арасын бозарга һәм яшәп килгән җәмгыять төзелешенә зарар китерергә» ниятләгән булган икән. Нәтиҗәдә Зәки Вәлиди Тоган «дәүләт түнтәрелеше оештырырга маташуда» [шунда ук] гаепләнеп, 10 елга төрмәдә утырырга хөкем ителә. Хәер, 1945 елда бу хөкем карары үз көчен югалта һәм 15 ай төрмәдә утырган галимне иреккә чыгаралар.

Тагын бер әкәмәт хәл: «нык үскән социализм» елларында Мәскәү дә нәкъ шундый сәяси гамәл кылды. Мәгълүм булганча, төрек шагыйре коммунист Назыйм Хикмәт [Назыйм Хикмәт (1902—1963) — төрек язучысы, җәмәгать эшлеклесе, 1921 елдан коммунист. 17 ел төрле төрек төрмәләрендә утыра] үзенең соңгы елларын Мәскәүдә яшәп уздырды. Әмма бу хәлне совет ягы сер итеп саклады. 1963 елда шагыйрь вафат булганнан соң, Н. Хикмәтнең хатыны Вера Тулякова шагыйрь музеен ачарга теләгәч, аңа катгый итеп болай диләр: «Без ирегезне хөрмәт итәбез, әмма аның аркасында Төркия белән араны бозасыбыз килми» [Братерский, Пасечник].

Кыскасы, Советлар Союзы һәм яшь Төркия Республикасы арасындагы мөнәсәбәтләр дулкын сыманрак халәттә иде. Бүген сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган документлар бу ике илнең «дуслык» дәверенә карый.

Бу документлар шуны сөйли: Кәмал Төркиясендә мөһаҗирләр — элеккеге Россия империясе гражданнары үзләрен тулысынча ирекле итеп тоя алмаганнар, мөһаҗирләр матбугатын тыюсыз гына бастыра һәм тарата алмаганнар. Иң үкенечлесе шунда: Әнкарәнең советчыл сәясәте иң беренче нәүбәттә мөһаҗир төркиләрнең сыртына төште. Югыйсә, алар өчен Төркия икенче ватан гына түгел, ә дөньяда үзләрен иминлектә, куркынычсызлыкта, бераз гына булса да уңайлылыкта тоя торган бердәнбер ышык урын иде.

Тәкъдим ителә торган документларны (төрекчәдән автор тәрҗемәсе) автор Әнкарәнең Республика архивыннан эзләп тапты. Бу архивтагы документлар башлыча 1923 елдан соңгы чорга, ягъни Төркия Республикасы төзелгән дәвергә кагыла. Күләмнәре әллә ни зур булмаса да, бу документлар төрек хакимиятенең 1930 еллар уртасындагы төп сыйфатларын ача. Уйлап карасаң, «Милли байрак» газетасын Төркия биләмәсендә таратуны тыю турындагы карарга Төркиянең Ататөрек үзе җитәкчелек итә торган югары хакимияте кул куйган! Юк, бердәнбер очрак кына булып калмаган бу, ягъни 1931 елда Төркиядә мөһаҗирэмигрантларның бүтән басмалары да тыелган: «Утлы йорт» журналы, «Белдереш» («Хәбәрләр») газетасы, шулай ук мәшһүр «Яңа Төркистан» гомумтөрки журналы. Бу басмалар Азәрбайҗанның һәм, гомумән, совет төркиләренең азатлыгын таләп итәләр. Ул елларда Берлинда чыга торган «Яңа милли юл» дигән эмигрантлар журналы бу хакта болай дип язды: «Без ышанабыз, безнең өчен дус-иптәш бу басмалар — безнең белән бер үк юнәлештә ватаныбызның азатлыгы өчен, милләтебезнең бергә туплануы өчен көрәшүче, уртак мәдәни үзәккә тупланырга ашкынучы бу газета-журналлар тиз арада яңадан чыга башлаячак [Матбугат дөньясында, б. 17].

«Милли байрак» газетасы — «Ерак Көнчыгыш төрки-татарлар мөселманнарының милли-дини комитеты» органы. Ул 1935—1945 ел-

ларда Мукденда татар телендә басылып килгән. Мукден (хәзерге Шэньян) — төньяк-көнчыгыш Кытайдагы Хуаньхэ елгасы ярындагы бер шәһәр, Ляонин провинциясенең административ үзәге. XX гасыр башында ул Маньчжуриянең иң эре шәһәрләреннән берсе булган. Татарлар монда нигездә 1917—1919 елларда килеп төпләнгәннәр. Беренчеләрдән булып бу шәһәргә татар кәсепчесе Әмин Әбүзәр килеп утырган һәм үзе янына 15—20 татар гаиләсен чакыртып китерткән. Тора-бара монда татар җәмәгатьчелеге оешкан, мәчет һәм татар мәктәбе ачылган, яшьләр әдәби-музыкаль кичәләр оештырганнар, милли һәм дини бәйрәмнәр үткәрелгән, үзешчән театр эшләп торган [Кәримуллин, б. 34—35].

«Милли байрак»ны оештыручы, аның идея-илһамчысы — Гаяз Исхакый. Бу газета 1935 елның февралендә булып узган Ерак Көнчыгыш татарларының II корылтае карары белән оештырылган. «Милли байрак» 1935 елның 1 ноябрендә Мукден шәһәрендә зур формат белән һәм атналык газета буларак чыга башлый. Газетаның нашире С. Аити була. Гаяз Исхакый Маньчжуриядән киткәннән соң, аны Ибраһим Дәүләткилдиев һәм аның хәләл җефете Рокыя Мөхәммәдиш нәшер итәләр. Төрле вакытта газетада эшләүчеләр: Әхмәтша Гыйззәтулла (газетаның финанс эшләре белән шөгыльләнә), Мансур Арыслан, Шаһвәли Илдар. Иң актив авторлардан Хөсәен Габдуш, Хәбибрахман Болгари, Әмирулла Аги һәм башкаларны әйтеп үтәргә була. Газета атаклы татар кәсепчесе һәм меценаты Әхмәтвәли Мәңгәрнең матди ярдәмендә чыгарылган [Насыйров, б.163—164; Татарский ..., с.357; Мусин, б.136].

Гаяз Исхакый үзе газетада берничә дистә мәкалә бастырган. Аларның төп тематикасы — милләтне, татар тормышын, аның бүгенгесен һәм киләчәген саклау.

«Милли байрак»тагы мәкаләләрнең күпчелеге татар халкының бәйсез киләчәге өчен көрәш идеяләре белән сугарылган. Бу газета шунда ук барлык татар диаспорасында киң танылу яулый һәм үзенә күрә татар эмиграциясе энциклопедиясенә әверелә. Җәмгысы 440 саны дөнья күрә. Маньчжурия җиренә совет гаскәрләре басып кергәч, 1945 елда «Милли байрак» яшәүдән туктый, ә аның җитәкчелеге кулга алына. Шәһәрдә яшәүче татар халкы, туплаган мал-мөлкәтен ташлап, Мукденнан күчеп китәргә мәҗбүр була [Насыйров, б.163—164; Татарский ..., с. 357; Мусин, б. 136].

Төркия Республикасы Эчке эшләр идарәсе үзенең «1936 елның 15 апреле» дип язылган беренче документында Министрлар Кабинетының югары секретариатына болай дип хәбәр итә: янәсе, аларга мәгълүм булганча, «Милли байрак» газетасы Советлар дәүләтенә каршы куәтле пропаганда алып бара һәм шулай ук дини пропаганда белән шөгыльләнә, шул сәбәпле дус дәүләт белән яхшы мөнәсәбәтләрне бозарга мөмкин. Газетаны илгә кертү мәсьәләсе Министрлар Кабинеты карамагына тапшырыла.

Бу документның пәйда булуына кем сәбәпчедер — тәртип саклаучылар үзләреме, әллә эмигрантлар арасындагы куштаннармы?.. Әйтүе кыен.

***Төрек Республикасының Эчке эшләр идарәсе. Матбугат бүлеге № 506. Әнкарә***

***15 апрель, 1936 ел.***

***Министрлар Кабинетының Югары секретариатына***

*Ерак Көнчыгышның Идел-Урал төрки-татарлары органы булган «Милли байрак» газетасы Мукден шәһәрендә (Маньчжурия) басыла һәм дустанә Советлар дәүләтенә каршы куәтле пропаганда алып бара, шулай ук дини пропаганда белән шөгыльләнә. Шуның нәтиҗәсендә һәм «Матбугат турындагы закон»ның 51 нче маддәсе нигезендә бу газетаны конфискацияләргә кирәк. Бу газетада безне дус дәүләтләр белән дошман итәрлек зарарлы язмаларның булуын һәм газетаның дини пропаганда алып баруын күздә тотып, Министрлар Кабинетыннан кичекмәстән үк бу газетаны безнең дәүләт территориясенә кертүне тыюны сорыйм.*

***Эчке эшләр министрлыгыннан***
*Devlet Arşivleri Genel Müdürlüğü*
*Cumhuriet Arşivi*
*Bakanlar Kurulu Kararları Katalogy*
*18/86/216/1936*

Бу документ Республиканың премьер-министры карамагындагы канцеляриягә җибәрелә. Канцелярия документны Ататөреккә һәм хөкүмәтнең башка министрларына имза өчен әзерли. Кистереп кенә әйтүе кыен: «Милли байрак» газетасын тыю мәсьәләсен хәл итүдә ниндидер астыртын көрәш булганмы-юкмы? Мостафа Кәмалга якын татарлар Садрый Максуди һәм Йосыф Акчура үз фикерләрен әйтә алганнармы? Әллә аларга бу хәлне бөтенләй белдермәгәннәрме? Мөгаен, әйтмәгәннәрдер. Милли иминлеккә кагылышлы мәсьәләләр читятларның киңәшләреннән башка гына хәл ителгәндер. Ататөрек башкалар фикеренә колак салырга мөмкин, әмма карарны ул үзе уйлаганча кабул иткән. Аннары, биш көнгә аерма (документның хөкүмәткә керүе һәм аңа кул куелу вакыты) — төрек бюрократиясе өчен бик кыска вакыт. Димәк, «Милли байрак» газетасын тыю кебек карарлар ул чактагы төрек хакимияте өчен гадәти эш булган.

***Төрек Республикасы премьер-министры карамагындагы канцелярия. Карарлар бүлеге. Карар № 2/4424***

***Карар***

*«Матбугат турындагы Закон»ның 51 маддәсе нигезендә чыгарылган карар:*

*Зыянлы мәкаләләр бастырып чыгарганы өчен Мукден шәһәрендә (Маньчжурия) чыга торган төрки-татар «Милли байрак» газетасын Төркия территориясендә таратудан тыярга. Бу карар шулай ук Эчке эшләр идарәсе тарафыннан 1936 елның 15 апрелендә чыгарылган 506 нчы доку-*

*мент белән дә раслана һәм 1936 елның 20 апрелендә Министрлар Кабинеты чыгарган карар белән беркетелә.*

*20 апрель, 1936 ел. Республика Президенты (К. Ататөрек)*

*Devlet Arşivleri Genel Müdürlüğü*
*Cumhuriet Arşivi*
*Bakanlar Kurulu Kararları Katalogy*
*030/18/01/02/64/31/9*

Әлбәттә, бу очракта Төркия Республикасы җитәкчеләре үз дәүләтләре мәнфәгатьләрен күздә тотып эш иткәннәр. Әмма Төркиянең Советлар белән дуслыгы да барып чыкмаган. Төркиядәге татар диаспорасы исә «Татар эмиграциясе энциклопедиясе»ннән мәхрүм калган. Эмигрантларның таркаулыгы аркасында рәсми инстанцияләрдә татар диаспорасының мәнфәгатьләрен яклаучылар калмаган...

**Әдәбият**


Атилла Ильхан о Галиеве и турецкой революции // Diyalog Avrasya. 2001. № 4. С. 50—57.

*Братерский А., Пасечник О.* Приехать, чтобы остаться // Известия. 2003. 24 июля, №130 (26447).

В последний час // Красная Татария. 1933. 5 ноября, №254 (4727).

*Кәримуллин Ә.* Язмыштан узмыш (Ерак Көнчыгыш илләрендәге татарлар тарихыннан) //Идел. 1990. №5. Б.34—35.

Матбугат дөньясында // Яңа милли юл. 1931. №11.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр, 1998.

*Насыйров Т.* Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. №7. Б.163—164.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998.

*Тунджер Б.* Заки Валиди Тоган. Уфа: Китап,1998.



***Ахунов Азат Марс улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Шәрыкны һәм Исламны өйрәнү кафедрасы доценты*
*e-mail: aakhunov@rambler.ru*

УДК 372.881.1=512.145

*Л.И. Яруллина, Э.И. Яруллин*

# ГОМУМБЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ

## (дәреслекләр, укыту методикасы һәм үсеш перспективалары): 2012—2013 еллар

Авторы предлагаемой вниманию читателей статьи проводят анализ учебников татарского языка. Рассматриваются издания 2012—2013 года, указываются ошибки, допущенные в них, отмечены и выделены положительные стороны создания учебников.

**Ключевые слова**: общеобразовательная школа, учебники татарского языка, положительные стороны, издания.

Гомумбелем бирү мәктәпләрендә татар телен укыту, аның үсеш перспективалары һәм төп юнәлешләре бүгенге көндә игътибар үзәгендә торган төп мәсьәләләрнең берсе санала. Соңгы берничә ел эчендә генә дә гомумбелем бирү мәктәпләрендә татар телен укытуга багышланган шактый дәреслек, уку-укыту комплектлары һәм методик ярдәмлекләр дөнья күрде. Әлеге юнәлештә Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Р.Х. Ягъфәрова, З.И. Җамалетдинова, И.Х. Мияссарова, К.С. Фәтхуллова, Ф.Ш. Гарифуллина,, К.Ф. Фәйзрахманова һәм башкалар шактый актив эшлиләр.

Мәктәп дәреслекләрен өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Бу өч төркем дәреслекләрнең укыту спецификасына бәйле үз максат-бурычлары, методлары һәм чаралары бар.

Беренче төркемне татар мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар телен ана теле буларак өйрәтүне һәм татар балаларының ана теле буенча белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру, баетуны максат итеп куйган дәреслекләр тәшкил итә. Икенче төркем дәреслекләр рус мәктәпләрендә укучы татар балаларын укытуны һәм сөйләмне камилләштерү, шомарту, татар теленең грамматик формалары белән тирәнрәк таныштыруны күздә тота. Ә рус балаларына (чит аудиториягә) татар телен өйрәтүче өченче төркем дәреслекләрнең төп максаты — укучыларда коммуникатив күнекмәләр булдыру, ягъни балаларны, иң беренче чиратта, татарча сөйләшергә, аралашырга өйрәтү. Бу максатлар программа һәм дәреслекләрнең эчтәлеген билгеләүче төп факторлар булып тора.

2012—2013 елларда һәр өч төркем укучылар өчен дә шактый дәреслек басылып чыгарга өлгерде. Мисал өчен, Р.Х. Ягъфәрова тарафыннан төзелгән «Әлифба: 1 нче сыйныф өчен дәреслек» (2012) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бастырырга рөхсәт ителгән. Анда урнаштырылган биремнәр укучыларның сөйләм телен, фикерләү дәрәҗәсен үстерүгә юнәлтелгән.

Дәреслектә татар халык авыз иҗатыннан әкиятләр урын алу бик

тә әһәмиятле. 1 нче сыйныф укучылары өчен бирелгән әкиятләр кызыклы һәм мавыктыргыч [«Балыкчы аю»(35 б.), «Энә карагы» (37 б.), «Юмарт дөя» (49 б.), «Суалчан кунакка бара» (60 б.), «Төлке белән мәче» (88 б.) һ.б.]. К. Аралбай, Г. Афзал, В. Ахунҗанов, А. Барто, Г. Бәширов, Ә. Бикчәнтәева, Р. Вәлиева, Г. Галиев, М. Галиев, Ш. Галиев, Ә. Гаффар, А. Гыйләҗев, Р. Заһидуллин, Р. Зәйдулла, Л. Зөлкарнәй, Н. Измайлова, Н. Исәнбәт, Б. Камалов, М. Кәрим, Р. Киплинг, Ш. Маннур, М. Мәһдиев, З. Минһаҗева, Р. Миңнуллин, Р. Мостафин, Э. Мөэминова, Ә. Мушинский, К. Насыйри, А. Нигъмәтуллин, З. Нури, В. Нуруллин, Г. Паушкин, М. Рәфыйков, Г. Рәхим, Б. Рәхмәт, Х. Сапаров, К. Тәхау, Р. Төхфәтуллин, Г. Тукай, И. Туктаров, З. Туфайлова, Х. Туфан, С. Урайский, А. Хәлим, А. Шамов, Л. Шәех, Р. Шәрипова, И. Юзеев, Ф. Яруллин, М. Яснов әсәрләре яки әсәрләреннән өзекләр һәм «Салават күпере» журналыннан, «Кем ул? Нәрсә ул?» энциклопедиясеннән алынган текстлар укучыларда хезмәткә карата хөрмәт, эти-әнигә ихтирам тәрбияли, табигатьнең матурлыгын күрергә, туган илне, кош-кортларны һәм хайваннарны яратырга өйрәтә. Дәреслекнең бизәлеше дә уңай тәэсир калдыра. Рәсемнәр матур, ачык төсләр белән ясалган, аңлаешлы. Дәреслекнең уңай ягы — китаптагы авыррак һәр сүзгә басым тамгасы куелган, тәрбияви текстлар бирелгән «Тәрбия китабы» (32 б.), «Ихтыяр» (47 б.), «Яхшылыкка-яхшылык» (85 б.)], яттан өйрәнергә тәкъдим ителгән шигырьләре дә кызыклы.

Дәреслек белән танышу барышында кайбер теләк-тәкъдимнәр дә тумый калмады әлбәттә. Уку әсбабында материалларны бастырганда, кайбер төгәлсезлекләр киткән. «Хәйран калырлык» (10 б.), «һава тирбәнешләре» (18 б.), «һава агымы» (19 б.), «үткер булып үстем» (21 б.) дигән сүзтезмәләр һәм «Һава агымы йоткылык аша ничек чыга?» (98 б.) дигән сорау 1 нче сыйныф укучысы өчен аңлашылып бетми кебек.

1 нче сыйныф дәреслегендә авыр сүзләр дә бик күп. Мәсәлән: дәрт, дәртле, дәртләнә (49 б.); бәрәкәт, бәрәкәтле (52 б.); укалау, укалы, ука (54 б.); әлсери, ансат, бәс, бәсле (60 б.); үгет, үгетли, гауга, гаугалы, горур, горурлана, гәрәбә, гарнир, галим, галимлек, гамәл (62 б.); тәпән (65 б.); иш, ишкәк, ышык, кеш, шома, шелтә, шелтәли, шик, ширбәт, шәкерт, шүрли, шүрлек (67 б.); изге, изгелек, эзтабар, үзән, зарар, зелпе, зиннәт, зирәк, кизү (70 б.); өтә, көлтә, көрпә, көрт, колмак, морза, мөлкәт, төрләнеш (73 б.); хаҗәт, зиһенле (75 б.); даһи, пөхтә, каһвә, аһәң, бихисап, баһадир, шаһитлык, сихәт, шөһрәт, хикмәт, мохит, ихтирам, шөһрәтле (98 б.); гыйфрит, зифа, ифрат, нәфрәт, офык, уфтана, саф, сафлана, сәфәр, хәтфә, фаҗига, фетнә, фикер (101 б.); мәгърур, гамь, гамьсез, гарьлек, дәгъва, шәфәкъ, шәфкать (110 б.). Әлифбада сүзлек эше бик аз бирелгән. Мәсәлән: озын нотык тотмыймын — күп сөйләп тормыйм (4 б.), мөкатдәс — изге, бөек (6 б.), аваздаш — охшаш яңгырашлы (8 б.), чуерташ — су белән юылып шомарган таш (10 б.), могҗиза — искитәрлек нәрсә (14 б.), сарыф итеп — файдаланып (27 б.), кәлҗемә — бәрәңгедән пешерелгән калын коймак (112 б.), ябага — яз көне коела торган йомшак йон катламы (117 б.).

Ф.Ф. Харисов һәм Ч.М. Харисова тарафыннан рус мәктәпләренең

5 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен төзелгән «Татар теле» дәреслеге (2012) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән бастырылган. Бу уку әсбабында татар халык авыз иҗатыннан әкиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, тизәйткечләр урын алу бик тә әһәмиятле, сүзлек эше һәм биремнәр дә уңышлы, тестлар да бирелгән (31—32 б., 56—57 б., 83—84 б., 138—139 б.). Дәреслекнең бизәлеше дә уңай тәэсир калдыра. Дәреслектә бирелгән иллюстрацион материаллар текстлар белән туры килә. Рәсемнәргә куелган сораулар һәм биремнәр баланың сөйләм телен үстерүне күз уңында тота, биремнәр һәм күнегүләр төрләндерелгән, тәрбияви якны да искә алып сайланган. Шулай да анда кайбер төгәлсезлекләр дә киткән. Мәсәлән, 19 нчы күнегүнең биреме 5 нче сыйныф укучысына авыррак булыр кебек (13 б.), кайбер рәсемнәр уңышлы түгел (58 б., 104 б., 125 б., 156 б.).

Соңгы елларда дәреслек бастыру эшенә «Мәгариф–Вакыт» нәшрияты да уңышлы гына кушылып китте. Ф.Ф. Харисов һәм Ч.М. Харисова тарафыннан төзелгән «Татар теле: 1 нче сыйныф өчен дәреслек»тә (2012) биремнәр, рәсемнәр, сүзлек эше һәм кроссвордлар бирелү дә уңышлы, шулай ук татар халык авыз иҗатыннан әкиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, тизәйткечләр урын алу бик тә әһәмиятле. Татар халык авыз иҗатыннан үрнәкләр бирү укучыларда хезмәткә карата хөрмәт, әти-әнигә ихтирам тәрбияли, табигатьнең матурлыгын күрергә, туган илне, кош-кортларны һәм хайваннарны яратырга өйрәтә. Дәреслек ахырында орфографик сүзлекчә бирелүен дә уңышлы дип саныйбыз.

З.И. Җамалетдинова тарафыннан төзелгән «Татар теле: 1 нче сыйныф өчен дәреслек» (2012) составына, дәреслектән тыш, эш дәфтәре, укытучылар өчен методик кулланма да керә. Дәреслекнең электрон кушымтасы да бар. Кушымта 26 дәрестән тора һәм шулай ук ул 54 аудио язманы, 23 анимацияне, 104 сюжетлы һәм 184 предметлы рәсемнәрне үз эченә ала. Уку әсбабының уңай ягы — сүзлек эше яхшы, ребуслар, кроссвордлар һәм татар халык авыз иҗатыннан үрнәкләр бирелгән. З. Туфайлова, М. Газизов, Ш. Галиев, Җ. Дәрзаман, Г. Зәйнашева, И. Иксанова, Р. Вәлиева, Г. Афзал, Г. Тукай, Һ. Такташ, Ә. Синегулов, А. Пушкин, М. Фәйзуллина, Ш. Җиһангирова, М. Соловьева, Н. Исәнбәт, С. Есенин, Х. Вахит, Э. Авзалова, Ш. Маннур, М. Хөсәен шигырьләре, «Салават күпере» журналыннан алынган әсәрләр укучыларда хезмәткә карата хөрмәт, әти-әнигә ихтирам тәрбияли, туган илне, кош-кортларны һәм хайваннарны яратырга өйрәтә.

Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Е.А. Пановалар тарафыннан рус мәктәпләренең 2 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен төзелгән «Татар теле» дәреслеге (2013) һәм Ф.Ф. Харисов, Г.Р. Шакиров, Р.К. Сәгъдиева, Л.К. Хисмәтовалар тарафыннан рус мәктәпләренең 3 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен төзелгән «Татар теле» дәреслеге (2013) гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем стандарты һәм татар теленнән гомуми белем бирүнең гамәлдәге дәүләт стандарты таләпләренә туры килерлек итеп эшләнгән. Әлеге ике дәреслек эш дәфтәре һәм укытучылар өчен төзелгән кулланма белән тулы бер комплектны (УМК) тәшкил итә. Яңа темаларны Фәрит абый, Алсу, Булат һәм Руслан сорау-

җавап (әңгәмә) формасында аңлата. Уку әсбабының уңай ягы — һәр яңа темадан соң, «Хәтереңдә калдыр!» бирелә, текстларны русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә итү биремнәре, татар халык авыз иҗатыннан үрнәкләр (мәкальәйтемнәр, табышмаклар, санамышлар, мәзәкләр һәм тизәйткечләр) һәм башваткычлар, ребуслар, шарадалар бирелгән.

Дәреслекнең бизәлеше дә уңай тәэсир калдыра. Дәреслектә бирелгән иллюстрацион материаллар текстлар белән туры килә. Рәсемнәргә куелган сораулар һәм биремнәр баланың сөйләм телен үстерүне күз уңында тота. Ш. Маннур, Р. Миңнуллин, Л. Шәех, Р. Бәшәр, Й. Шәрәпова, Ф. Яруллин, Р. Мингали, Ш. Галиев, Г. Гыйльманов, Л. Лерон, Ә. Кари, Р. Вәлиева, К. Нәҗми, Э. Мөэминова, Х. Халиков, Ф. Яруллин, Х. Гарданов, М. Фәйзуллина, Л. Әмирханова, Ф. Кәрим, С. Шакир шигырьләре укучының сөйләм телен үстерә һәм балаларда хезмәткә карата хөрмәт, әти-әнигә ихтирам тәрбияли. Дәреслек ахырында «Татарча-русча сүзлек», «Русча-татарча сүзлек», «Дөрес әйт һәм дөрес яз! сүзлеге», «Аңлатмалы сүзлек» бирелгән. Әлеге сүзлекләр, укучылар өчен, бик отышлы һәм файдалы дип саныйбыз. Шулай ук эш дәфтәрләре булу да яхшы. Әлеге дәфтәрләрдә бирелгән күнегүләрне укучылар бик кызыксынып эшлиләр.

Дәреслек белән танышу барышында кайбер теләк-тәкъдимнәр дә тумый калмады әлбәттә. Уку әсбабында материалларны бастырганда, кайбер төгәлсезлекләр киткән. Шулай ук 2 нче сыйныф дәреслегендә темага карата күнегүләр бик аз, балаларның белемнәрен ныгыту өчен җитәрлек түгел. Хәтер диктанты өчен дә күнегүләр азрак.

3 нче сыйныф дәреслегендә исә лексикасы балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килеп бетмәгән күнегүләр дә очрый. Бер күнегү кысаларында яңа сүзләрнең артык күп булуы укучыларга аларны тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә комачаулый. Яңа сүзләр темаларга бүленеп бирелсә, укучылар өчен уңайлырак булыр иде.

Дәреслеккә сөйләм телен үстерүне максат иткән күнегүләр (рәсемгә карап хикәя язу) буенча әзерлек эше дә кертелмәгән. Кызыксындыра торган сораулар куелса, сүз байлыгын арттыру өчен матур сүзләр, чагыштырулар, сынландыру-җанландыруга мисаллар бирелсә, яхшырак булыр иде.

И.Х. Мияссарова һәм К.Ф. Фәйзрахманова тарафыннан төзелгән «Татар теле: 3 нче сыйныф өчен дәреслек» («Мәгариф – Вакыт» нәшрияты, 2013) гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем стандарты һәм татар теленнән гомуми белем бирүнең гамәлдәге дәүләт стандарты таләпләренә туры килерлек итеп эшләнгән. Уку әсбабы, дәреслектән тыш, мөстәкыйль эш дәфтәре, укытучылар өчен методик кулланма белән бердәм комплектны тәшкил итә. Дәреслек 2 кисәктән тора. Һәр кисәкнең ахырында, укучыларның тел байлыгын арттыру, дөрес язу һәм дөрес әйтү күнекмәсен үстерү максатыннан, «Аңлатмалы сүзлек», «Дөрес әйт! сүзлеге», «Дөрес яз! сүзлеге» һәм «Тотрыклы сүзтезмәләр сүзлеге» урнаштырылган. Кагыйдәләр һәм яңа теманы кабатлау өчен тестлар бирелү дә дәреслекнең уңай ягы булып тора. Китапта программада каралган материаллар урын алган. Ул элеккеге басмаларга караганда камилрәк, уңайлырак.

Дәреслектә бирелгән биремнәр һәм күнегүләр төрләндерелгән, тәрбияви якны да искә алып сайланган. Алар укучыларның сөйләм телен, фикерләү дәрәҗәсен үстерүгә юнәлтелгән. Дәреслекнең бизәлеше дә уңай тәэсир калдыра.

И.Л. Литвинов, Э.Р. Садыйкова, Л.И. Гариповалар тарафыннан рус мәктәпләренең 3 нче сыйныфында укучы, рус телендә сөйләшүче балалар өчен төзелгән «Татар теле һәм уку китабы» (Татарстан китап нәшрияты, 2013) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бастырырга рөхсәт ителгән. Дәреслекнең уңай ягы — текстларда, диалогларда, шигырьләрдә сүзләргә басым куелган, сүзлек эше бирелеп бара, мәкаль-әйтемнәр, кроссвордлар һәм тәрҗемә итү эше (биремнәрдә татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү текстлары) бирелә. Б. Рәхмәт, М. Газизов, Г. Әхтәмова, С. Гыйльфан, М. Фәйзуллина, Х. Гарданов, Ш. Галиев, К. Булатова, Р. Мингалим, Җ. Дәрзаман, Р. Рәкыйпов, Н. Исәнбәт, Х. Халиков, Р. Миңнуллин, Ә. Фәйзи, М. Җәлил, Э. Мөэминова, Р. Корбан, В. Хәйруллина шигырьләре укучыны табигатьнең матурлыгын күрергә, әти-әнине, хезмәтне, туган илне һәм хайваннарны яратырга өйрәтә. Дәреслек ахырында «Өстәмә уку өчен» халык авыз иҗатыннан әкиятләр, табышмаклар, такмаклар, санамышлар, бишек җырлары китерелә һәм «Татарча-русча сүзлекчә» бирелә. Уку әсбабы белән танышу барышында кайбер теләк-тәкъдимнәр дә тумый калмады әлбәттә. Мәсәлән, рәсемнәрдәге балалар йөзе олы кешеләрнекенә охшап тора, ә калган рәсемнәр уңышлы һәм аңлаешле.

Гомумән алганда, авторлар бирем һәм күнегүләрне төрләндерергә, телдән һәм язма күнегүләрне чиратлаштырырга тырышканнар, структур яктан әлеге дәреслекләр программа таләпләренә туры китереп төзелгән, тәрҗемә итү текстлары да дөрес сайланган. Киләчәктә игътибар ителергә тиешле мәсьәләләрнең берсе — күнегүләр һәм биремнәрне формалаштырганда, фикер төгәллеге һәм җыйнаклыгы җитмәү. Бу проблема барлык тип дәреслекләр өчен дә хас.

Соңгы елларда чыккан дәреслекләр сыйфат дәрәҗәсе ягыннан да, бизәләше нисбәтеннән дә алдагы буын дәреслекләреннән берничә баскыч өстә торалар. Дәреслекләр, һичшиксез, яхшы якка үзгәрә һәм камилләшә баралар.

## Әдәбият

*Җамалетдинова З.И.* Татар теле: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек. Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 71 б.

*Җамалетдинова З.И.* Татар теле дәресләре: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма. Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 83 б.

*Җамалетдинова З.И.* Татар теленнән эш дәфтәре: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен. Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 31 б.

*Литвинов И.Л.* Татар теле һәм уку китабы: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан: Татар. кит. нәшр. 2013. 135 б.

*Мияссарова И.Х.* Татар теле: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. 1 нче кисәк. Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшр. 2013. 127 б.

*Мияссарова И.Х.* Татар теле: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. 2 нче кисәк. Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшр. 2013. 111 б.

*Фәтхуллова К.С.* Татар теле: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан: Татар. кит. нәшр. 2013. 151 б.

*Харисов Ф.Ф.* Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 159 б.

*Харисов Ф.Ф.* Татар теле: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 79 б.

*Харисов Ф.Ф.* Татар теле: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 95 б.

*Харисов Ф.Ф.* Татар теле: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшр. 2013. 159 б.

*Харисов Ф.Ф.* Татар теле: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшр. 2013. 143 б.

*Ягъфәрова Р.Х.* Әлифба: татар телендә башл. гомум белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек. Казан: Татар. кит. нәшр. 2012. 119 б.

***Яруллина Ләйсән Илсур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: liysan-jarullina@mail.ru*

***Яруллин Эльмир Илсур улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*e-mail: ehlmir-jarullin@mail.ru*

УДК 517.3

***Ә.Ф. Галимҗанов***

# БЕРЕНЧЕ ТӨР ВАКЛАНМА-ИНТЕГРАЛ ТИГЕЗЛӘМӘЛӘРНЕ ЯКЫНЧА ЧИШҮ ЫСУЛЛАРЫ

*Остазым, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы*
*Габделхәев Билсур Габделхәй улының якты истәлегенә багышлана*

В работе рассматривается обобщенное дробно-интегральное уравнение с интегралом в смысле Вейля. Доказаны существование и единственность, а также устойчивость решения. Построены прямые методы решения таких уравнений: методы коллокаций и Галёркина. Дано их теоретическое обоснование на основе результатов конструктивной теории функций и функционального анализа.

**Ключевые слова:** дробно-интегральное уравнение, метод коллокаций, метод Галёркина

Вакланма тәртипле интеграл һәм дифференциал тигезләмәләр фән һәм техниканың күп өлкәләрендә кулланыла. Чагыштырмача яңа аппарат буларак, аларны якынча чишү ысуллары әлегә эшләнмәгән. Бу мәкаләдә вакланма тәртибендәге интеграл тигезләмәләрнең аерым бер төрен якынча чишү ысуллары карала.

Вейль-Лиувилль вакланма интегралы түбәндәгечә билгеләнә:

$$I_{\pm}^{(\alpha)}(\varphi;t) = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi} \varphi(x-t)\Psi_{\pm}^{\alpha}(t)dt,\ \ \alpha > 0,$$

биредә

$$\Psi_{\pm}^{\alpha}(t) = 2\sum_{k=1}^{\infty}\frac{\cos(kt \mp \alpha\pi/2)}{k^{\alpha}}$$

Вакланма тәртибендәге Вейль-Лиувилль чыгарылмасы болай билгеләнә:

$$D_{\pm}^{(\alpha)}f = \pm\frac{d}{dx}I_{\pm}^{(\alpha)}f.$$

## 1. Чишелешнең булуы һәм бердәнберлеге

Түбәндәге вакланма-интеграл тигезләмәне карыйк:

$$A\overline{\varphi} = \gamma + I_{\pm}^{(\alpha)}(\varphi;t) + T(\varphi;t) = f(t), 0 \le t \le 2\pi \quad (1.1)$$

Биредә $\gamma$, $\varphi(t)$ — билгесезләр, $I_{\pm}^{(\alpha)}(\varphi;t)$ — Вейль мәгънәсендәге вакланма интеграллау операторы, $0<\alpha<1$, $f(t)$ — бирелгән функция, $T$ — бирелгән сызыкча оператор. Алдарак кулланылачак тамгаларны кертик:

$$C_{2\pi}^{0} = \left\{f \in C_{2\pi}: \int_0^{2\pi} f(t)dt = 0\right\}$$

— уртача кыйммәте нуль булган 2π — периодик өзлексез функцияләр пространствосы;

$\overline{C}$ исә $\overline{\varphi}=(\gamma,\varphi)$ вектор-функцияләр пространствосы; биредә $\gamma\in R$, $\varphi\in C^0_{2\pi}$. Бу пространствода норма түбәндәгечә билгеләнә:

$\|\overline{\varphi}\|=|\gamma|+\|\varphi\|_{2\pi}$.

Шулай ук вакланма α тәртибе белән дифференциалланучы $C^\alpha\equiv C^\alpha\,[0,2\pi]$ пространствосын кертик. Норма түбәндәгечә билгеләнә:

$\|f\|_{C^\alpha}=|c_0(f)|+\left\|D_\pm^{(\alpha)}(f-c_0(f))\right\|_{C_{2\pi}}$, $c_0(f)=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}f(t)dt$. Биредә $D_\pm^{(\alpha)}$ — тәртибе $0<\alpha<1$ булган Вейль-Лиувилль вакланма дифференциаллау операторы.

$C_{2\pi}$ һәм $\overline{C}$ пространстволарының тулы, нормаланган пространстволар булуы билгеле. $C^\alpha$ пространствосының нормаланган икәнлеге һәм тулылыгы шулай ук бик җиңел күрсәтелә.

(1) тигезләмәсе өчен түбәндәге расламалар үтәлә:

**1 нче теорема.** $T:\overline{C}\to C^\alpha$ тулаем өзлексез оператор булсын һәм (1) тигезләмәсенә тиңдәш бериш $A\overline{\varphi}=0$, $\overline{\varphi}\in\overline{C}$ тигезләмәсенең $\overline{C}$ пространствосында тривиаль $\overline{\varphi}=0\leftrightarrow\varphi=0$, $\gamma=0$ чишелеше генә булсын. Ул вакытта $A:\overline{C}\to C^\alpha$ операторына өзлексез кире оператор бар, димәк (1) тигезләмәсе теләсә нинди $f\in C^\alpha$ уң як функциясе өчен бердәнбер $\overline{\varphi}^*=(\varphi^*,\gamma^*)\in\overline{C}$ чишелешенә ия.

**Исбатлау**. Башта ярдәмче тигезләмәне карыйк:

$$G\overline{\varphi}\equiv\gamma+I_\pm^{(\alpha)}\varphi=f,\overline{\varphi}\in\overline{C},f\in C^\alpha. \quad (1.2)$$

$G:\overline{C}\to C^\alpha$ операторы өчен өзлексез кире оператор бар икәнен күрсәтик, ә бу операторлар нормалары өчен

$$\|G\|_{\overline{C}\to C^\alpha}=\|G^{-1}\|_{C^\alpha\to\overline{C}}=1 \quad (1.3)$$

тигезлеге үтәлә.

Теләсә нинди $\overline{\varphi}\in\overline{C}$ функциясе өчен түбәндәге тигезлекләр хас:

$$\|G\overline{\varphi}\|_{C^\alpha}=|c_0(G\overline{\varphi})|+\left\|D_\pm^{(\alpha)}(G\overline{\varphi}-c_0(G\overline{\varphi}))\right\|_{C_{2\pi}}=\left|\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left(\gamma+I_\pm^{(\alpha)}(\varphi;t)\right)dt\right|+$$
$$\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(\gamma+I_\pm^{(\alpha)}\varphi-\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left(\gamma+I_\pm^{(\alpha)}(\varphi;t)\right)dt\right)\right\|_{C_{2\pi}}$$

Ләкин теләсә нинди $\varphi\in C^0_{2\pi}$ функциясенең Вейль мәгънәсендәге вакланма интегралы шулай ук $C^0_{2\pi}$ пространствосына керә, димәк,

$$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left(I_\pm^{(\alpha)}(\varphi;t)\right)dt=0.$$

Моннан

$$\|G\overline{\varphi}\|_{C^\alpha}=|\gamma|+\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(I_\pm^{(\alpha)}\varphi\right)\right\|_{C_{2\pi}}=|\gamma|+\|\varphi\|_{C_{2\pi}}=\|\overline{\varphi}\|_{\overline{C}}$$

икәнлеге чыга. Болардан исә

$$\|G\|_{\overline{C}\to C^\alpha}=1$$

нәтиҗәсе табыла. Моннан соң, теләсә нинди $f \in C^\alpha$ функциясе өчен, (2) формуласын файдаланып,

$$\gamma = c_0(f) \equiv \gamma^*, \varphi = D_{\pm}^{(\alpha)}\big(f - c_0(f)\big) \equiv \varphi^*$$

булуын табабыз, ягъни $G : \overline{C} \to C^\alpha$ операторының кире сызыкча операторы бар һәм ул

$$G^{-1}f = \overline{\varphi}^* = (\gamma^*, \varphi^*) = \left(c_0(f), D_{\pm}^{(\alpha)}\big(f - c_0(f)\big)\right).$$

Шуңа күрә, теләсә нинди $f \in C^\alpha$ өчен

$$\|G^{-1}f\|_{\overline{C}} = \left\|\overline{\varphi}^*\right\|_{\overline{C}} = |\gamma^*| + \|\varphi^*\|_{2\pi} = |c_0(f)| + \left\|D_{\pm}^{(\alpha)}\big(f - c_0(f)\big)\right\|_{C_{2\pi}} = \|f\|_{C^\alpha}$$

Биредән $\|G^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}} = 1$ икәнлеге ачык.

(1) тигезләмәсен аңа эквивалент булган оператор формасында языйк.

$$A\overline{\varphi} \equiv G\overline{\varphi} + T\varphi = f, \overline{\varphi} \in \overline{C}, f \in C^\alpha \quad (1.4)$$

G операторына өзлексез кире оператор булганга күрә, (3) тигезләмәсе

$$K\overline{\varphi} \equiv \overline{\varphi} + G^{-1}T\varphi = G^{-1}f, \overline{\varphi}, G^{-1}f \in \overline{C}. \quad (1.5)$$

Теорема шарты һәм (3) формулалары нигезендә, $G^{-1} T: \overline{C} \to \overline{C}$ операторы тулаем өзлексез, димәк (5) тигезләмәсе $\overline{C}$ банах пространствосында икенче төр Фредгольм тигезләмәләренә тиңдәш тигезләмә булып тора. Бу тигезләмә Фредгольм альтернативасының үтәлүен күрсәтә, моннан исә теореманың расламасы табыла.

**2 нче теорема**. $q \equiv \|T\|_{\overline{C} \to C\alpha} < 1$ булсын. Ул вакытта (1) тигезләмәсенең теләсә нинди $f \in C^\alpha$ өчен бердәнбер $\overline{\varphi}^* = (\varphi^*, \gamma^*) \in \overline{C}$ чишелеше була, биредә $\gamma^* \in R$, $\varphi^* \in C^0_{2\pi}$, бу вакытта

$$\|\overline{\varphi}^*\|_{\overline{C}} \le \frac{\|f\|_{C^\alpha}}{1-q}$$

тигезсезлеге үтәлә.

**Исбатлау.** 1 нче теоремадагы исәпләүләр буенча, (1) тигезләмәсе (5) тигезләмәсенә эквивалент һәм аны түбәндәге формада язарга мөмкин:

$$\overline{\varphi} = G^{-1}f - G^{-1}T\varphi \equiv H\overline{\varphi} \quad (1.6)$$

Бу вакытта теләсә нинди $\overline{\varphi}, \overline{\omega} \in \overline{C}$ өчен

$$\|H\overline{\varphi} - H\overline{\omega}\|_{\overline{C}} = \|G^{-1}f - G^{-1}T\varphi - (G^{-1}f - G^{-1}T\omega)\|_{\overline{C}}$$
$$= \|G^{-1}T\varphi - G^{-1}T\omega\|_{\overline{C}} \le \|G^{-1}T\|_{\overline{C}\to\overline{C}} \cdot \|\overline{\varphi} - \overline{\omega}\|_{\overline{C}}.$$

$G^{-1}$ T операторының нормасын түбәндәгечә бәяләп була:

$$\|G^{-1}T\|_{\overline{C}\to\overline{C}} \le \|G^{-1}\|_{C^\alpha\to\overline{C}} \cdot \|T\|_{\overline{C}\to C^\alpha} = q < 1,$$

шулай итеп, $\|H\overline{\varphi} - H\overline{\omega}\|_{\overline{C}} \le q\|\overline{\varphi} - \overline{\omega}\|_{\overline{C}}, q < 1,$ ягъни $H$ операторы кысу операторы булып тора. Ул вакытта, кысучы чагылдырулар принцибы буенча, (2.6) тигезләмәсе нигезендә билгеләнгән операторның бердәнбер кузгалмас ноктасы $\overline{\varphi}^*$ бар, димәк (1) тигезләмәсенең дә бердәнбер чишелеше була. Моннан соң, башлангыч якынайтуны ирекле сайлап, түбәндәге итерацияләрне башкарабыз:

$$\overline{\varphi}_0 = G^{-1}f \equiv r,$$

$$\overline{\varphi}_1 = r - G^{-1}Tr,$$
$$\overline{\varphi}_2 = r - G^{-1}T(r - G^{-1}Tr) = r - G^{-1}Tr + (G^{-1}T)^2 r,$$
$$\overline{\varphi}_n = \sum_{k=0}^{n}(-1)^k (G^{-1}T)^k r.$$

Бу вакытта (1) тигезләмәсенең чишелешен болай язып булачак:

$$\overline{\varphi}^* = \sum_{k=0}^{\infty}(-1)^k (G^{-1}T)^k r.$$

Бу формуланы файдаланып, $\overline{\varphi}^*$ чишелеше нормасын бәяләп була:

$$\|\overline{\varphi}^*\|_{\overline{C}} \le \sum_{k=0}^{\infty} q^k \|r\|_{\overline{C}} = \frac{\|r\|_{\overline{C}}}{1-q} = \frac{\|G^{-1}f\|_{\overline{C}}}{1-q} \le \frac{\|f\|_{C^\alpha}}{1-q}$$

Шулай итеп, теорема исбатланды.

**3 нче теорема.** 2 нче теорема шартларында (1) тигезләмәсенең бердәнбер $\overline{\varphi}^* = (\varphi^*, \gamma^*) \in \overline{C}$ чишелешен мондый итерацион метод белән табырга мөмкин:

$$\gamma^i + I_{\pm}^{(\alpha)}(\varphi^i; t) = f(t) - T(\varphi^{i-1}; t), i = 1,2, \dots$$

бу вакытта башлангыч якынайту ¯φ^0 теләсә нинди була ала. Аерым алганда, әгәр $\overline{\varphi}^0 = G^{-1}f = \left(c_0(f), D_{\pm}^{(\alpha)}(f - c_0(f))\right)$ икән, $i$-нче итерация төгәлсезлеге болай бәяләнә:

$$\left\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}^i\right\|_{\overline{C}} \le \frac{q^{i+1}\|f\|_{C^\alpha}}{1-q}, i = 1,2, \dots$$

**Исбатлау.** (5) формуласын кулланып, эквивалент методны табабыз:

$$\overline{\varphi}^i = G^{-1}f - G^{-1}T\varphi^{i-1}, \mathrm{i} = 1,2, \dots$$

2 нче теоремадагы исәпләүләргә охшаган исәпләүләр кулланып, төгәлсезлек хатасын табабыз:

$$\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}^i = \sum_{k=i+1}^{\infty}(-1)^k (G^{-1}T)^k r;$$

$$\left\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}^i\right\|_{\overline{C}} \le \sum_{k=i+1}^{\infty} \|G^{-1}T\|_{\overline{C}\to\overline{C}}^k \|r\|_{\overline{C}} \le \frac{q^{i+1}\|G^{-1}f\|_{\overline{C}}}{1-q} \le \frac{q^{i+1}\|f\|_{C^\alpha}}{1-q}, i = 1,2, \dots$$

Теорема исбатланды.

## 2. Чишелешнең тотрыклылыгы

(1.1) тигезләмәсе белән бергәттән түбәндәге интеграл тигезләмәне карыйк:

$$A_\varepsilon \overline{\varphi} \equiv \gamma + I_{\pm}^{(\alpha)}(\varphi; t) + T_\varepsilon(\varphi; t) = f_\varepsilon(t), 0 \le t \le 2\pi, \varepsilon > 0, \qquad (2.1)$$

Биредә $T_\varepsilon, f_\varepsilon$ — (1.1) тигезләмәсенең тиңдәшле элементларына якын булган элементлар.

**4 нче теорема**. Түбәндәге шартлар үтәлсен:

а) $A : \overline{C} \to C^\alpha$ операторының өзлексез кире операторы булсын;

б) $\|T - T_\varepsilon\|_{C_{2\pi}\to C^\alpha} \le \varepsilon$

Ул вакытта теләсә кайсы $f_\varepsilon \in C^\alpha$ һәм теләсә нинди $\varepsilon \in (0, \varepsilon_0)$ өчен (2.1) тигезләмәсенең бердәнбер $\overline{\varphi}_\varepsilon = (\gamma_\varepsilon, \varphi_\varepsilon)$ чишелеше булырлык $\varepsilon > 0$ саны бар.

Әгәр дә өстәмә рәвештә

в) $\|f - f_\varepsilon\|_{C\alpha} \leq \varepsilon$ шарты үтәлә икән, $\overline{\varphi}_\varepsilon(t)$ якынча чишелешләре төгәл $\overline{\varphi}^*$ чишелешләренә $\overline{C}$ пространствосында җыела һәм җыелу тизлеге $p_\varepsilon = \varepsilon\|A^{-1}\|_{C\alpha \to \overline{C}} < 1$ булырлык теләсә нинди $\varepsilon > 0$ өчен түбәндәгечә булачак:

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_\varepsilon\|_{\overline{C}} \leq \frac{p_\varepsilon}{1 - p_\varepsilon}\left(1 + \|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}\|f\|_{C^\alpha}\right) = O(\varepsilon), (\varepsilon \to 0+).$$

**Исбатлау.** Теореманың б) шартын кулланып, теләсә нинди $\overline{\varphi} \in \overline{C}$ өчен табабыз:

$$\|A\overline{\varphi} - A_\varepsilon\overline{\varphi}\|_{C^\alpha} = \|T\varphi - T_\varepsilon\varphi\|_{C^\alpha} \leq \varepsilon\|\varphi\|_{C_{2\pi}} \leq \varepsilon\|\overline{\varphi}\|_{\overline{C}}$$

шуңа күрә

$$\|A - A_\varepsilon\|_{\overline{C} \to C^\alpha} \leq \varepsilon, \varepsilon > 0.$$

$\varepsilon_0 > 0$ саны $p_\varepsilon < 1$ тигезсезлеге чишелешләренең иң зурысы булсын. Ул вакытта киресе булган операторга якын торган операторның киресе булу турындагы барлык шартлар үтәлә, ягъни, $A$ — банах пространствосында чикләнгән оператор, $A^{-1}$ — аңа кире оператор булсын. Ул вакытта

$$\|A - A_\varepsilon\|_{\overline{C} \to C^\alpha} \leq \varepsilon_0 \leq \frac{1}{\|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}}$$

тигезсезлеген канәгатьләндергән $A_\varepsilon$ операторлары өчен чикләнгән кире $A^{-1}_\varepsilon$ операторлары булачак. Теореманың беренче расламасы исбатланды. Дәвам итеп, табабыз:

$$A\left(\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_\varepsilon\right) = f - A\overline{\varphi}_\varepsilon = f - f_\varepsilon + (A_\varepsilon - A)\overline{\varphi}_\varepsilon,$$ моннан исә

$$\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_\varepsilon = A^{-1}(f - f_\varepsilon + (A_\varepsilon - A)\overline{\varphi}_\varepsilon)$$ булуы чыга. Шулай итеп,

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_\varepsilon\|_{\overline{C}} \leq \|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}(\|f - f_\varepsilon\|_{C^\alpha} + \|(A_\varepsilon - A)\overline{\varphi}_\varepsilon\|_{C^\alpha}) \leq$$

$$\|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}(\|f - f_\varepsilon\|_{C^\alpha} + \|A_\varepsilon - A\|_{\overline{C} \to C^\alpha}\|A_\varepsilon^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}\|f_\varepsilon\|_{C^\alpha} \leq \|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}(\|f - f_\varepsilon\|_{C^\alpha}$$

$$+\frac{p_\varepsilon}{1-p_\varepsilon}\|f_\varepsilon\|_{C^\alpha}) \leq \frac{\|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}}{1-p_\varepsilon}$$

$$\|f - f_\varepsilon\|_{C^\alpha} + p_\varepsilon\|f\|_{C^\alpha}) \leq \frac{p_\varepsilon}{1 - p_\varepsilon}\left(1 + \|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}\|f\|_{C^\alpha}\right)$$

Теорема тулаем исбатланды.

## 3. Тигезләмәне чишүнең якынча ысуллары

(1.1) тигезләмәсе гадәттә төгәл чишелмәгәнгә, аны чишү өчен якынча ысуллар төзергә һәм аларны нигезләргә кирәк була. Моның өчен, якынча чишелешләр төзүнең гомуми ысулы нигезендә, $n$ тәртибендәге тригонометрик күпбуыннар күплегенә тәңгәл булган $X_n$ һәм $Y_n$ астпространстволары эзлеклелеге кертелә. Моннан тыш, билгеле бер $P_n: Y \to Y_n$ операторы кертелә, якынча тигезләмә исә оператор рәвешендә болай языла:

$$P_nAx_n = P_ny, \ (x_n \in X_n, y_n \in Y_n$$

Бу тигезләмәнең төгәл чишелеше исә башлангыч, төгәл тигезләмәнең якынча чишелеше сыйфатында кабул ителә. Һәр шундый якынча тигезләмә, $P_n$ операторын сайлауга бәйле рәвештә, якынча чишелеш коэффициентла-

рын табу өчен сызыкча тигезләмәләр системасына китерелә. Хәзер исә коллокация һәм Галёркин ысулларын карыйк.

### 3.1 Коллокация ысулы

(1.1) тигезләмәсенең якынча чишелеше

$$\overline{\varphi}_n(t) = (\gamma_n, \varphi_n(t)) \epsilon \overline{C} \tag{3.1}$$

вектор-функциясе рәвешендә табыла, биредә

$$\gamma_n \in R, \varphi_n(t) = \sum_{k=1}^{n} a_k \sin kt + b_k \cos kt, \qquad n \epsilon N \tag{3.2}$$

Билгесез $\{a_k, b_k\}_{k=1}^{n}$ коэффициентлары исә (1.1) тигезләмәсенә чишелеш урынына (3.1) формуласын куеп һәм уң як һәм сул якны коллокация төеннәрендә тигезләп табылган сызыкча тигезләмәләр системасыннан табыла, ул система оператор рәвешендә болай күрсәтелә:

$$A(\overline{\varphi}_n; t_j) = f(t_j), t_j = \frac{2\pi j}{2n+1}, j = \overline{0,2n}. \tag{3.3}$$

Бу схема өчен түбәндәге теорема үтәлә:

**5 нче теорема.** Түбәндәге шартлар үтәлсен:

1) (1.1) тигезләмәсенең теләсә нинди уң як $f \in C^\alpha$ $[0,2\pi]$ функциясе өчен бердәнбер чишелеше бар;

2) Мондый вакланма чыгарылмалар булсын:

$D_{\pm}^{(\alpha)}(T(\varphi;t)) \in Lip_M \beta, 0 < \beta \leq 1 - \alpha, M = M_0 \|\varphi\|_{C_{2\pi}}$,биредә $M_0$ — $\varphi$ га бәйле булмаган уңай константа.

Ул вакытта коллокацияләр ысулы сызыкча тигезләмәләр системасының җитәрлек дәрәҗәдә зур $n$ өчен бердәнбер чишелеше була һәм ‾φ_n^* (t) якынча чишелешләренең төгәл $\overline{\varphi}^*$ чишелешләренә омтылу тизлеге мондый:

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_n^*\|_{\overline{C}} = O\left(\frac{\ln n}{n^\beta}\right) \quad (n \to \infty)$$

**Исбатлау.** Түбәндәге билгеләмәләрне китерик:

$$X_n = H_n^T \cap C_{2\pi}^0, \overline{X}_n = \{\ \overline{x}_n\}, \overline{x}_n = (\gamma_n, x_n), \gamma_n \in R, x_n \in\ X_n.$$

Лагранж тригонометрик интерполяция операторы $L_n^T: C^\alpha \to H_n^T$ дип алсак, (3.3), һәм шулай ук Лагранж күпбуынының бердәнберлеге нигезендә, табабыз:

$$A_n \overline{\varphi}_n \equiv L_n^T A \overline{\varphi}_n = L_n^T f, \overline{\varphi}_n \in \overline{X}_n, L_n^T f \in H_n^T. \tag{3.4}$$

$L_n^T$ операторы проекцион оператор булганга күрә, шулай ук $L_n^T H_n^T \equiv H_n^T$ булганга, (3.4) тигезләмәсе түбәндәге тигезләмәгә эквивалент:

$$A_n \overline{\varphi}_n \equiv G \overline{\varphi}_n + L_n^T T \varphi_n = L_n^T f \tag{3.5}$$

(3.5) тигезләмәсенең һәм башлангыч тигезләмәнең уң як функцияләре өчен түбәндәгеләр үтәлә:

$$\delta_n \equiv \|f - L_n^T f\|_{C^\alpha} = |c_0(f - L_n^T f)| + \left\|D_{\pm}^{(\alpha)}(f - L_n^T f - c_0(f - L_n^T f))\right\|_{C_{2\pi}}$$

$$= \left|\frac{1}{2\pi} \int_0^{2\pi} (f - L_n^T f)(t) dt\right| + \left\|D_{\pm}^{(\alpha)}\left(\tilde{f} - \widetilde{L_n^T f}\right)\right\|_{C_{2\pi}}$$

Биредә $\tilde{f} \equiv f - c_0(f), \widetilde{L_n^T f} \equiv L_n^T f - c_0(L_n^T f)$.

Беренче кушылучыны бәялик:

$$\left|\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}(f - L_n^T f)(t)dt\right| \le \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}|f - L_n^T f|(t)dt$$

$$\le \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left(1 + \|L_n^T\|_{C_{2\pi}\to C_{2\pi}}\right)E_n^T(f)dt = \left(1 + \|L_n^T\|_{C_{2\pi}\to C_{2\pi}}\right)E_n^T(f).$$

Лагранж операторы нормасы өчен түбәндәге бәя үтәлә:

$$\|L_n^T\|_{C_{2\pi}\to C_{2\pi}} \le \frac{4}{\pi} + \frac{2}{\pi}\ln\frac{2(2n+1)}{\pi};$$

Ул вакытта

$$\left|\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}(f - L_n^T f)(t)dt\right| \le B_1 \ln n\, E_n^T(f)\ (n \to \infty). \tag{3.6}$$

Икенче кушылучыны табабыз:

$$\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(\tilde{f} - \widetilde{L_n^T f}\right)\right\|_{C_{2\pi}} = \left\|\sum_{k=1}^{\infty}\left[D_\pm^{(\alpha)}\left(\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right)\right]\right\|_{C_{2\pi}} \le \sum_{k=1}^{\infty}\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right)\right\|_{C_{2\pi}}$$

$\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f} \in H_{2^k n}^T$ булганга күрә, бу аңлатма өчен тригонометрик күпбуыннарның вакланма чыгарылмаларның Бернштейн тигезсезлеге килеп чыга:

$$\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right)\right\|_{C_{2\pi}} \le c(\alpha)(2^k n)^\alpha \left\|\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right\|_{C_{2\pi}}.$$

Исәпләүләрне дәвам итеп, табабыз:

$$\left\|D_\pm^{(\alpha)}\left(\tilde{f} - \widetilde{L_n^T f}\right)\right\|_{C_{2\pi}} \le$$

$$\sum_{k=1}^{\infty} c(\alpha)(2^k n)^\alpha \left\|\widetilde{L_{2^k n}^T f} - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right\|_{C_{2\pi}} \le c(\alpha)\sum_{k=1}^{\infty}(2^k n)^\alpha\left(\left\|f - \widetilde{L_{2^k n}^T f}\right\|_{C_{2\pi}} + \left\|f - \widetilde{L_{2^{k-1}n}^T f}\right\|_{C_{2\pi}}\right) \le$$

$$B_2 c(\alpha)\sum_{k=1}^{\infty}(2^k n)^\alpha \ln(2^k n)\, E_{2^{k-1}n}^T(f)$$

Биредә $B_2$ — $n$ га бәйсез даими зурлык.

Теореманың икенче шарты нигезендә, $D_\pm^{(\alpha)}(\tilde{f}(t)) \in Lip_{M_1}\beta$; димәк, $\tilde{f}$ функциясе өчен $\tilde{f} = I^\alpha g \in Lip_{M_2}(\alpha + \beta)$ булырлык $g \in Lip_{M_3}\beta$ функциясе бар. Моннан һәм Джексонның беренче теоремасы нәтиҗәсеннән $f$ функциясенең иң яхшы тигез якынлыгы өчен түбәндәге бәя чыга:

$$E_n^T(f) \le \frac{12M_1}{n^{\alpha+\beta}}$$

Моны алдагы нәтиҗәгә куеп, гади, ләкин озын исәпләүләр нигезендә, табабыз:

$$B_2 c(\alpha)\sum_{k=1}^{\infty}(2^k n)^\alpha \ln(2^k n)\, E_{2^{k-1}n}^T(f) \le \frac{B_3}{n^\beta}\sum_{k=1}^{\infty}\frac{\ln(2^k n)}{2^{(k-1)\beta}} \le \frac{B_4 \ln n}{n^\beta}.$$

Ике кушылучының бәяләрен берләштерсәк, төгәл һәм якынча тигезләмәләрнең уң яклары аермасы нормасының бәясе табыла, ягъни

$$\delta_n \equiv \|f - L_n^T f\|_{C^\alpha} \leq \frac{B_5 \ln n}{n^\beta} \qquad (3.7)$$

Биредә һәм арырык, $B_i$ ($i$=1,2,…) — $n$ га бәйле булмаган даими зурлыклар.

Хәзер исә, якынча ысулларның гомуми теориясе нигезендә, $A$ һәм $A_n$ операторларының якынлыгын билгелик.Теләсә нинди $\overline{\varphi}_n \in \overline{X}_n$ өчен мондый тигезлекләр хас:

$$\|A\overline{\varphi}_n - A_n\overline{\varphi}_n\|_{C^\alpha} = \|(G\overline{\varphi}_n + T\varphi_n) - (G\overline{\varphi}_n + L_n^T T\varphi_n)\|_{C^\alpha} = \|T\varphi_n - L_n^T T\varphi_n\|_{C^\alpha}.$$

Әле генә башкарылган исәпләүләргә тиң исәпләүләр ярдәмендә түбәндәгене табабыз:

$$\|A\overline{\varphi}_n - A_n\overline{\varphi}_n\|_{C^\alpha} \leq \frac{M_0 B_6 \ln n}{n^\beta}, \text{ ягъни } \varepsilon_n \equiv \|A - A_n\|_{\overline{X}_n \to C^\alpha} \leq \frac{B_7 \ln n}{n^\beta}.$$

Теореманың 2) шарты нигезендә $T$ операторы тулаем өзлексез оператор булып тора, димәк, 1 нче теореманы да исәпкә алсак, A операторының өзлексез кире операторы бар. Шулай итеп, якынча ысуллар гомуми теориясенең төп теоремасының барлык шартлары да үтәлә:

1) $A : \overline{C} \to C^\alpha$ операторының өзлексез кире операторы бар;

2) $A\text{-}A_n : \overline{X}_n \to C^\alpha$ операторлары $n > n_0$ булганда чикләнгән, бу вакытта $\varepsilon_n \equiv \|A\text{-}A_n\|_{\overline{X}_n \to C\alpha} \to 0,\ n \to \infty$;

3) $q_n \equiv \|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}} \varepsilon_n \leq 1,\ (n \geq n_1 > n_0)$

4) $\delta_n \equiv \|f - L_n^T f\|_{C^\alpha} \to 0,,\ n \to \infty.$

Бу вакытта, җитәрлек дәрәҗәдә зур $n$ өчен, $A_n^{-1}$ операторлары бар һәм аларның нормалары болай чикләнгән:

$$\|A_n^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}} \leq \frac{\|A^{-1}\|_{C^\alpha \to \overline{C}}}{1 - q_n}$$

Шушы ук теорема буенча төгәл $\overline{\varphi}^* = (\gamma^*, \varphi^*)$ чишелешенә омтылучы якынча $\overline{\varphi}_n^*$ чишелешләре бар һәм аларның төгәл чишелешкә омтылу тизлеге мондый булачак:

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_n^*\|_{\overline{C}} = O(\varepsilon_n + \delta_n) = O\left(\frac{\ln n}{n^\beta}\right)$$

Теорема исбатланды.

## 3.2 Галёркин ысулы

$\{\psi_k\}_{k=0}^{2n} = \{1, \cos t, \sin t, \cos 2t, \sin 2t, \ldots \cos nt, \sin nt\}$ — тулы сызыкча бәйсез тригонометрик система. Якынча чишелеш, коллокация ысулындагыча, вектор-функция рәвешендә эзләнә:

$$\overline{\varphi}_n(t) = (\gamma_n, \varphi_n(t)) \epsilon \overline{C},$$

Биредә шулай ук

$$\gamma_n \in R, \varphi_n(t) = \sum_{k=1}^{n} a_k \sin kt + b_k \cos kt, \qquad n \epsilon N$$

Билгесез $\{a_k, b_k\}_{k=1}^{n}$ коэффициентлары $A\overline{\varphi}_n - f$ аермасының тригонометрик системаның беренче элементларына ортогональлек шартыннан табыла, ягъни:

$$\int_0^{2\pi} \left(A\overline{\varphi}_n(s) - f(s)\right)\psi_k(s)ds = 0, k = \overline{0,2n} \qquad (3.8)$$

Галёркин ысулының исәпләү схемасы өчен түбәндәге теорема үтәлә:

**6 нчы теорема.** Түбәндәге шартлар үтәлсен:

1) (1.1) тигезләмәсенең теләсә нинди уң як $f \in C^{\alpha}[0,2\pi]$ функциясе өчен бердәнбер чишелеше бар;

2) Мондый вакланма чыгарылмалар булсын:

$D_{\pm}^{(\alpha)}(T(\varphi;t)) \in Lip_M\beta, 0 < \beta \le 1-\alpha, M = M_0\|\varphi\|_{C_{2\pi}}$,биредә $M_0$ — $\varphi$ га бәйле булмаган уңай константа. Һәм шулай ук $D_{\pm}^{(\alpha)}(f(t) - c_0(f)) \in Lip_{M_1}\beta$ булсын.

Ул вакытта Галёркин ысулы системасы (3.8) җитәрлек дәрәҗәдә зур $n$ өчен бердәнбер чишелешкә ия һәм якынча чишелешләр $\overline{\varphi}_n^*(t)$ төгәл $\overline{\varphi}^*$ чишелешләренә мондый тизлек белән җыела:

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_n^*\|_{\overline{C}} = O\left(\frac{\ln n}{n^{\beta}}\right) \quad (n \to \infty).$$

**Исбатлау.** $X_n = H_n^T \cap C_{2\pi}^0, \overline{X}_n = \{\ \overline{x}_n\}, \overline{x}_n = (\gamma_n, x_n), \gamma_n \in R, x_n \in\ X_n$ булсын. $S_n^T: C^{\alpha} \to H_n^T$ — Фурье операторы булсын. (3.8) формуласы нигезендә түбәндәге тигезлекләр табыла:

$$a_k(A\overline{x}_n - f) = 0, b_k(A\overline{x}_n - f) = 0, \qquad k = \overline{0,n} \leftrightarrow S_n(A\overline{x}_n; t) = S_n(f; t).$$

Фурье рәте кисемтәсе күрсәтелешенең бердәнбер булуыннан чыгып, түбәндәге тигезлекләрне язарга мөмкин:

$$A_n\overline{\varphi}_n \equiv S_nA\overline{\varphi}_n = S_nf, \quad \overline{\varphi}_n \in \overline{X}_n, \ S_nf \in H_n^T \qquad (3.9)$$

$S_n$ операторы проекцион оператор булып тора, моннан тыш $S_n\ H_n^T = H_n^T$, димәк (3.9) тигезләмәсе түбәндәге тигезләмәгә эквивалент:

$$A_n\overline{\varphi}_n \equiv G\overline{\varphi}_n + S_nT\varphi_n = S_nf. \qquad (3.10)$$

Якынча ысуллар гомуми теориясенең төп теоремасындагы параметрларны исәплибез:

$$\delta_n \equiv \|f - S_n^Tf\|_{C^{\alpha}} = |c_0(f - S_n^Tf)| + \left\|D_{\pm}^{(\alpha)}(f - S_n^Tf - c_0(f - S_n^Tf))\right\|_{C_{2\pi}} = \left\|D_{\pm}^{(\alpha)}(f - S_n^Tf)\right\|_{C_{2\pi}}$$

Коллокация ысулын нигезләгәндә башкарылган исәпләүләргә аналогик исәпләүләр башкарып табабыз:

$$\delta_n \equiv \|f - S_n^Tf\|_{C^{\alpha}} \le \frac{A_1 \ln n}{n^{\beta}};$$

$$\varepsilon_n \equiv \|A - A_n\|_{\overline{X}_n \to C^{\alpha}} \le \frac{A_2 \ln n}{n^{\beta}};$$

$$\|\overline{\varphi}^* - \overline{\varphi}_n^*\|_{\overline{C}} = O(\varepsilon_n + \delta_n) = O\left(\frac{\ln n}{n^{\beta}}\right) \quad (n \to \infty).$$

Теорема исбатланды.

## Әдәбият

*Габдулхаев Б.Г.* Прямые и проекционные методы решения сингулярных интегральных уравнений 1 рода. Казань: КГУ, 1994. 245 с.

*Натансон И.П.* Конструктивная теория функций. М. — Л.: ГИТТЛ, 1949. 687 с.

*Самко С.Г., Килбас А.А., Маричев О.И.* Интегралы и производные дробного порядка и некоторые их приложения. Минск: Наука и техника, 1987. 688 с.

***Галимҗанов Әнис Фуат улы,***
*математика фәннәре кандидаты*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*функцияләр теориясе кафедрасы доценты*
*e-mail: anis_59@mail.ru*

УДК 792

***М.Г. Арсланов***

# ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНЕҢ КҮПКЫРЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ: Хөсәен Уразиковның тууына 110 ел

Статья посвящена изучению личности и творчества актера, режиссера и драматурга Х.Уразикова в контексте татарской театральной культуры. В частности, рассмотрены его творческая биография и актерская деятельность.

**Ключевые слова:** Х.Уразиков, история татарского театра, драматургия.

Уразиков Хөсәен Ибраһим улы (07. 01. 1894, Саратов губернасы Дергачев өязе Сәфәр авылы — 24. 08. 1977, Казан) — актер, режиссер, драматург, педагог, ТАССРның халык (1945), РСФСРның атказанган (1950) артисты. Ленин ордены кавалеры (1957). 1920 елда Самара драма студиясен тәмамлый. Оренбургта, Фрунзеда татар труппаларында эшли. 1923 елдан Кызыл Октябрь исемендәге татар театры актеры (хәзер Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры). Ул милли драматургия спектакльләрендә күбесенчә гади көнкүреш рольләрен башкара. Төп рольләре: Юныс Хаҗи (Ш. Камал, «Хаҗи әфәнде өйләнә»), Мулла (М. Әблиев, «Шәмсекамәр»), Мортаза бай (Ә. Фәйзи, «Тукай»), Бикәмәт (Н. Исәнбәт, «Зифа») һ.б. Режиссер булып эшли. 1944—1948 елларда Г.Камал исемендәге академия театрында художество җитәкчесе була. Куйган спектакльләре: «Данлы чор» (Т. Гыйззәт, 1937), «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт; К. Тумашева белән бергә, 1940), «Миңлекамал» (М. Әмир, 1944), «Мулланур Вахитов» (Н. Исәнбәт, 1948), «Диңгездәгеләр өчен» (Б. Лавренев, 1948), «Зифа» (Н. Исәнбәт, 1954). «Каюм Насыйри» пьесасының автордашы (М. Гали белән бергә) һ.б. 1933—1965 елларда Татар театр училищесында укыта.

Х.Уразиков — театр тарихында ныклы урын алган, бай иҗат мирасы калдырган олы шәхесләребезнең берсе. Аның исеме Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, К. Тинчурин, Г. Болгарская, Ф. Ильская, З. Солтанов, Х. Әбҗәлилов, Г. Шамуков, Ф. Халитов кебек күренекле сәхнә осталарыбызның исемнәре белән хаклы рәвештә янәшә тора.

Х. Уразиков үзенең иҗат эшчәнлеген 1920 елда Самара драма студиясендә К. Тинчурин белән З. Солтанов җитәкчелегендә башлап җибәрә. Алар Уразиковка Г. Кариев реалистик мәктәбе традицияләрендә актер, режиссер эше буенча тәүге күнекмәләр бирәләр, сәхнәдә тормыш дөреслегенә мәхәббәт, һәртөрле ялганга, штампка килешмәүчән караш тәрбиялиләр. Болардан тыш Х. Уразиков һәр ике укытучысының, актер һәм режиссер буларак, иң көчле якларын — К. Тинчуринның театральлеген, образны психологик яктан ачарга отмылышын, З. Солтановның сәхнәдән яңгыраган сүзгә аеруча игътибарын кабул итә. Соңрак алар Х. Уразиковның үз иҗат йөзен билгеләүче төп сыйфатлар булып эвереләләр.

«Г. Кариевка хатирә», Дүртенче татар бригадасы, Г. Тукай исемендәге Алма-Ата шәһәре труппаларында, Кызыл Октябрь исемендәге һәм Әс-

терхан татар дәүләт театрларында эшләгән еллар артистның үз амплуасын, мөмкинлекләрен ачыклау, иҗат йөзен, башкару үзенчәлекләрен эзләү чоры булып саналырга хаклы. Бу вакытларда уйналган Хәмзә бай (Г. Камал, «Беренче театр»), Бәдри (М. Фәйзи, «Галиябану»), Хәзрәт (С. Рәмиев, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!») һәм башка рольләр — беренче авырлыклар, зур иҗат юлының тәүге баскычлары.

Егерменче еллардагы газета-журнал мәкаләләре аша артист Уразиковның үсеш юлын шактый ачык төсмерләргә була. Аларда баштарак Бояр (Д. Юлтый, «Карагол»), Мәрди (К. Тинчурин, «Сүнгән йолдызлар»), Чалбарчы (К. Нәҗми, «Печән базары») кебек эпизодик рольләр, соңрак — әсәрләрнең төп геройлары белән янәшә куярлык Хәсән (Г. Кутуй, «Балдызкай»), Җиһанша (К. Тинчурин, «Зәңгәр шәл»), Гыйсмәт (Ә. Таҗетдин-Рахманкулов, «Боз астында упкын») кебек персонажлар турында сүз бара. Бу рольләрне башкарып, Х. Уразиков үзен ышандыру сәләтенә ия булган, кызыклы характерлар тудыра алучы шактый оста артист итеп таныта.

Х. Уразиков үсешендә К. Тинчурин әсәрләре аерым урын алып тора. «Зәңгәр шәл»дәге Җиһанша образы, мәсәлән, Уразиковның принципиаль уңышы булуы белән бергә, шул әсәрдәге икенче бер образга (Ишанга) үзенчәлекле әзерлек тә булып тоела. Нәтиҗәдә беренче тапкыр Әстерхан татар дәүләт театрында 1929 елда уйналган һәм соңыннан да берничә тапкыр яңартылган Ишан образы артист Уразиковның биографиясенә лаеклы бер бизәк буларак кабул ителә. Х. Уразиков иҗатында фикер киңлеге, сурәтләү чараларының байлыгы ягыннан Ишан белән беррәттән Мисбах хаҗи («Җилкәнсезләр»), Шакирҗан («Сакла, шартламасын») Туктамыш («Ил»), Үтәш («Кандыр буе»), Кыям («Беренче чәчәкләр») кебек образлар шактый зур урын алып торалар. К. Тинчурин әсәрләрендәге әлеге образлар Х. Уразиковка осталыгын чарларга, диапазонын киңәйтергә, үзен төрле жанрларда сынап карарга зур мөмкинлекләр тудыра, иҗади йөзен формалаштырырга ярдәм итә.

Шул ук вакытта Уразиков рус һәм чит ил классиклары әсәрләрендә дә дәвамлы рәвештә зур һәм җаваплы рольләр башкарып килә. Шулар арасыннан дөньяның күренекле сәнгать осталары уйнаган һәм Х. Уразиков тарафыннан тыенкы манерада, ләкин эчке бер кайнарлык белән башкарылган Варум (Ф. Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Левшин (М. Горький, «Дошманнар») рольләре аның өчен өлгергәнлеккә үзенчәлекле имтихан булып тора.

50 еллык сәхнә эшчәнлеге дәверендә Х. Уразиков тарафыннан барлыгы 160 ка якын роль уйналган. Шуларның Ишан, Мисбах хаҗи (К. Тинчурин, «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр»), Колый Тархан, Бикәмәт (Н. Исәнбәт, «Хуҗа Насретдин», «Зифа»), Сәмигулла (Ш. Хөсәенов, «Зөбәйдә — адәм баласы»), Левшин, Печенегов, Иван Коломийцев (М. Горький, «Дошманнар», «Соңгылар») татар артистлары тудырган иң гүзәл образлар галереясында сакланырга хаклы. Әлеге образлардан чыгып, артист Уразиков иҗатының үзенчәлекле якларын билгеләп китү зарур. Сәхнәгә революциядән соң килгән икенче буын татар артистлары вәкиле буларак, Х. Уразиковка Г. Кариев мәктәбенең реалистик традицияләрен «татар театры атасы»ның иң якын хезмәттәшләреннән кабул итү насыйп була. Шуңа күрә аның иҗатына, беренче буын татар артистларындагыча, сәхнәдә тормыш дөреслегенә тугрылык, халыкның тормыш-көнкүре-

шен, мәдәниятен аңлап эш итү, милли характер үзенчәлекләренә, кеше күңеле нечкәлекләренә тирән үтеп керә белү хас. Аның осталык диапазоны гаҗәп киң. Ул драматик яки юморга бай булган рольләрне бердәй осталык белән башкара алучы бик сирәк очрый торган артистларның бер вәкиле. Х. Уразиков иҗат иткән геройлар матур тембрлы тирән баритон тавышка, уртачадан чак кына калку нык гәүдәгә, тыенкы, ләкин гаҗәеп ышандыра алу сәләтенә, пластикага, төгәл жестка ия. Бу сыйфатлар тормышчанлык, гадилек, бөтенлек белән берлектә Х. Уразиков иҗат иткән сәхнә образларының коллектив портретын тудыралар.

Х. Уразиковның артистлык хезмәте бай һәм тирән. Ләкин аның мәдәниятебезгә керткән өлеше моның белән генә чикләнми. Х. Уразиков — халкыбыз сәнгатенә үзенчәлекле, тирән эчтәлекле спектакльләр биргән сәләтле режиссер да. Тирәннән тикшергәндә, ул куйган спектакльләрнең үз вакытында халык тормышында, ил язмышында шактый әһәмиятле урын тотканлыгы күренә. Х. Уразиков тарафыннан куелган спектакльләрнең күбесе заман темасына багышланган. «Хуҗа Насретдин», «Каюм Насыйри», «Мулланур Вахитов», «Банкрот», «Хөррият» кебек беренче карашка шул чор белән турыдан-туры бәйләнмәгән әсәрләрне дә ул чын мәгънәсендә заманча итеп куярга тырыша. Болар да Х. Уразиков иҗатында заман темасының үзенчәлекле чагылышы булып торалар. Чөнки сәхнәдә чор тамашачысын дулкынландырырлык проблемалар чагылуы, заман кешесенең уй-хисләрен кузгатырлык геройлар гәүдәләнүе кирәк. Х. Уразиков исә үткән чорларга багышланган спектакльләрендә дә әнә шуларга ирешә. Аның «Мактаулы заман», «Миңлекамал», «Диңгездәгеләр өчен», «Ялгыз каен», «Зифа», «Таң атканда», «Зөбәйдә — адәм баласы» кебек спектакльләре турыдан-туры заман проблемалары белән бәйләнгән. Боларда заманга хас конфликт, заман кешесе, зур фикерләр, җәмгыятьнең төп үсеш тенденцияләре чагыла. Х. Уразиковның режиссер буларак беренче эше — 1936 елда куелган «Мактаулы заман» турында Мирсәй Әмир: «...спектакльнең төп уңышы — бүгенге чынбарлыкны дөрес чагылдыруында, бүгенге тормышны бөтен күңеллелеге белән бирүендә, аның ягымлы кешеләрен күрсәтүендә», — дип язган иде [Әмир]. Бу сүзләрне алда саналган спектакльләрнең барысына да адреслап буладыр мөгаен.

Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман» пьесасы 1935 елда язылып, 1936 елның башында куелу өчен Татар дәүләт академия театрына алына. Аңа кадәр ул язучылар союзында укыла һәм уңай бәя ала. Бигрәк тә өлкән язучы һәм драматург Ш. Камал, язучы К. Нәҗми әсәргә югары бәя бирәләр, тизрәк сәхнәгә куярга тәкъдим итәләр. Ләкин «дистанция теориясен» һәм «саф сәнгатьне» яклаучылар пьесаны көчле тәнкыйть утына алалар, авторны натурализмда, «канатсызлыкта» гаеплиләр. Шуның нәтиҗәсе буларак театрның штаттагы режиссерларының берсе дә пьесаны куярга алынмый. Автор театр дирекциясенә әсәрне сәхнәгә куюны артист Х. Уразиковка тапшырырга тәкъдим итә. Бу тәкъдимгә режиссерлар коллегиясе дә каршы килми. Тиздән репетицияләр башлана.

«Хөсәен Уразиков, реалист артист буларак, режиссерлык эшен дә реалистик формада корып җибәрә. Ул өстәл артында сүз сөйләүдән бигрәк, артистларның үзләре белән күбрәк

шөгыльләнеп, образлар өстендә, һәр образның әсәрдә токкан роле турында практик рәвештә, сүз, фикерне тамашачыга җиткерү турында эш алып бара» [Гыйззәт, б. 268]. Т. Гыйззәтнең «Мин ничек артист һәм драматург булдым» дигән мәкаләсеннән алынган бу өзек Х. Уразиковның спектакль өстендә эшләү методын ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Иң элек Х. Уразиковның өстәл арты дәверендә артык озак булмыйча, бары образларның характерларын ачу, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, аларның спектакльдә тотачак урынын билгеләү өчен кирәк кадәр генә «утыруын» әйтергә кирәк. Һәр артист югарыда саналганнарны үзләштерү белән мизансцена стадиясенә күчә. Бу вакытта әле декорацияләр әзерләнмәгән, бары аларның урындыклардан, ширмалардан торган контурлары гына бар. Хәзер инде Х.Уразиков артистларга тулы ирек куя. Аларның образлар арасындагы эчке мөнәсәбәтләрен аң-лаудан килеп чыккан табигый мизансценаларны сайлап ала һәм «ныгыта» бара. Эш процессының барлык стадиясендә дә сүзне, фикерне тамашачыга җиткерү беренче урында тора. Х. Уразиков сүзнең драма артисты өчен иң көчле сурәтләү чарасы икәнен яхшы аңлый, шуңа һәрвакыт ачык дикция, чиста тавыш белән сөйләүне таләп итә.

Режиссерның авторны сиземләве иң элек әсәрне сәхнәгә кую планында, соңрак спектакльнең тышкы оформлениесендә чагыла. Ә мәнә ничек итеп артистларда авторны тою, ярату хисе тәрбияләргә? Бу бит аларга образларны автор уйлаганча бирү өчен һава кебек кирәк. Театр белгечләренә Х. Уразиков тарафыннан куелган «Мактаулы заман», «Зифа», «Зөбәйдә — адәм баласы» кебек әсәрләрнең, куяр алдыннан бәхәсләргә дучар булуы, рольләр бүленгәч, кайбер артистларга рольләрнең бик үк охшап бетмәве билгеле. Шуңа карамастан, спектакльләр зур уңыш белән баралар, әлеге артистлар башта яратмаган рольләрен бик яхшы башкаралар. Бу факт режиссерның артистлар коллективында авторны ярату тойгысын тәрбияли алуы турында сөйли.

Гомумән, Х. Уразиков спектакльләрендә бернинди трюк та, бернинди артык нәрсә дә булмый. Музыка, яктылык, декорацияләр — һәммәсе үз урынында, барысы бер максатка — режиссерның әйтергә теләгән фикерен тулырак ачуга — юнәлдерелгән була. Аның игътибар үзәгендә һәрвакыт артистлар, калган барлык сурәтләү чаралары аларның уенын мөмкин кадәр калкурак итеп күрсәтүгә хезмәт итәләр.

Премьера гаҗәеп зур күтәренкелек белән үтә. «Бу беренче постановкасы белән иптәш Уразиков үзенең режиссерлык эшендәге осталыгын күрсәтте» — дип яза «Кызыл Татарстан» газетасы [Әмир]. «Моңарчы Татар дәүләт академия театры тамашачыларына үзенең артистлык осталыгы белән нык күренеп килгән Х. Уразиков иптәш бу постановка белән үзенең режиссерлык осталыгын да күрсәтә алды», — дип бу фикерне куәтли «Совет әдәбияты» журналы [Ярми, б. 69].

Авыл кешеләре тормышы М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасында да яктыртыла. Ләкин, Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман» комедиясеннән аермалы буларак, бу әсәрдә Бөек Ватан сугышы чоры гәүдәләндерелә һәм авыл хуҗалыгын Миңлекамал шикелле үзен-үзе аямый торган, сәләтле, инициативалы җитәкче кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе үзәккә куела. «Миңлекамал» драмасы хәзер дә татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы

чорында тыл батырларын сурәтләгән иң көчле драма үрнәкләренең берсе булып исәпләнә. Аңа бу зур бәяне, алда әйтелгәннәрдән тыш, югары идеялелеге, гражданлык пафосына байлыгы, сәнгатьчә оста эшләнеше тәэмин итә.

Татар дәүләт академия театрына М. Әмир драманы 1944 елның башларында алып килә. Х. Уразиков әсәрне укып чыгу белән «куярга» дигән карарга килә. Әсәрнең үзәгендә Миңлекамал образы. Х. Уразиков бу рольне ике артисткага — М. Сульва һәм Г. Булатовага тапшыра. Режиссер образны «чишүгә» һәр артистның үз мөмкинлекләреннән чыгып якын килә. Шуңа күрә спектакльдә сәнгатьчә кыйммәте ягыннан бертигез булган ике Миңлекамал образы иҗат ителә. Артисткалар автор биргән төп материал нигезендә, үз мөмкинлекләреннән чыгып, үзенчәлекле ике характер тудыралар. Миңлекамал — Мәрьям Сульва йомшак характерлы, шул ук вакытта кирәк чакта үзенең теләгенә ирешмичә тукталмый торган көчле ихтыярлы хатын булып күз алдына килә. Ул тормышның әчесен-төчесен күп татыган, аның йөрәгендә ниндидер авыр кайгы бар шикелле. Һәм шул кайгы аның һәр хәрәкәтендә, һәр сүзендә чагылган төсле. Сульва-председатель авыл хуҗалыгын тирәннән белә, төптән уйлап эш итә торган кеше булып хәтердә кала. Шулар өстенә Миңлекамал-Сульвада тагын гаҗәеп бер тыйнаклык, басынкылык бар.

Миңлекамал-Булатова исә җиңелрәк, дәртлерәк, күбрәк интуициягә таянып эш итүчән, шуңа карамастан үз сүзендә нык торучан, көчле ихтыярлы хатын булып гәүдәләнә. Миңлекамал-Булатованы райком секретарена китергән сәбәпләрнең дә көчлерәге, бәлки, акылга караганда, дуамал хисләредер. Юкка гына бит аны авылда «Җенлекамал» дип атамыйлар.

Гомумән алганда һәр ике артистка әйткән сүзен таш яуса да үти торган, үз көченә нык ышанган, авырлыклар алдында югалып калмый, җитәкче буларак көчле оештыру сәләтенә ия булган, эшли һәм эшләтә белүче булдыклы татар хатыны — дәүләт эшлеклесе образы тәкъдим итәләр.

«Миңлекамал» спектакле премьерасы зур күтәренкелек белән үтә. «…Бүгенге бөек сугыш чорындагы тыл темасына гаять актуаль булган «Миңлекамал» пьесасы автор Мирсәй Әмирнең дә, аны рекордлы кыска срокта сәхнәгә куйган режиссер — Татарстанның атказанган артисты Хөсәен Уразиковның да, бөтен театр коллективының да уңышы», — дип бәяли спектакльне «Кызыл Татарстан» газетасы [Иделле]. Бу фикерне «Красная Татария» газетасы да куәтли: «Автору пьесы «Миннисамал» М. Амиру и Татарскому академическому театру удалось создать волнующий спектакль о сегодняшней татарской деревне. Основа успеха в том, что автор и театр задались целью показать действительность правдиво, глубоко, во всей ее сложности, без лакировки» [Гаккель].

Бер уңайдан уңышның икенче сәбәбен дә күрсәтеп китик. Ул — режиссер Х. Уразиковның яшь драматургны тирәнтен аңлап, әсәрне тулы канлы сәхнә образларында чагылдыра алуы. Спектакльдә барлык артистлар да тигез уйныйлар. Драматургик материалның яхшы сыйфатлы булуы һәм аны сәхнәдә гәүдәләндерүнең сәнгатьчә дөреслеге уңышның төп нигезе булып тора.

Әйтелгәнчә, бу анализланган ике спектакль режиссер Уразиковның заман темасын чагылдырган әсәрләре үрнәге. Ләкин «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт әсәре, режис-

сер К. Тумашев белән бергә куелган), «Каюм Насыйри» (М. Гали һәм Х. Уразиков әсәре), «Мулланур Вахитов» (Н. Исәнбәт), «Банкрот» (Г. Камал), «Хөррият» (М. Әмир) кебек беренче карашка агымдагы чор белән турыдан-туры бәйләнмәгән әсәрләрне дә Х. Уразиков чын мәгънәсендә заманча итеп куярга тырыша. Билгеле булганча, әсәрнең заманчалыгын сурәтләнгән вакыйгаларның безнең көннәрдә баруы гына билгеләми. Иң мөһиме — сәхнәдә бүгенге тамашачыны дулкынландырырлык проблемалар чагылуы, заман кешесенең уй-хисләрен кузгатырлык геройлар гәүдәләнүе кирәк. Режиссер Уразиков әлеге әсәрләрне сәхнәгә куйганда әнә шундый принциплар нигезендә эш итә.

Х.Уразиков — татар театры өчен бик тә традицион булган реалистик режиссура вәкиле. Аның мондый программасы газета-журнал мәкаләләрендә, радио, телевидение чыгышларында атап әйтелмәгән. Ләкин ул — реализмны көндәлек тормышта, турыдан-туры спектакльләр кую процессында пропагандалаучы. Шуңа күрә аның әсәрләре, тышкы яктан караганда да, «нәкъ тормыштагы кебек». Тамашачы алдында һәрвакыт диярлек дүртенче стенасы алынган гадәти йорт яки иксез-чиксез files ераkларга китеп югалучы, йөрәккә якын табигать күренеше. Аларда — тормыштагы кебек көн һәм төн, яз һәм җәй, көз һәм кыш алышынышы. Бу шартларда «яшәүче» кешеләр дә табигый сөйләшәләр, тормыштагыча хәрәкәтләнәләр. Күренә ки, режиссерның һәр сурәтләү чарасы: декорация, яктылык, музыка, реквизит, бутафория, театраль шау-шулар — барысы да сәхнәдә кешене, аның эчке дөньясын, уй-кичерешләрен, хисләрен мөмкин кадәр калкуырак гәүдәләндерүгә юнәлдерелгән. Әлеге принцип бүгенге көн режиссурасында яңадан алгы планга чыкты. Димәк, Х. Уразиков режиссурасы да актуальлеген югалтмаган.

Х. Уразиковның драматургия, театраль педагогика өлкәсендәге хезмәтләре дә җитди игътибарга лаек. Ул тәрҗемә иткән «Икмәк», «Гаҗәеп эретмә» (В. Киршон әсәрләре, русчадан) «Йөрәк серләре» (Б. Рахманов, үзбәкчәдән), үзе генә һәм Ш. Сарымсаков белән бергә инсценировкалаган «Тау чәчәге» (М. Ибраһимбеков), «Сәүбәновлар» (К. Нәҗми, «Язгы җилләр»), М. Гали белән берлектә язган «Каюм Насыйри» әсәрләре үз вакытында сәхнәбездә шактый уңыш белән барганнар. Ул тәрбияләгән артистлар әле бүген дә Республика театрларында уңышлы эшләп киләләр.

**Әдәбият**

*Әмир М.* Мактаулы заман // Кызыл Татарстан. 1936. 3 март.

*Гаккель Е.* Минникамал // Красная Татария. 1944. 17 мая.

*Гыйззәт Т.* Әсәрләр: 4 томда. Казан, 1978. IV т. 268 б.

*Иделле Г.* «Миңлекамал» пьесасы турында // Кызыл Татарстан. 1944. 10 май.

*Ярми Х.* Уңышлы адым // Совет әдәбияты. 1936. № 3. 69 б.

***Арсланов Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы,***
*сәнгать фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*театр һәм музыка сәнгате бүлеге җитәкчесе*

УДК 811.512.145′342

*Ш.Н. Асылгәрәев*

# ШӘЕХГАТТАР ИМАНАЕВ — ТАТАР СӨЙЛӘМ АВАЗЛАРЫНЫҢ ЯСАЛЫШЫН ҺӘМ ЯҢГЫРАШЫН ТӨГӘЛ ФӘННӘР КАНУННАРЫНА НИГЕЗЛӘП ӨЙРӘНГӘН ГАЛИМ

В статье рассматривается одно из направлений научной деятельности разностороннего ученого Ш. Иманаева, а именно появление и образование звуков речи в результате деятельности центральной нервной системы и органов речи по законам физики. Ученый на основе многочисленных примеров демонстрирует различные изменения звуков в процессе речи. Появление и образование звуков человеческой речи рассматривается в трех аспектах: акустическом, биологическом и лингвистическом.

**Ключевые слова:** фонетика, звук, звуки речи, звуковая система, акустика, органы слуха, звуковые сигналы, тон, артикуляция, речевой аппарат, сингармонизм.

Татар телен, шул исәптән аның фонетикасын фәнни өйрәнә башлауга былтыр 235 ел тулды. Ул С. Хәлфиннең русларга татар телен өйрәтү өчен әзерләгән «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов...» исемле дәреслеге белән башланып китә. Китап 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә басылып чыккан. Шуннан соң бу өлкәдә 22 ел буе тынлык хөкем сөрә, басылып чыккан мәкаләләр дә, дәреслекләр дә, китаплар да күренми. Ә менә XIX гасырга аяк баскач, татар телен русларга һәм, татарлардан тыш, бүтән милләт вәкилләренә өйрәтүне күздә тотып, дистәләгән татар грамматикалары һәм үзөйрәткечләр дөнья күрә. Аларда, әлифба өйрәтүгә бәйле рәвештә, фонетика бүлегенә дә урын бирелә. Ләкин авторларның күбесе фонетика предметын бик примитив, чиктән тыш гадиләштереп бирәләр, әйтергә теләгәннәрен аңлата, хәтта аваз белән хәреф төшенчәләрен аерып күрсәтә алмыйлар. Дөрес, әлеге төшенчәнең аермасын белеп, сизеп эш итүчеләр дә булган. Бу бигрәк тә И. Гиганов, Г. Фәезханов, К. Насыйри хезмәтләрендә ачык күренә.

Татар фонетикасы XX йөзгә кергәч зур үсеш кичерә. Мәсәлән, татар теленең аваз составын, аларның төзелешен, үзгәрешләрен өйрәнүгә багышланган йөзләрчә мәкаләләр, дәреслекләр һәм зур күләмле монографик хезмәтләр нәшер ителде. Шулар арасында 1910 елда «Бәянелхак» газетасы типографиясендә басылган «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» исемле китап аерым игътибарга лаек. Чөнки ул, яңа гасырга аяк баскач, татар телен өйрәнүгә багышланган беренче фәнни хезмәт булган. Аның авторы — Шәехгатттар Хәсән улы Иманаев.

Укучыда хаклы рәвештә шундый сорау туарга мөмкин: кем ул Шәехгаттар Иманаев? Урынны күп алмас өчен, Исмәгыйль Рәми белән Рәис Даутовларның Ш. Иманаев турында «Әдәби сүзлек»тә бирелгән язмаларын китерү белән чикләнергә туры килә.

«ИМАНАЕВ Шәехгаттар Хәсән улы (1875—1939) — юрист, филолог, җәмәгать эшлеклесе. Элекке Казан губернасы, Алабуга өязе, Тирсә авылында ахун гаиләсендә туа. Баш-

та Уфа гимназиясендә, аннан Казан гимназиясендә укый. 1897 елда Казан университетының юридик факультетына кереп, аны 1891 елда тәмамлый. 1901—1902 елларда университетның тарих-филология факультетында да белем ала. Озак еллар Казанда шәһәр судьясы булып эшли, коллежский асессор чины белән отставкага чыга. 1911 елны дәгъва вәкиле (адвокат) хокукы ала. 1913—1914 елларда «Хокук вә хәят» исемле журнал чыгара. Ш.Иманаев — «Бәянелхак» газетасының соңгы редакторы» [Рәми ... , 107 б.].

Боларга өстәп тагын шуларны әйтергә мөмкин. Шәхес культы чоры шаукымы Ш.Иманаевны да читләтеп үтмәгән. 1933 елда аны кулга алалар һәм, ике ел дәвам иткән тикшерүләрдән соң, «Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе»нең актив әгъзасы булуда һәм шул контрреволюцион оешманың Казандагы филиалын җитәкләүдә гаепләп, 1935 елда өч елга Себергә сөргенгә сөрәләр. Срогын тутырып Казанга кайткач та, аның тормышы җайланмый, өстеннән яла ягулар дәвам итә.

Ш. Иманаев 1939 елда (64 яшендә) Казанда вафат була. Үлгәннән соң 59 ел үткәч, 1998 елның 21 октябрендә ул РФ Законы нигезендә Татарстан Республикасы прокуратурасы карары белән аклана. Ш. Иманаевның тормышы һәм иҗатына караган кайбер мәгълүматлар «Гасырлар авазы» («Эхо веков», 2002, № 1/2, с. 126—138) журналында да урнаштырылган.

Хәзер Ш. Иманаевның югарыда телгә алынган «Татар теленең нәхүе вә сарыфы»на әйләнеп кайтыйк.

Галим бу хезмәтенә зур өметләр баглаган, аның телчеләр һәм зыялылар тарафыннан танылуын теләгән. Ләкин авторны куандырырга, шат-



ландырырга ашкынып торучылар гына табылмаган, китап басылып, шактый гомер узганнан соң гына, ул күренекле рус галиме, танылган шәрык телләре белгече Н.Ф. Катановның зур бәясен алган. Ни кызганыч, татар тел белгечләре һәм зыялылары аны автор үзе исән вакытта да, үлгәннән соң да күрмәгәннәр, китап уңай яктан да, кире яктан да үз бәясен алмаган, әйтерсең андый хезмәт язылмаган да, басылып та чыкмаган. Ул хәтта 1910 елдан соң матбугатта басылган һәр язмага, һәр дәреслеккә һәм китапка үз фикерен әйтеп, үз бәясен биреп барган Г.Ибраһимов игътибарыннан да читтә калган.

Китапның күләме зур түгел — нибарысы 102 бит. Ул керештән (мөкатдимә) һәм өч бүлектән (фонетика, морфология, синтаксис) тора. Бу мәкаләдә хезмәткә тулаем анализ ясау максат ителми, бары тик аның фонетикага караган өлеше турында гына сүз алып барылачак. Сәбәбе хезмәтнең яртысы дип

әйтерлек фонетикага багышланган булуда гына да түгел, бәлки фонетика законнарының фәнни итеп бирелүендә, фәнни итеп тасвирлануында.

Хәзерге тел белемендә сөйләм авазы өч аспекттан чыгып карала. Моның сәбәпләрен «Татар грамматикасы» авторлары болай аңлата:

«Авазлар системасы ул бик катлаулы күренеш, һәм аны өч аспекттан чыгып карарга кирәк.

Аваз берәмлекләренең ясалуы сөйләм органнары идарә итүче үзәк нерв системасының функциясе булганга күрә, авазлар кеше организмы эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе буларак каралалар. Бу — артикуляцион (яки биологик) аспект. Икенчедән, табигатьтәге теләсә нинди тавыш кебек үк, сөйләм авазлары да нинди дә булса җисемнең тирбәнүе нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, ягъни физик күренеш булып торалар, бусы аларның акустик (яки физик) аспекты була. Һәм, өченчедән, алар төрле мәгънәви берәмлекләрне (сүз, морфема һ.б.) оештыралар, ягъни аралашу, фикерләребезне белдерү өчен хезмәт итәләр, моннан исә аларның өченче иң мөһим аспекты — лингвистик (яки функциональ) аспекты килеп чыга» [Татар грамматикасы, 1998, б. 64].

Бу аспектлар Ш. Иманаев хезмәтендә дә бар. Галим, татар телчеләреннән беренче булып, авазларның барлыкка килүен, ясалуын һәм аларның үзгәрешләрен физика законнарына һәм сөйләм органнары, үзәк нерв системасы эшчәнлегенә нигезләп аңлата.

**Акустик (яки физик) аспект**

Автор, башта ук физика законнарына нигезләнеп, тавыш барлыкка килү күренешен аңлатуны кирәк саный. Китабының 6-7 нче битләрендә дөньядагы һәрбер әйбернең һава белән чормап алынуы турында әйтә. Һаваның үзенә генә хас үзлеккә ия булуын да искәртә, ягъни һава әйбернең кеше күзе күрә алмый торган урыннарын да чормап ала. Һава чормап алган берәр яңгыравыклы әйбергә суксак, ди автор, бу әйбернең халәтендә үзгәреш барлыкка килә. Шушы үзгәреш нәтиҗәсендә әйберне чормап алган һава дулкынлана һәм дулкыннар тирә-якка тарала. Әлеге дулкыннар иң элек кешенең сизү, тою органы булган колак яфрагына килеп җитә, чөнки колак яфрагы тавыш дулкыннарын җыя һәм аларны тышкы ишетү юлына юнәлдерүгә ярдәм итә. Аннан соң дулкын, тышкы ишетү юлы аша узып, колак пәрдәсенең (Ш.Иманаев аны «колак анасы» дип бирә. — *Ш.А.*) тирбәнүен китереп чыгара. Бу тирбәнүләр эчке колак рецепторлары тарафыннан нерв импульсына күчәләр һәм ишетү нервысы буйлап баш миенә тапшырылалар. Бу күренешне галим болай тасвирлый: «Ошбу үзгәреш инсанның сизү коралларыннан колак анасын (пәрдәсен) хәрәкәтләндерә һәм инсанның да һушына әсир (тәэсир. — *Ш.А.*) кыйла һәм ишиянең (әйбернең) халәтендә тәгъйир (үзгәреш) булганлыгын инсанның гакылы аркылы инсанның үзенә белдерә. Ошбу сугылганнан соң колак анасы белән һава аркылы шәйнең (әйбернең) халәтендәге тәгъйирне һис кылдырган нәрсәне тавыш диләр» [Иманаев, 1910]. Физика фәне галимнәре «тавыш — дулкын ул», дип өйрәтәләр [Кикоин, 1995, б. 178]. Бу хакыйкатьне Ш.Иманаев та нәкъ аларча аңлаган, ул да сөйләм авазы белән табигатьтәге тавышның барлыкка килүендә бернинди дә аер-

ма күрмәгән. Автор һәр әйбернең, нинди генә формада, нинди генә рәвештә булмасын, катымы ул, сыеклык яисә газ хәлендәме, тавыш биргәндә барсының да дерелдәве, үзенең халәтен (рәвешен) үзгәртүе турында яза.

Тавышлар төрле була. Кеше сызгыруны барабан кагудан, ирләр тавышын хатын-кыз тавышыннан җиңел аера. Димәк, тавыш билгеле бер үзлекләргә ия. Шуларның берсе — тавыш көче, ягъни тавышның яңгырау көче, катылыгы. Тавышның бу үзлеген Ш.Иманаев ике телеграмм баганасы арасына сузылган тимер чыбык мисалында аңлата. Әгәр «тимер чыбыкка суксак, — ди галим, — ул чыбык (—) өскә таба бөгелер, дуга яисә салават күпере кеби бер хәлгә килер . Аннан соң кире иске хәленә кайта башлар һәм кайтып җиткәч, туктый алмыйча, ошбу рәвешчә түбәнгә бөгелер, һәм чыбык ничек югары таба бөгелсә, шулай ук түбәнгә бөгелер, һәм бөгелүе арткан саен тавышының куәте артыр. Мәсәлән, ярты ай хәтле бөгелсә, чирек ай хәтле бөгелгәндәгегә караганда тавыш куәтлерәк булыр» [Иманаев, б, 7] Һәм, фикерен дәвам итеп, тугызынчы биттә болай яза: «Тавыш коралының бер мәртәбә бөгелүенең зурлыгына карап тавышның куәте үзгәрә һәм тавышны куәтләндереп әйтүгә, сугу, диелә» [Иманаев, б. 9]. Димәк, Ш.Иманаев тавыш көченең (куәтенең) тирбәлеш амплитудасына бәйле булуын яхшы аңлаган. Чөнки амплитудасы зур булган дулкынның тавышы көчле, куәтле була.

Тавыш тоны. Бер төрле тавышларны түбән тонлы, икенчеләрен югары тонлы тавышлар дип йөртәләр. Бу — тирбәлешләр ешлыгына бәйле. Хәзер Ш. Иманаевның үзен тыңлап карыйк: «Әйбернең бөгелүенең зурлыгыннан гайре бер секундта ничә мәртәбә бөгелгәне дә тавышка тәэсир итә. Ул чакта тавышның катылыгына (түбәнлегенә) яисә нечкәлегенә (югарылыгына) сәбәп була» (Иманаев, б. 7). Кыскасы, хезмәтнең авторы тавышның тонын тавыш дулкынындагы тирбәлешләр ешлыгына бәйләп карый, һәм дөрес эшли. Чөнки югары тонлы тавышка тирбәлешләрнең зуррак ешлыгы, түбән тонлы тавышка, киресенчә, тирбәлешләрнең азрак, кимрәк ешлыгы туры килә. Бу хакыйкать Ш.Иманаев чорында да, хәзер дә шулай аңлатыла.

Ләкин табигатьтә барлыкка килгән һәр дулкынны да кеше колагы тавыш рәвешендә кабул итми. «Ошбу тавыш пәйдә булсын өчен, — дип яза Ш.Иманаев, — бер секундта дулкынлау хисабы бер йөздән бер меңгә (100—1000) хәтле булырга тиеш. Ул чагында әйбер тугрысындан гарәпләр әйтәләр «сан» дип, ягъни кычкырды, тавыш, аваз бирде, дигән сүз була... Әгәр әйбернең дерелтәве бер секундта бер йөздән ким булса, ул вакытта чиста аваз (тон) булмый...» [Иманаев, б. 7]. Тавышның таралу тизлеге турында галим болай ди: «Тавыш яктылыктан акрынрак китә. Тавыш һавада бер секундта 332,5 метр китә. Һәм суда, һәм чуенда шәбрәк китәр» [Иманаев, б. 7].

## Артикуляцион (яки биологик) аспект

Бу аспектны аңлату өчен Ш.Иманаев сөйләм аппаратының һәм анда урнашкан органнарның (автор аларны кораллар дип атый. — *Ш.А.*) рәсемен (сурәтен) бирә. «Инсанның авызыннан чыккан тавышлардан (авазлардан) сүз вә җөдә килсен өчен ошбу коралларның хәрәкәтләнүе зарур буладыр» [Иманаев, б. 27], — ди

дә, аларны санап чыга: әүвәл — тын ала торган әгъза, икенче — бугазның югары кыйсмендәге тавыш чыга торган тишек — бушлык, өченче — каты аңкау һәм йомшак аңкау (кече тел), дүртенче — түбән теш казнасы, бишенче — хосусый тавыш кораллары (ирен, теш, тел һәм борын).

Тавыш (аваз) барлыкка китерүдә төп рольне бугазның кимерчәкләре арасында урнашкан тавыш ярылары (китапта «ике эчке каты» дип бирелгән. — *Ш.А.*) уйный, дип әйтүе белән автор хаклы әлбәттә. Ул тавыш ярыларының өч төрле торыштагы сурәтләрен китерә [Иманаев, б. 26]. Беренче рәсемдә тавыш ярыларының бер-берсеннән ераклашкан моменты сурәтләнгән, чөнки кеше сөйләмәгәндә тавыш ярылары бер-берсеннән ерагаялар һәм шул вакытта иң зур тавыш ярыгы хасил була. Бу күренешне һәм анда бара торган процессларны галим болай сурәтли: «Гадәти тын алганда һава авыз, бугаз аркылы үпкәгә керә һәм шул ук юл белән чыга. Ошбу тын алган вакытта керүе дә, чыгуы да бер вакыт эчендә дәвам кыйла һәм бу вакытта бугазның мәзкүр ике эчке каты берсе-берсеннән аерылып, берсе-берсенең каршысында тыныч тора һәм бу вакытта һава буш кереп, чыгып йөри» [Иманаев, б. 28]; икенче рәсемдә тавыш ярыларының бер-берсенә якынлашкан, хәтта орынып торган моменты сурәтләнгән, чөнки кеше сөйләшкәндә, шулай ук, җырлаганда да тавыш ярылары якынаялар, үпкәләрдән чыга торган һава басымыннан алар бик тиз тирбәнә башлыйлар. Хезмәттә бу күренеш болай тасвирланган: «Әмма ләкин инсанның халендә шул чак була ки, һава алганда бу мәзкүр бугазның ике каты берсе берсенә тиеп китә һәм ул чагында... тавыш пәйда була. Ошбу актык җайда мәзкүр ике корал (тавыш ярылары. — *Ш.А.*) берсе берсенә тиеп тора һәм дерелти һәм ошбу җайда үпкәгә кергән һаваның чыгу дәвамы керү дәвамына бәрабәр булмас... Әгәр мәзкүр ике каты берсе берсенә тыгыз тиеп, тартылып торсалар, үпкәдән чыга торган һава аларга бәрелеп, аларны тибрәтер. Ошбу вакытта мәзкүр тибрәнүнең куәтенә карап йә авазлы, йә авазсыз тавыш (йә сузык, йә тартык аваз. — *Ш.А.*) пәйда була. Өченче рәсемдә тавыш ярылары кешенең шыпырт яисә пышылдап сөйләшкән моментын күрсәтәләр. Бу вакытта тавыш ярылары арасындагы ярык сөйләшкән вакыттагыга караганда киңрәк (зуррак), тик торгандагыга, сөйләшмәгән вакыттагыга караганда таррак (кечерәк) була.




Галимнәр үткәргән тәҗрибәләр күрсәткәнчә, тавыш ярылары бер секунд эчендә 80 нән алып 10 000 гә кадәр тирбәнеш ясый алалар» [Цузмер, б. 110]. Әмма тавыш ярыларында барлыкка килгән тавышның сөйләм авазы булып формалашуы өчен, тавыш ярыларының тирбәнүе белән беррәттән, сөйләм органнарының да хәрәкәтләнүләре һәм билгеле бер торышны алулары шарт. Чөнки кешенең сөйләм авазлары тел, иреннәр, аскы казналык торышы үзгәргәндә йоткылыкта, йоткылык өсте куышлыгында, авыз

һәм борын куышлыкларында гына тәмам формалашып җитә.

Ш. Иманаев, чын зыялы, укымышлы кеше буларак, бу хакыйкатьне яхшы аңлаган һәм авазларны әйткән вакытта сөйләм органнарының нинди торыш алуларын күрсәтеп биргән. Бу хакта ул болай дип яза: «Һәрбер тавышны әйткәндә авыз төрлечә ачылыр, түбәнге теш казнасы төрлечә күтәрелеп, төрлечә төшерелер. Мәсәлән, «а» тавышын әйткәндә, авызны әйләндереп алган тел буыны хәрәкәтләнүе буенча, түбән теш казнасы түбәнгә төшә, авыз киң ачыла. Шуңар күрә моңар ачык аваз дип әйтелүе урынлы. «А» тавышын әйткәндә, авыз киң ачылып, тел белән иреннең хәрәкәтләнүе сизелми. Әгәр авызны тар итеп ачып, тел уртасын аңкауга якынлаштырсак, «ы» тавышы пәйда була» [Иманаев, б. 29]. Автор, шул рәвешчә, хезмәтенең 29—33 битләрендә һәр авазның ясалу урыны, анда катнашкан сөйләм органнары һәм аларның торышлары турында шактый киң һәм тулы мәгълүмат бирә.

Укучыларның күпчелеге Ш. Иманаев хезмәтеннән хәбәрдар булмауны исәпкә алганда, аларны үзгәрешсез, оригиналдагыча китерү, укучы өчен кызыклы һәм файдалы булыр. Менә алар:

«У» тавышы әйтелгәндә иреннәр тарая, алга таба чыгарыла һәм берсе берсенә кырыйлары белән генә тиеп тора, авыз тар ачылып, телнең иң төбе күтәрелә;

«Ә» тавышы ачык «а» белән тар «и» араларында була... «Ә» тавышын әйткәндә телнең уртасы аңкау мөнәсәбәтчелегендә хәрәкәтләнә;

«И» авазы тел уртасы белән әйтелә һәм йомшак әйтелгәндә тел очы түбән тешләргә тиеп тора;

«Ы» (кымыз) авыз тар ачылыр, телнең төбе белән уртасы арасындагы кисәге аңкауга тия, мәсәлән, кыска кеби;

«Э» (е) (кеше, эз) авыз тар ачылып, урта тел аңкауга якынрак булыр;

«О» (соло) дигәндәге җайда телнең уртасы белән төбе арасындагы кисәге хәрәкәтләнер;

«Ө» (көзгө) дигәндәге авазны әйткәндә телнең уртасы хәрәкәтләнер һәм ирен очлайтып әйтелер.

Авазсыз тавышлар (тартык авазлар. — *Ш.А.*) әйтелгәндә кайсы орылып әйтелер, мәсәлән, «ф» кеби, кайсы кырт киселеп, өзелеп әйтелер, мәсәлән, «п» кеби, кайбер тавышларны әйткәндә ирен йомылып, кысылып әйтелә, мәсәлән, «п», «б», «м», яисә түбәнге ирен югаргы тешләргә якынлашыр, мәсәлән, «ф», «в» тавышларын әйткәндәге кеби. Ирен хәрефләре икегә бүленә: ике ирен белән әйтелә торган, мәсәлән, «м» һәм ирен-теш белән әйтелә торганнарга, мәсәлән, «в», «ф» кеби.

«П», «б», «м» тавышлары әйтелгәндә ике ирен белән әйтелер, әйтелгән чагында иреннәр икесе дә берсе берсенә тыгыз тиеп, бөтенләй йомылып торырлар. Бу тавышларны каты әйтелгәндә тел хәрәкәтсез була. Әгәр йомшак әйтелсәләр, телнең уртасы аңкауга якынлаша.

«Ф», «в» авазлары рус лөгатеннән алынган. Бу аваз ирен һәм теш белән әйтелә. Кече тел азрак күтәрелгән «ф» тавышын әйткәндеге кеби. Әмма «ф» тавышыннан тәгауте (аермасы) шул булыр ки, «ф» авазы саңгырау аваз булыр, «в» авазы яңгырый торган аваз булыр һәм урта яңгырау белән яңгырар. Рус кагыйдәсе буенча фамилия артыннан куела, мәсәлән, ڤا (ва) яисә يڤا (ева) дип. Иреннәр «ф»ны әйткәнгә караганда катырак берсе берсенә якынлашыр һәм һава көч белән чы-

гар. Бу тавышлар дәхи каты һәм йомшак та әйтелер. «Ф», «в» каты әйтелгәндә, түбәнге ирен югаргы тешләргә якынлаша, тел хәрәкәтсез була. Әгәр йомшак әйтелсә, түбәнге ирен югаргы тешләргә якынлашканнан гайре телнең уртасы аңкауга якынлаша.

«Җ» авазын әйткәндә телнең урта һәм алдагы кисәге хәрәкәтләнә һәм, «и» авазын әйткәндәгегә караганда, аңкауга якынырак тиеп тора. Каты әйтелгәндә тел очы югаргы тешләргә якынлаша, йомшак әйткәндә түбән тешләргә тия».

Әйткәндә аңкауга мөнәсәбәте булган авазлар, дип автор түбәндәгеләрне күрсәтә: «Телнең аңкауга мөнәсәбәтчелеге ошбу кыяфәттә булыр: тел аңкауга очы белән тия, мәсәлән, «т» тавышын әйткәндә; телнең уртасы белән, мәсәлән, «и» тавышын әйткәндә, ك (к) тавышын әйткәндә телнең түбе белән әйтелә. Кайбер хәрефләрне әйткәндә тел очы югары теш казнасына тия, мәсәлән, «з», «н», «л», «т», «д» тавышларын әйткәндәге кеби...

Телнең алгы кисәге «ш», «ж», «р» тавышларын әйткәндә теш өстендәге каты аңкауга тия. Тел түбе ике төрле хәрәкәтләнә: ул үзенең иң тирәндәге кисәге белән, мәсәлән, «а», «у» тавышларын әйткәндә, икенче үзенең өстәгерәк кисәге белән, мәсәлән, «ы» (кымыз) тавышын әйткәндә. گ (г), ک (к), خ (х) тавышларын әйткәндә тел уртасы тавышны йомшаграк итеп әйтергә сәбәпче була. Мәсәлән, сез дигәндәге س (с) авазы кеби.

Борын «ң» тавышының мәхрәҗе (ясалу урыны) була. «Ң» тавышы борын белән йомшак та һәм каты да әйтелер. Йомшак аңкау яисә кече тел булмаса, инсанның тавышы стакан тавышына бәрабәр булыр иде. Кече тел аңкауга тими, борын юлын капламый, гадәти хәлендә булса, авыз һәм борын белән әйтелә торган «м», «н» хәрефләре пәйда була. Калган җайда (вакытта, очракта. — *Ш.А.*) күтәрелеп, борын юлын каплап, аңкауга тыгыз тиеп торса, һава авыздан чыгып, авыз хәрефләре пәйда була».

Шушында авазларның артикуляциясен китерүне туктатып тору урынлы булыр, чөнки алар бик күп. Ш.Иманаев татар телендә тугыз сузык, 34 тартык аваз саный. Сузыклары белән килешергә кирәк, чөнки алар хәзерге татар әдәби телендәге сузык авазлар белән тәңгәл киләләр. Әмма 34 тартык авазның барысы да татар теле авазлары түгел, аның дистәгә якыны гарәпнеке. Укучылар хәтерлидер, узган гасырның 30 нчы елларына кадәр безнең бабайлар гарәп хәрефләренә нигезләнгән әлифбадан файдаландылар. Аңа (татар әлифбасына) гарәп авазларын язуда күрсәтә торган барлык хәрефләр дә кертелгән иде. Нәтиҗәдә, татар язуы өчен һич хаҗәте булмаган, бәлки бер үк хәрефнең төрле-төрле вариантлары рәвешендә йөргән, дистәгә якын чит, ят хәреф кулланылды. Шуңа күрә, хәзерге татар әдәби теленә мөнәсәбәте булмаган ул авазларның артикуляциясен китерүнең һич кирәге юк дип санарга кирәк.

Татар теленә сингармонизм законы хас. Аның ике төре бар — рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Гарәп хәрефләренә нигезләнгән татар язуында бу закон сакланмаган һәм саклана да алмаган. Чөнки татар теленең тугыз сузык авазын язуда бирү өчен өч кенә сузык аваз хәрефе булган: ا (әлиф), و (уау) һәм ى (йа). Ул чорда, сүзнең калын яисә нечкә әйтелүе сузыкларга бәйле түгел, бәлки тартыкларга карап йөри, дип исәпләгәннәр. Шуңа күрә тартык-

ларны икегә бүлеп йөрткәннәр — каты (тәфхим) әйтелешле һәм йомшак (тәркыйк) әйтелешле авазлар.

Ш.Иманаев, татар телчеләреннән беренче булып, татар телендә рәт гармониясе булуын таный һәм аны мисаллар белән дәлилли. Хезмәтнең 23 нче битендә ул болай яза: «Әгәр бер сүзнең әүвәлге иҗеге йомшак булса һәм калган иҗекләре дә йомшак булыр. Сүзнең әүвәлге иҗеге каты булса һәм калган иҗекләре дә каты булыр. Ошбу галәмәт татар лөгатенең табигатеннән булып, мәсәлән, гарәп лөгатендә булмас һәм гарәп лөгатендә әүвәлге иҗек, мәсәлән, каты булып, икенче иҗек йомшак булуы мөмкин» [Иманаев, б. 23]. Фикерен дәлилләү өчен ул түбәндәге мисалларны китерә: «Кайчан асыл (төп, тамыр. — *Ш.А.*) иҗектә «а» авазы булса, иттикак кыйлынмыш (ясалган, төрләнгән сүз. — *Ш.А.*) сүзләрдә очрый: «а», «ы», «у», мәсәлән «бар»дан алынган: барган, бару, барды. Әгәр асыл иҗектә «ә» булса, мөштәкат сүзләрдә булыр «ә», «ү», «е» (э): бәрмәк — бәр — бәрү — бәрде. Асыл иҗектә «и» авазы булса, мөштәкат сүзләрдә «ә», «е» (э), «ү»: кил — килә — килү — килде. Асыл иҗектә «у» булса, мөштәкат сүзләрдә «а», «у», «ы» була: бул — була — булды — булган. Асыл иҗектә «ү» булса, мөштәкат сүзләрдә «ә», «е» (э), «ү» була: үлмәк — үл — үлә — үлде — үлү.

Кайчан асыл иҗектә «о» авазы булса, мөштәкат сүзләрдә була: «ы» — «а», «у». Ормак — ор — орды — орган — ору, ороп тормак — тор — торды — торган — тору — тороп. Кайчан төп иҗектә «ө» торса, мөштәкат сүзләрдә «ә», «ү», «е» (э), «ө» була. Көлмәк — көлә — көлде — көлү — көлгән — көлөп» [Иманаев, б. 25—26]

Укучы игътибар иткәндер, китерелгән мисаллар арасында ирен гармониясенә туры килә торганнары да бар, бигрәк тә асыл иҗектә о — ө сузыклары торган сүзләрдә. Ләкин ни гаҗәп, кайбер сүзләрнең (ороп тормак, тороп, көлөп) язылышында ул закон сакланган, икенчеләрендә (торды, көлде) юк. Автор бу хакта үзе бернәрсә дә язып калдырмаган.

Сингармонизмга иллюстрация рәвешендә китерелгән мисаллардан күренгәнчә, татар телендә рәт гармониясе асыл (төп, тамыр) иҗектәге сузык авазга мөнәсәбәттә карала. Асыл иҗекнең сузык авазы калын булса, калган иҗектәге сузык авазлар да калын була һәм, киресенчә, асыл иҗекнең сузыгы нечкә булса, калган иҗектәге сузык авазлар да нечкә була. Шуңа күрә Ш. Иманаевны татар телендә иҗек ясалу, аның төзелеше һәм төрләре мәсьәләләре битараф калдырмаган, ул аларга шактый урын биргән.

Галим татар телендә иҗек ясалу процессын сөйләм органнары эшчәнлегенә бәйләп аңлата һәм ул күренешне болай тасвирлый: «Тавыш авазлы булсын, авазсыз булсын — аны әйткәндә тавыш кораллары өч хәлгә төшә:

Әүвәл — тавыш коралы тыныч, хәрәкәтсез хәленнән тавышны әйтер өчен кирәк булган хәлгә таба хәрәкәтләнә башлый. Икенче — ул хәлгә җиткәч, берничә микъдар тавыш чыккан арада тик тора, ягъни хәлен үзгәртми. Өченче — кораллар, тавыш әйтелгәннән соң, тыныч хәлгә төшәләр, кире әүвәлге хәлләренә кайталар. Әгәр авазсыз тавыш артыннан авазлы тавыш барса, ул чагында җамдәнең (тартык авазның. — *Ш.А.*) өченче хәлендәге тыныч хәлгә кайтуы булмый, ләкин саутиянең (сузык авазның. — *Ш.А.*)

әүвәлге хәлендәге хәрәкәсе белән бергә кушыла һәм җамдә саутия белән тыгыз тоташлы әйтелә һәм бу гадәд мотәһәррәк (хәрәкәләр саны буенча) җамдәдән гыйбарәт булган сауте пәйда була. Ошбу берничә тоташкан һәм берсе берсе белән нык бәйләнгән авазны һәҗа яисә гавам телендә иҗек дип әйтерләр. Мәсәлән: «ак», «кара» дигән сүзләрдә берәр иҗек, «кымыз» дигәндә ике иҗек — «кы» һәм «мыз» һәҗаләре бардыр (кара дигән сүз дә ике иҗектән тора, бу очракта автор хаталанган. — *Ш.А.*). Иҗек сүзнең озынлыгына карап йөридер. Бинаән галәиһи кайбер сүздә бер иҗек була, кай сүздә — ике. Өч яисә дүрт иҗек сирәк була. Һәр бер иҗектә бер авазлы тавыш булырга кирәк, чөнки хруф саутиясез иҗек булмас, хруф җамдәсез булса да» [Иманаев, б. 20—21].

Хәзерге тел белемендәге иҗек турындагы өйрәтүләрне Ш.Иманаевныкы белән чагыштырып карасак, без аларда аерма күрмәбез. Мәсәлән, «Татар грамматикасы» авторлары иҗек турында түбәндәгечә язалар: «Иҗек — сөйләмнең иң кечкенә әйтелеш берәмлеге, аның элементлары акустик яктан да, артикуляцион яктан да бик тыгыз береккән булалар. Татар телендә иҗекнең мәҗбүри элементы булып сузык аваз тора. Ул иҗекнең үзәген тәшкил итә» [Татар... , б. 87].

Ш.Иманаев татар телендә иҗекне өч төргә бүлә: гадәти кыска, озын һәм йомык. Гадәти кыска иҗектә сузык аваз кыска була, — ди галим. Мәсәлән, кеше сүзендәге «е» авазы. Озын иҗектә сузык авазның озын булуын искәртә. Мәсәлән, күрү, үсү, кумак сүзләрендәге «ү», «у», «а» авазлары. Йомык иҗектә аваз саны өч булып, авазлы тавышның (сузык авазның) уртада килүе мәҗбүри.

Автор сүздә бер иҗек төп рольне үти дигән фикер үткәрә һәм бу иҗекне — асыл иҗек яисә сүзнең тамыры дип атый: «Һәрбер шәйнең (әйбернең) үзенең бер асыл төбе булдыгы кеби һәм сүзнең дә үзенең бер төбе, асылы була. Ошбу төп — төп иҗек яисә сүзнең тамыры, дип атала. Мәсәлән, караган — карады — карамыйнча дигән сүзләрдә «кара» ике иҗектән гыйбарәт булып, сүзнең тамыры дип атала» [Иманаев, б. 22].

Сүз ике яки аннан да күбрәк иҗекләрдән торса, аларның берсе башкалардан аерылыбрак әйтелә. Аеру функциясен басым (китапта «сугу» дип бирелгән. — *Ш.А.*) үти, яки иҗекләрнең берсе басымлы була. Ш. Иманаев фикеренчә, басымлы иҗекнең сузык авазы бераз сузылыбрак әйтелә. Ләкин бу әлеге аваз башкалардан һәрвакыт озын була дигән сүз түгел, дип искәртә автор. Бу турыда ул үзе болай яза: «Һәрбер сүз һәҗадән йә һәҗаләрдән гыйбарәт һәм шул мәзкүр һәҗаләрне һәр сүздә берсе берсеннән аерырга тиеш буладыр. «Кумак» дигән сүздә әүвәлге һәҗа озын тавышлы «ку» булып, аның озынлыгы «у» тавышының табигатеннән була. Икенче һәҗа дәхи озын була — مٯ̃ (мак). Әмма «мак» сугу (басым) аркасында озын булып укыла. «Сугу» сурәт тәләффыз шивә лисанны күрсәтә һәм сугылган һәҗа куәтлерәк итеп сугыбрак әйтелә. Мәсәлән, «кумак»та «а» һәм «ору»да «у» куәтләндерелеп, сугылып әйтеләләр һәм «кумак»ның «у» тавышы озын булса да, «а»га караганда кыскарак әйтелер. Авазның озынлыгы, назарият ягыннан, ап-ачык нәхү вә сарыф рәвешләреннән күренә. Мәсәлән, قوّا (куа) = قووا

(куyа). Һәрбер авазлы тавыш сугылырга кадәр булса да, һәрбер сугылган авазлы тавыш озын булырга кадәр булып бетмәс, ягъни «сугылган» да «озын» да гамәлиятчә мәдле (озын) булып әйтелсәләр дә. Әүвәл — назарият ягыннан, мәсәлән, кеше дигәндәге «е» тавышы үзенең табигатенә һәм тарихына бинаән озын була алмас һәм икенче гамәлдә сугылган һәҗа куәтлерәк әйтелер... Сугу күбесенчә актык һәҗагә туры килер. Әмма әүвәлге һәм икенче һәҗагә дә туры килер: кеше (актык), былтыр (беренче), балтыр (икенче), укыт (әүвәлге)» [Иманаев, б. 22—23].

Ш.Иманаевны татар язуының камил булмавы борчый һәм бу кимчелекләрнең, җитешсезлекләрнең сәбәпләрен түбәндәгеләрдән күрә. Беренчесе — сузык авазларны язуда күрсәтү өчен сузык аваз хәрефләренең җитмәве, икенчесе — язу кагыйдәсенең (имляның) камил булмавы. Әлеге җитешсезлекләр турында ул китабының сүз башында ук язып куйган. Алар белән укучыны таныштыру да урынлы булыр. «Бу көнгәчә татарлар язуында тавышлы авазларны күрсәтә торган хәрефләр барысы да истигъмал (куллану) кыйлынмаганының зур уңайсызлыгы мәгълүмдер. Әүвәл тавышлы аваз булмаганда, тавышсыз авазлардан гына һәҗадәге хәрәкәт санисе вә гайре авазлы тавышларны чыгарып укып булмый. Мәсәлән, قصز (сызык), بر (бер) кеби. Икенче — шундый сүзләр бар ки, авазларның хәрефе төрлечә языла. Мәсәлән, ئولگان (үлгән), كوزگو (көзгә), صولو (соло) кеби. Өченче яктан, кайбер авазларның хәрефе йә бөтенләй язылмый, мәсәлән, كشى (кеше) ди-гәндәге «к» хәрефе артындагы тавыш кеби, йә бүтән бер аваз хәрефе белән күргәзелә. Мәсәлән, шул ук كشى дигәндәге «ш» хәрефе артындагы һәм مينيكى (минеке) дигәндәге «н» вә «к» артындагы һәм صولو ‘ كوزگو дигәндәге «с», «к», «г» хәрефләре артындагы авазлар кеби» [Иманаев, б. 4].

Галим татар язуындагы кимчелекләрнең сәбәпләрен күрсәтеп кенә калмый, аларны бетерү юлларын да тәкъдим итә. Моның өчен, аның фикеренчә, һәр зыялы кеше әйтелештәге аваз белән язылыштагы хәреф аермасын белергә тиеш. Автор бу сорауга үзе үк дөрес җавап та бирә. «Кәлимә яисә сүз тәләффыздa (әйтелештә) тавышлардан гыйбарәт буладыр. Мәсәлән, аққа дип әйтсәк, бу сүзнең а-қ-қ-а тавышларыннан гыйбарәт булуын күрәбез. Тәләффызда әйтелгән тавышның кәгазьдә язылган сурәте — хәреф дип аталадыр. Мәсәлән а-қ кеби» [Иманаев, б. 6]. Ш.Иманаев авазларны (тавышны) икегә: ишетелеп авазлы булып әйтелә торган тавышларга (сузык авазларга) һәм авазсыз, ягъни ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелә торган тавышларга (тартык авазларга) бүлеп карый [Иманаев, б. 6].

Ш.Иманаев алфавитта һәр тавышның үзенә генә хас билгесе булырга һәм һәр тавышның язуда аерым хәреф белән күрсәтелергә тиешлеген әйтә. Әйтеп кенә дә калмый, ул да, К.Насыйри кебек, гарәп графикасы җирлегендә сузык авазлар өчен өстәмә билгеләр системасын эшли. Шулай итеп, К.Насыйридан соң, татар телчеләре арасыннан Ш.Иманаев татар телендә тугыз сузык аваз булуын исбатлый һәм аларны үзе эшләгән билгеләр белән практик рәвештә язып та күрсәтә. Искәрмә рәвешендә әйтик, К.Насыйри татар телендә 10 сузык аваз саный, ләкин Ш. Иманаевта ул тугыз. Керәшен татарлары өчен

миссионерлар төзегән «Азбука» китапларында да һәм 1998 елда нәшер ителгән «Татар грамматикасы»нда да алар тугыз дип биреләләр.

«Татар теленең нәхүе вә сарыфы»нда татар теленең а — у — и авазлары элеккечә آ (элиф), او (уау), اى (йа) хәрефләре белән күрсәтелгәннәр, калган алты авазны бирү өчен түбәндәге билгеләр алынган:

1. Әүвәлгесе — آنى (әни), آتى (әти), آنكاى (әнкәй) дигән сүзләрдәге — (ә) авазы.

2. Икенче аваз — اوسكان дигәндәге әүвәлге авазлы тавыш. Моны او хәрефе өстенә һәмзә куеп أو дип күрсәтелер.

3. Өченче аваз шулдыр ки — قمز (кымыз) дигән сүзне әйткәндә ишетелер. Бу тавышны язуда күрсәткәндә, тавышсыз авазның хәрефе астына һәмзә куелыр ء дип. Әгәр бу тавыш башта ишетелсә, мәзкүр һәмзә элиф хәрефе астына куелыр — إ дип. Актыкта ишетелсә, ى (йа) хәрефе астына куелыр — ئ — дип. Мәсәлән, إق تاماغى (Ык тамагы), قِلغان (кылган) кеби.

4. Дүртенче тавыш — كشى (кеше) дигәндәге авазлы тавыш булыр. Бу авазны гарәп лөгатеннән алынган аст исемендә мәгълүм булган кәсрә тавышының хәрефе белән күрсәтелер. Әгәр бу тавыш башта ишетелсә, — اِ һәм актыкта ишетелсә, ىِ белән күрсәтелер. Мәсәлән, كشى (кеше), انِى (эне) кеби.

5. Бишенче тавыш — صولو (соло) дигәндәге тавыш булыр. Бу тавыш و (уау) өстенә замма و куелып күрсәтелер — وُ дип.

6. Алтынчы тавыш — كوزگو (көзгә) дигәндәге тавыш булыр һәм гарәптән алынган و белән күрсәтелер. Бу аваз тәләффызда әйткәндә гарәп кәлимәсенең замма тавышына охшашлы булып әйтелә. Бу тавышның хәрефен و белән язу лазим. Мәсәлән, كۇزگۇ (көзгә) дип язу лазим [Иманаев, б. 8—9].

Галим хезмәтенең 38 нче битендә сузык авазларга тагын бер кат игътибар итә һәм аларның язудагы хәрефләрен мисаллар белән күрсәтә:

آ (а) – آلفان– آقچا – آغاچ – آلما – آق.

اَ (ә) – اَدابلىِ – اَز .

او (у) – اورام – اوطِردِم – اوقو.

اُو (ү) – اُولگان – اُوسكاَن .

إ (ы) – قِمِز – قِز – قِل – قِلغان – قِلچ.

وُ (о) – صوُلوُ – طوُردِم – اوُرلِق – صوُصقِچ – قوُلاق – قوُلاق.

ـُـ (ө) – كـُزگـُ – كـُمُش .

اِ (е//э) – كِشىِ – ايكىِ – مِندىِ – تِلدىِ – بِزنىِ – سِزنىِ .

اى (и) – ايدِل – تيراَن – مى – نى – اَتى – اَنى.

(Иманаев, б. 38).

Сузык авазлар автор тарафыннан үзләре икегә бүленгәннәр: «1) а, у, ы, о — каты авазлы диелерләр, чөнки аларның авазлары каты булып чыгар. 2) ә, ү, е (э), ө авазлары йомшак диелерләр, чөнки мәзкүр авазлар йомшак булып чыгар» [Иманаев, б.10]. Хәзерге татар әдәби телендә беренчеләрен — калын, икенчеләрен нечкә сузык дип йөртәләр.

«Татар теленең нәхүе вә сарыфы»нда автор тагын бер бүленеш күрсәтә. Мәсәлән, а, у, ә, и, ү авазларын ул ачык авазлар, о, ө, ы, е (э) авазларын саңгырау авазлар дип бирә.

Ш. Иманаев, инде алда әйтелгәнчә, татар телендә 34 тартык аваз саный һәм аларның хәрефләрен (аерым торганда) болай күрсәтә:

ا ب ت ث ج ح خ د ذ ر ز س ش ص ض ط ظ
ع غ ق ك ل م ن و ه (ە) ى چ پ ژ ڭ گ ۋ

[Иманаев, б. 12].

Галим, башка татар телчеләре кебек, тартык авазларны калынга һәм нечкәгә бүлеп карамый, аларның ка-

лын яисә нечкә әйтелүләре сузык авазга бәйле, ди. «Болар урынында һәм авазлы тавышка карап калын да һәм нечкә дә булып укылалар» [Иманаев, б. 13]. Тартык авазлар, хәзерге татар әдәби телендә кабул ителгәнчә, яңгырауларга — д, б, г, ў һәм саңгырауларга т, п, к, бүленгән.

Татар телендә аваз үзгәрешләре һәм язу кагыйдәләре (имля) мәсьәләләре дә автор игътибарыннан читтә калмаган, урыны һәм җае туры килгән саен ул аларга тукталган һәм үз фикерен әйтә барган.

Аңлашыла ки, Ш. Иманаев татар теле фонетикасын фәнни өйрәнә башлауга үзеннән зур өлеш керткән, бик күп күренешләр, закончалыклар турында башлап сүз әйтүче дә ул булган. Кызганычка каршы, үз вакытында татар зыялылары, татар телчеләре аның хезмәтеннән тиешенчә файдаланмаганнар, аңа тиешенчә игътибар итмәгәннәр. Ышанасы килә, киләчәктә бу гаделсезлеккә чик куелыр, Ш.Иманаевның «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» китабы татар грамматикаларының тарихын язганда галимнәребезгә ышанычлы чыганак булып хезмәт итәр.

## Әдәбият

*Иманаев Шәехгаттар.* Татар теленең нәхүе вә сарыфы. Казань: Типография газеты «Баянуль-хакъ», 1910. 102 б.

*Рәми Исмәгыйль, Даутов Рәис.* Әдәби сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

*Кикоин И.К., Кикоин А.К.* Физика. Урта мәктәпнең 9 нчы с-фы өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 1995. 205 б.

Татар грамматикасы. Өч томда. I т.—Мәскәү-Казан: Инсан-Фикер, 1998. 510 б.

*Цузмер А.М., Петришина О.Л.* Биология. Кеше һәм аның сәламәтлеге. Урта мәктәпнең 9 нчы с-фы өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 1995. 262 б.

***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*гомуми лингвистика бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 7.03

***Р.Р. Солтанова***

# ТӨРКИ СӘНГАТЬ БЕЛЕМЕНЕҢ КӨНҮЗӘК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

## (Казакъстан сәнгаткәрләре тәҗрибәсеннән)

В статье на примере Казахстана рассматриваются актуальные проблемы тюркологического искусствознания. Сделан обзор исследований в области изобразительного и декоративного прикладного искусства, музыки, театрального искусства и хореографии. В центре внимания проблемы поиска национальной идентичности, изучения базовых основ тюркского искусства, этнокультурных традиций в современном искусстве.

**Ключевые слова:** тюркологическое искусствознание, национальная идентичность, этнокультурные традиции, межкультурный диалог.

Сәнгать белеме өлкәсендә эзләнүләрнең заманча этабы милли һәм мәдәни тәңгәллек проблемаларына бәйле методологик карашларны эзләү активлыгы һәм сәнгать үсешенең традицион булмаган формаларын ачыклау белән характерлана. Бу яктан караганда төрки сәнгать белеме хәзерге сәнгать үсеше юнәлешләреннән иң үзенчәлеклесе булып санала. Ул элеккеге Советлар Союзының төрки республикаларында (Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстанда) соңгы ике дистә елларда аеруча активлашты [Акилова, с.152—161].

Тарихи вакыйгаларның үзенчәлекле үсеш кичерүенә, табигый һәм мәдәни процессларның үзгәлегенә, этник культураларның бер-берсенә йогынты ясавына карамастан, халкыбызның хәзерге сәнгатендә тагын да зуррак игътибарны һәм тирән өйрәнүне таләп итә торган уртак проблемалар шактый әле.

2014 елның 25—28 май көннәрендә ТР ФА Г. Ибрагимов иемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бер төркем хезмәткәрләре Алматыда булып кайттык. Казакъстан сәнгать белгечләре белән түгәрәк өстәл артына җыелып фикер алышканда төрки халыкларның сәнгати культурасын теоретик, методологик яктан, дөньяга караш проблематикасы югарылыгыннан өйрәнүнең яңа ракурслары ачыкланды; ирешелгән казанышларны бергәләп бәяләү, идеяләр белән уртаклашу һәм хезмәттәшлекне тагын да тирәнәйтү зарурлыгы билгеләнде.

Казакъстан тикшеренүчеләренең дә игътибар үзәгендә, бездәге кебек үк, төрле аспектларда чагылыш тапкан милли традицияләр проблемасы тора. 1980 нче елларның икенче яртысыннан башлап (бигрәк тә бәйсезлек елларында), борынгы тамырларыбыз, рухи культурабыз нигезләрен, милли характердагы үзенчәлекләрне тирәнтен аңлап фикер йөртү мөһимлеге калкып чыкты.

Казакъстанның тасвирый сәнгате белән танышу безне шундый нәтиҗәгә китерде: сәнгатьтә милли алымнарга мөрәҗәгать итүне традицион сәнгать, традицион культура эволюциясендә өзелмәс чылбырның

дәвамы дип кабул итәргә кирәк. Аның үзәген традицион поэтиканың тирән мәгънәсенә нигезләнгән образлы-пластик бербөтен концепция тәшкил итә, һәм ул XX гасырның иҗади казанышлары белән синтезланган (берләштерелгән). Моның белән бәйле рәвештә һөнәрчелекнең, декоратив-гамәли сәнгатьнең (келәм туку, зәркәнчелек, күн сәнгате) нәфис бизәкләү телен, формаль-пластик үзенчәлекләрен (колорит, композицион чишелеш) генә түгел, ә дөньяның аларда гәүдәләндерелгән художестволы сурәтен (картинасын), сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен өйрәнүгә үзеннән-үзе кызыксыну уяна.

Сәнгать белеме өлкәсендә фәнни тикшеренүнең бүгенге этабы методологик карашларның яңа теоретик вариантларын эзләүне актуальләштерде һәм, әйтергә кирәк, соңгы ике дистә ел эчендә төрки сәнгать белеме сизелерлек үзгәрде. Бу күренеш Казакъстан сәнгать белеме үсешендә бөтен тулылыгы белән раслана. Бу өлкәне фәнни яктан тикшеренүчеләр һәм сәнгаткәрләр үзләренең милли тәңгәллекләрен эзләү юлында төрки сәнгатьнең борынгы (база) нигезләренә, бүгенге сәнгатьнең этномәдәни традицияләренә мөрәҗәгать итәләр.

Р. Ергалиева тикшеренүләренең үзәгендә, мәсәлән, казакъларның тасвирый сәнгатендә «аңның этнокоды, кыйммәтләр системасы, кешене, табигатьне һәм дөньяны кабул итү» чагылышы үзенчәлекләре белән бәйле мәсьәләләр күтәрелгән [Ергалиева, 2011].

Автор Казакъстанда профессиональ сәнгатьнең катлаулы үсеш юлларын этник традицияләр белән бәйле контекстта өйрәнә, аларда казакъ халкының традицион фикерләү һәм сәнгатьчә кабул итү принципларының чагылышын ачыклый.

Этномәдәни архетиплар (иң тәүге образлар) системасындагы эпик башлангычны Р. Ергалиева болай дип аңлата:

«Константный этнический код традиционного сознания, уходящее истоками в казахский героический эпос. На примере живописи и скульптуры показано взаимодействие двух типов культур: этнического типа сознания и образного мышления со спецификой профессиональных видов изобразительного искусства, которое во многом сформировало самобытное уникальное лицо художественной школы Казахстана». Автор билгеләп үткәнчә, гасырның социаль тетрәнүләргә дучар булуына карамастан, Казакъстанның профессиональ сынлы сәнгатендә халыкның борынгыдан килгән рухи, этник кыйммәтләре нык саклана. Автор шундый мөһим нәтиҗә ясый: «в казахской культуре действует механизм духовной преемственности с этнической традицией, который способствует сохранению самобытной национальной культуры казахов на разных витках ее исторического развития» [Ергалиева, 2011].

Казакъстан осталары иҗатында авангард сәнгате идеяләрен хуплау үзенчәлеге Хәлимә Хәмит кызы Труспекованың «Авангардные идеи XX века в живописи и актуальном искусстве Казахстана» дигән монографиясендә [2011, 376 с.] чагылыш таба. Светлана Кобжанованың «Мировые художественные традиции в развитии живописи Казахстана (1930—1980-е годы)» [Алматы, 2012. 164 с.] хезмәтендә Казакъстан сынлы сәнгатенең дөньякүләм традицияләре һәм Казакъстан сәнгатендә классиклар һәм авангардчылар күтәрелеп чыгуның төп этаплары эзлекле итеп яктыртылган.

Коллегаларыбыз белән якыннан аралашу исбатлаганча, сәнгать, сәнгать культурасы — болар мәдәниятара диалоглар белән тыгыз бәйләнгән. Алар бер-берсенең йогынтысын чагылдырып кына калмыйлар, ә һәркайсы үзе мәдәниятара аралашуга этәрә. Икенче бер мәдәниятне хөрмәт итү, толерантлык, диалогка бару һәм хезмәттәшлек шул халыкның мәдәниятен яхшы белгән очракта гына мөмкин, бер үк вакытта бу үзара тиңдәшлекне дөрес аңлауга ачкыч та.

Казакъ галимнәре, Казакъстанда яшәүче халыкларның тасвирый сәнгатен өйрәнеп, бу юнәлештә күләмле фәнни тикшеренү эшләре алып баралар. Әйтик, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Ергалиева, 2012 елдан башлап, «Казакъстандагы уйгур художниклары иҗатында этник янәшәлек» «Казакъстанның хәзерге художниклары иҗатында сәнгати синтез традицияләре», «Хәзерге уйгур художниклары иҗатында инновация һәм мәдәни ядкәрьләр» дигән темалар өстендә эшли.

Казакъстанда яшәүче алманнарның (немецларның) сәнгать проблемаларын Р.И. Каргабекова тикшереп өйрәнә. Казакъстандагы әрмән художникларының сынлы сәнгатен һәм скульптурасын, Казакъстандагы әрмән рәссамнарының Библия сюжетларын А.Б. Кенжакулова өйрәнә.

Д.С. Шәрипова Казакъстан сәнгать мәктәбе үсешенә өлеш керткән татар рәссамнары (Б. Урманче, З. Кадыйров, К. Шәяхмәтов, Б. Табиев, К. Муллашев һ.б.) иҗаты өстендә эшли. Аның тикшеренүләре «Татарстан рәссамнары биобиблиографик сүзлеге»нең татар диаспорасы вәкилләренә багышланган бүлеген тулыландырачак. Әйтергә кирәк, бу уртак проектның перспективасы гаять зур, аны тормышка ашыру максатында архивларда, китапханәләрдә, музейларда һәм башка мәдәният учреждениеләрендә безне зур эшләр көтә. Шушы максаттан чыгып, музейда булганда Б. Урманченың Казакъстан чоры буенча өстәмә мәгълүматлар да тупладык. М.Ауэзовның мемориаль музее даими экспозициясендәге һәм А.Кастеев исемендәге дәүләт музеендагы 1940 нче елларда Б.Урманче тарафыннан иҗат ителгән картиналарны фотога төшердек. Рәссам Алпысбай Казгуловның шәхси коллекциясендә дә аның сынлы сәнгатькә һәм графикага караган 4 картинасына тап булдык.

Мәдәниятара диалоглар активлашуда белем дәрәҗәсенең югарылыгы, культура өлкәсендә үзара элемтәләрнең көчәюе, мәдәни вакыйгалардан хәбәрдар булу зур әһәмияткә ия. Б. Урманче картиналарының төп нөхсәләре урын алган М. Ауэзов музее эшчәнлеге, шулай ук А. Кастеев исемендәге дәүләт музее фондлары һәм даими экспозициясе белән танышуыбыз да шушы максаттан чыгып тормышка ашырылды. Музей ишек алдында, ачык һавада оештырылган скульптуралар күргәзмәсендә катнашучылар белән турыдан-туры сөйләшү мөмкинлегенә ия булдык. Скульпторлар «Казан — төрки дөнья башкаласы» кысаларында 1914 елның июлендә башкалабызда оештырылган симпозиум белән дә бик теләп кызыксындылар. 3 скульптор алда торган симпозиумнарда катнашырга теләк белдерделәр.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, Казакъстанның бүгенге тасвирый сәнгате күп төрле художестволы стильләрне һәм юнәлешләрне берләштергән мозаик киңлектән гыйбарәт. Бу — музей экспозиция-

ләрендә дә чагылыш тапкан. Моны музей тарафыннан оештырылган хәзерге заман скульптурасы күргәзмәсе дә раслый.

Казакъстанда булганда халык сәнгате проблемалары һәрчак игътибар үзәгендә булуына төшендек. Менә берничә ел инде Республика һөнәрчеләренең «Шебер» конкурсы оештырыла. Эчтәлеге белән сирәк очрый торган (уникаль) мондый конкурс «Казакъстанда һөнәрчелек үсеше һәм халык һөнәрчеләре иҗатын торгызу» («Развитие ремесел и возрождение народных художественных промыслов в Казахстане») программасы кысаларында 2009 елдан гамәлгә кертелгән булган һәм ул «OUR HERITAGE» иҗтимагый фонды, ФЕЦА (Үзәк Азиянең Евразия фонды) белән берлектәге «Шеврон» компаниясе, ЮНЕСКО, Казакъстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Казакъстандагы АКШ илчелеге химаясе белән оештырыла. Конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүче-лауреатлар әсәрләренең каталогы нәшер ителә. Конкурс халык осталары арасында киң популярлык яулаган һәм мәдәният өлкәсендәге иң кызыклы вакыйгалардан санала. «OUR HERITAGE» фонды рәисе, оештыручыларның берсе Айжан Беккулова бу конкурсны уздыру тәҗрибәсе белән уртаклашып, Татарстандагы шундый конкурсларда катнашырга теләген белдерде.

Безнең игътибарны театр сәнгате өлкәсендәге күренекле галимнәрнең бәйсезлек елларында сәхнә сәнгатенә багышланган хезмәтләреннән тупланган җыентыклар җәлеп итте. «Казахское сценическое искусство. Период независимости» [Алматы. 2009. 488 с.] дигән коллектив монографиядә профессиональ сәхнә сәнгате үсешенең бәйсезлеккә ирешкәннән соңгы этаплары яктыртылган. Китапта милли сәхнә сәнгатенең төрле жанрлары һәм формалары (драма, опера, балет, бүгенге хореография) үсеше мәсьәләләре күтәрелгән, аларга хас художество-эстетик үзенчәлекләр ачыкланып билгеләнгән. «Театры городов Астаны и Алматы» һәм «Областные театры периода независимости» дигән монографияләрдә башкаладагы һәм регионнардагы театрларда казакъ сәхнә сәнгатенең бүгенге торышы, аларның үсеп китү юнәлешләре һәм үзенчәлекләре анализлана. Авторлары — күренекле театр белгечләре Кундакбайулы Багыбек, Сания Кабдиева, Аманкелди Мукан, Гөлнар Нумасейтова һ.б.

«Идея независимости и театральное искусство» [2011, 416 с.] дигән коллектив монографиядә дәүләт бәйсезлеген саклау төп, мөһим төшенчә буларак карала. Аның «Идея независимости в произведениях на фольклорной основе» һәм «Идея независимости в исторических драмах» дигән бүлекләрендә бу идеянең театр сәнгатендә — профессиональ театр барлыкка килгән вакыттан башлап, хәзерге заманның яшь режиссерлары һәм балетмейстерлары сәхнәләштергән әсәрләрдә гәүдәләнеше тасвирлана.

Р. Жумасеитованың «Хореография Казахстана. Период независимости» [Алматы, 2010, 220 с.] китабында балет труппалары һәм Дәүләт бию академия театры үрнәгендә милли хореография үсеше тенденцияләре фәнни тикшереп анализлана. Хезмәт, шулай ук, бүгенге заман биюләрен куюда катнашкан яшь коллективлар эшчәнлеген дә колачлый. Анда балет фестивальләренә, кон-

курсларга күзәтү ясала; хореография өлкәсендә кадрлар әзерләүнең бүгенге торышы ачыклана.

Безнең өчен музыкаль сәнгать өлкәсен өйрәнүче галимнәр тәҗрибәсе дә зур әһәмияткә ия. Аерым алганда, «Музыка тюркского мира» [Алматы, 2009] дигән монографиядә Татарстан музыка белгечләре (Г. Сәйфуллина, Г. Гобәйдуллина, Э. Каюмова) мәкаләләре дә урын алган. Бу хезмәттә, традицион музыканың төп жанрлары белән беррәттән, музыкаль археология проблемалары, дини даирәдә (системада) традицион музыка, музыкаль культураларның үзара бер-берсенә йогынтысы, шулай ук музыкаль төркичелектә методология мәсьәләләре күтәрелә.

Казакъстанның әйдәүче галимнәре милли сәнгать һәм драматургия өлкәсендә дә җитди эзләнүләр алып баралар. Сәнгать белеме һәм сәнгать проблемалары мәсьәләләре шулай ук Казакъстанда нәшер ителә торган вакытлы басмаларда яктыртылып бара. М.О. Ауэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институты 2005 елдан бирле «Керуен» дигән фәнни һәм әдәби-публицистик журнал чыгара, сәнгать белгечләре катнашында «Памятники истории и культуры Казахстана» дигән фәнни җыентык (җаваплы редакторы — Р.А. Ергалиева) басыла. Бу басмаларда безгә дә катнашырга тәкъдим булды.

Командировкада вакытта сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү буенча төп уку йорты — Т. Жургенов исемендәге Сәнгать академиясе эшчәнлеге тәҗрибәсе белән танышу мөмкинлеге насыйп булды. Академиянең театр, тасвирый сәнгать, хореография өлкәсендәге укытучылары белән түгәрәк өстәл артында сөйләшү, фикерләшү уздырылды. Театрларда эшләүче танылган рәссамнар Т. Сулеев, К. Халыков сценографлар әзерләү тәҗрибәсе һәм киләчәккә планнары белән уртаклаштылар. Киләчәктә Татарстанда уздырыла торган Халыкара «Нәүруз» фестивале кысаларында казакъ осталары күргәзмәсен уздырырга һәм «Төрки театр рәссамнары» («Художники тюркских театров») дип аталган уртак проектта казакъ коллегаларыбызның да катнашуын тәэмин итәргә килештек.

Казакъстанлылар белән танышуыбыз М.Ауэзов исемендәге Республика драма театрында Ж. Ергалиевның «Кас кагыл…» («Миг») дигән метафизик трагедиясен (режиссеры — Е. Нурсултан, сәхнә рәссамы — Е. Туяков) карау белән төгәлләнде.

**Әдәбият**

*Акилова К.Б.* К проблеме национальной идентичности в современном искусстве тюркских стран на постсоветском пространстве // Творчество Баки Урманче и актуальные проблемы национального искусства: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 115-летию со дня рождения Б.И. Урманче, Казань, 21—22 февраля 2012 года. С. 152—161.

*Ергалиева Р.Р.* Этническое и этическое в искусстве Казахстана. Алматы, 2011.

*Ергалиева Р.Р.* Этническая составляющая в творчестве уйгурских художников Казахстана. 2012.

*Жумасеитова Г.* Хореография Казахстана. Период независимости. Алматы, 2010.Идея независимости и театральное искусство / коллектив авторов. Алматы, 2011, 416 с.

Казахское сценическое искусство. Период независимости. Алматы. 2009. 488 с.

*Кобжанова С.* Мировые художественные традиции в развитии живописи Казахстана (1930—1980-е годы). Алматы, 2012.

Музыка тюркского мира. Алматы, 2009.

*Труспекова Х.Х.* Авангардные идеи XX века в живописи и актуальном искусстве Казахстана. 2011.

Хореография Казахстана. Период независимости. Алматы, 2010.

***Солтанова Рауза Рифкат кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе*

УДК 745

***Д.И. Әхмәтова***

# ӘСТЕРХАН ӨЛКӘСЕНЕҢ ҮЗЕШЧӘН РӘССАМНАРЫ

## (Әстерхан өлкәсенә экспедиция нәтиҗәләре буенча)

Летом 2013 г. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ была предпринята научная экспедиция в Приволжский район Астраханской области в целях изучения быта и материальной культуры проживающих здесь татар. Одним из интереснейших аспектов исследования оказалось творчество самодеятельных татарских художников данного района. В ходе экспедиции были выявлены несколько самодеятельных художников разного художественного уровня. Показательно, что в большинстве случаев художники-любители следуют традициям реалистического искусства, подражают профессионалам. Уникально влияние на творчество всех самодеятельных художников национального татарского искусства как осознание ими своей принадлежности к определенным этническим корням, своей самоидентификации в условиях многонациональной среды.

**Ключевые слова:** самодеятельное искусство Астраханской области, художник-любитель, научная экспедиция.

Үзешчән иҗат элек-электән тамашачыларда зур популярлык казана. Беренчедән, үз-үзеңне күрсәтү мөмкинлеге буларак, икенчедән, дөньяны үзенчәлекле кабул итү, үз фәлсәфәсе һәм мантыйгы, оригиналь, чиста, берни белән дә болганчыкланмаган дөньяны күрү җәлеп итә. Профессионал булмаган рәссамнарның эшләрендә ихласлык шатлыгы да, яшәү зирәклеге дә бар.

Үзешчән иҗат (бу очракта рәсем сәнгате күздә тотыла) беркайчан да бертөрле булмаган. Авторларның бер өлеше һәрвакыт, классика яки хәзерге сәнгатькә таянып, профессионалларга охшатырга тырышкан. Аларның әсәрләренең катлауландырылган, композицион һәм төсләр характерындагы профессиональ бурычларны чишәргә омтылу күзәтелгән пластик теле шуннан килә.

Ә бер өлеше, «наив» рәссам булып калып, үзен ихлас һәм сәнгатьнең шартлылыкларыннан бәйсез әсәрләрдә таба. Күп очракта үзе яки зур булмаган аудитория өчен эшләүче үзешчән рәссам — бүгенге көндә популярлык казанучы сирәк булмаган күренеш.

Үзешчән рәссамнар төрле шәһәрләрдә, өлкә һәм район үзәкләрендә, авылларда яшиләр. Мегаполисларда мондый осталар, «ял көненең рәссамы», мәдәни тормышның артык мөһим булмаган элементы булса, провинциаль урыннарда мондый рәссамнар еш кына төп культура вәкиленә, милли һәм халык традицияләрен популярлаштыручыларга әйләнәләр.

2013 елның җәендә ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни экспедициясе составында безнең тарафтан Әстерхан өлкәсенең Идел буе районында яшәүче татарларның көнкүреше һәм материаль культурасы өйрәнелде. Тикшеренүнең иң кызык аспектларыннан берсе — әлеге районның үзешчән татар рәссамнары иҗаты булды. Алар өчен иҗатта иң мөһиме — милли чикләр

югалган дөньяда, билгеле бер этник культура вәкиле булуларын күрсәтү икәнлеге ачыкланды. Әмма күпчелек очракта үзешчән рәссамнарның реалистик сәнгать традицияләренә нигезләнүен, профессионалларга охшатырга тырышуын күзәтергә туры килде. Үзешчәннәр иҗатында ирекле күчереп ясау яки киң билгеле классик картиналарны интерпретацияләү кебек юнәлеш тә бар. Бик сирәкләр генә, рәсем ясауның, колористика законнарының профессиональ күнекмәләренә ия булмый торып, иҗатчыларның иң кадерле сыйфаты — образлы фикер йөртүгә ия. Менә ни өчен натурадан ясалмаган, ә әйтелгән пейзаж мотивлары да, кеше характерлары да ышандыра. Әлбәттә, бу бүленеш шартлы һәм профессионал булмаган рәссамнар иҗатында аерым тенденцияләр, бербереен тулыландырып һәм баетып, еш кисешә.

Шул факт кызык тоела: үзешчән рәссамнар Россиядә сирәк күренеш булмаса да, Казан арты татар авылларында станокта башкарыла торган иҗат белән шөгыльләнүче андый рәссамнар очрамый диярлек, чөнки сәнгатьнең әлеге төре татарлар өчен традицион түгел. Әстерхан өлкәсендә исә андый осталар әз түгел, аларның күпчелек татар милли сәнгате кысаларында эшләве аеруча кызык.

Һәр тикшерелгән авылда да диярлек безгә бер булса да рәссам очрады. Мәсәлән, Киләче (Килинчи) авылында Кужамкулов Румил Мавлүд улы эшли. Авыл клубының элеккеге директоры иҗади шәхес булып чыкты, гармунда да уйный, төрле авыл чараларында катнаша. Рәсем ясау белән яшь чагыннан шөгыльләнә. Эшләренең төп жанры — пейзажлар. Үзенә якын булган туган җир табигатен, авыл һәм аның тирә-ягын ясый. Аның картиналары реалистик юнәлештә ясалган, бай колоритка ия. Җирле халык кайвакыт аның эшләрен бүләккә дип (мәсәлән, туйларга) сатып ала. Әмма рәссамның иҗади натурасы станокта башкарыла торган иҗат белән генә тукталып калмаган, аның тарафыннан өй, капка, ишегалды бизәлгән. Кужамкулов татар традицияләрендә эшләнгән үзенең капкасын гадәти булмаган, бай төсле төсләргә буяган. Кечкенә капка янында кеше кыяфәтен хәтерләткән түмәр — үзенә күрә йорт сакчысы урнашкан. Ишегалды төрле материаллардан булган объектлар белән бизәлгән: мәсәлән, газон — төрле төсләргә буялган ташлардан, сарай диварлары магнитофон тасмаларының буш бобиннары белән эшләнгән. Бакчада, карачкы урынына, конкурска дип ясалган милли киемнән кеше биеклегендәге «Масленица» курчагы тора. Шулай ук папье-машедан эшләнгән түбәтәйле татар башы да бар. Бу урында шуны да искәртергә кирәк: Р.М. Кужамкулов үзенең ишегалдын һәм өен эстетик бизәү өстендә максатчан эшләгән.

Кызан (Татарская Башмаковка) авылындагы танылган чигү остасы Баузия Нәҗметдин кызы Исхакованың (1928 елгы) улы Исхаков Әдһәм Хаҗитархан улы (1959 елгы) да үзешчән рәссам икән. Әнисе сүзләре буенча, улы армиядә писарь булып хезмәт иткән, балачактан рәсемнәр белән мавыкмаса да, художество сәләтенә ия булуы нәтиҗәсендә, авыл мәктәбе өчен заказлар ясап, үз-үзен күрсәтә алган, хәтта мәдәният йортында рәсем укыткан. Фотографияләр буенча әбисе Иблиәминова Маһинур

Мөхәммәд кызының һәм этисе Исхаков Хаҗитархан Ильяс улының портретларын ясаган. Фотография буенча шулай ук автопортрет ясалган. Анда үзеңнең психологик образыңны — үз-үзенә ышанган кеше образын тудыруның уңышлы омтылышы ясалган. Шулай ук аның тарафыннан шактый монохром, минимум детальле, соры төстәге мәчет бинасын сурәтләгән, каллиграфиясез, әмма берникадәр традицион шамаил ясау кагыйдәләре буенча шамаил эшләнгән. Аның кырларында пыяла рамкаларга куелган, борынгы шамаилләрнең иске традициясе буенча пыяла эченнән чәчәкләр белән бизәлгән ике фотографик портрет эленгән. Портретларда — Б.Н. Исхакованың эти-әнисе фотографияләре. Әдһәм Исхаков әнисенең кухнясын япон стилендә эшләгән, экзотик кошлар белән бизәгән.

Майлы күл (Яксатово) авылында Таҗиев Дамир Ибраһим улы (1948 елгы) өендә кирпеч йорт интерьерында икенче кат баскычының декоратив бизәге, шулай ук бүлмәләрнең берсендә татар орнаменты традицияләрендә түшәмне бизәү бар. Аларның авторы — Таҗиева Ильмира Дамир кызы (1973 елгы). Ул агач кисү һәм реставратор белгечлеге буенча Әстерхан педучилищесын тәмамлаган. Соңыннан мединститутта укыган. Хәзер Камызакта балалар йортында эшли, Кызанда (Татарская Башмаковкада) яши.

Авылдашларның художество сәләтләренә хөрмәт белән каравының тагын бер кызыгы шул: тумышы белән Җәмәле (Три Протока) авылыннан булган Хөсәенов Хабибрахман Хәким улының (1940 елгы) профессиональ рәссам, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы булуы. Аны сәнгать мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ниязова Фирдәвес Хәким кызы юнәлткән. Хәзер Хөсәенов Әстерханда танылган рәссам, аның бер эше өлкә губернаторы А.Жилкинның кабул итү бүлмәсендә урнаштырылган.

Әмма безнең өчен иң кызык үрнәк — Киләче авылының үзешчән рәссамы Кидло Алиса Николаевна булды (1988 елгы). Ул 2013 елда Әстерхан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлаган, авыл мәктәбендә өстәмә белем бирү педагогы булып эшли, аңа балаларны да тарткан. Оригами белән шөгыльләнә. Аның иҗаты чын, «садә» художникларга хас булган, дөньяга оригинал караш, образлы фикер йөртү системасы, стандарт булмаган якын килү белән кызык. Әбисенең йортында ул, гаҗәеп атмосфера тудырган: бөтен өслекләрне — койма, капка, өй, веранда һәм хуҗалык корылмаларын бизәгән. Алиса рәсемне кәефенә карап ясый (төсләр сайлау да шуңа бәйле), бар нәрсәнең күңелгә яхшы тәэсир итүен тели, шуңа туры килгән темалар да сайлый — тәвә кошы, оҗмаһ кошлары, әкияти агачлар, чәчәк һәм үсемлекләр, аккошлар, балыклар, пальмалар һәм диңгез. Төсләр ачык, локаль, татар орнаментлары куллана, чөнки Алиса үзен татар кызы дип саный (әнисе буенча татар). Майлы буяулар белән дә, аппликация техникасында да (үзе ябыша торган кәгазь, обойлар, төсле кәгазь) эшли. Балавыз, акбурлар, төсле карандашлар һәм фломастерлар ярдәмендә башкарылган графика белән дә шөгыльләнә. Аның иҗатының «садә» рәсем сәнгате стилендә булуы шиксез, чөнки ул бөтенләй үзгә, реаль чынбарлыкка бернинди мөнәсәбәте булмаган, әмма

бик тәэсирле, үзенең аерым образлылык системасы булган художество дөньясы тудырган. Шунысы кызык: яшь рәссамның бабасы үз вакытында агачка уеп язу, бизәк төшерү белән шөгыльләнгән, шулай итеп, бу йортта да иҗади традицияләр дәвам итә.

Шул рәвешле, экспедиция барышында сәнгати осталыгы төрле дәрәҗәдә, ләкин үз талантын үзенчә күрсәтә алган берничә үзешчән рәссам ачылды. Бүгенге шартларда барлык үзешчән рәссамнарның да билгеле бер этник тамырларга каравы, күпмилләтле әйләнә-тирәлектә үз урыннарын аңлавы һәм аларга нәкъ менә милли татар сәнгатенең йогынтысы кыйммәт.

***Әхмәтова Динә Ирек кызы,***
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

*Гали Рәхим*

## «ОТЕЛЛО» (куелу мөнәсәбәте илә)

Гали Рахим – писатель, поэт, литературовед, фольклорист – в истории татарской литературы, науки и культуры занимает особое место. В 1920-е годы он был также членом театральной репертуарной комиссии, являлся автором нескольких пьес, поэтому тема театральных постановок была ему близка.

Предлагаемая статья Г. Рахима посвящена постановке на татарской сцене произведения «Отелло» Шекспира. Статья «Отелло» (куелу мөнәсәбәте илә)» была опубликована 20 апреля 1921 года в газете «Татарстан хәбәрләре». Трагедию Шекспира на татарский язык перевел Габдрахман Карам, роли исполнили такие известные актеры, как Мухтар Мутин, Гульсум Болгарская, Гульсум Камская и др. В статье Г. Рахим коротко останавливается на содержании произведения, дает характеристику актерскому исполнению. Также без внимания рецензента не остается художественное оформление спектакля: грим, костюмы и декорации.

**Ключевые слова:** Гали Рахим, татарская литература, театроведение, Шекспир, история татарского театра, «Отелло», татарская периодическая печать.

15 апрельдә «Большой театр» сәхнәсендә беренче мәртәбә мәшһүр инглиз драматургы Шекспирның иң атаклы трагедияләреннән «Отелло» уйналды.

Бөтен Европа әдәбиятының аталарыннан, театрының пирләреннән (нигез салучыларыннан) хисапланган, бөтен галәм тарафыннан «даһи» дип танылган бөек Шекспирның әсәрләрен безнең татар сәхнәсе әле беренче тапкыр күрә. Шекспир моннан өч йөз еллар элек [XVI—XVII гасырлар чигендә] яшәгән. Ул ярлы, эшче бер гаиләдән чыгып гомерен артистлыкта кичергән. Ул гомер буе үзе уйнаган театр өчен язган. Заманасында аны тәкъдир итмәгәннәр; күп еллар узганнан соң гына аның шөһрәте бөтен Аурупага таралып, шул көннән бирле аның әсәрләре туктаусыз бөтен Аурупага, хәттә бөтен галәм сәхнәләрендә уйнала, хәзергә чаклы мәдәни публика тарафыннан кимемәс дикъкать белән карала. Шундый искерми торган, мәңгелек әсәрләр алар.

«Отелло» да, «Гамлет», «Макбет», «Король Лир», «Ромео вә Джульетта», «Юлсызлар» шикелле, Шекспирның беренче дәрәҗәдә тора торган әйберләреннән санала.

«Отелло» гаять авыр бер фаҗига. Затән [нигездә] Шекспирның шөһрәте үзенең трагедияләре белән. Ул, башлыча, трагедия язучы. Аның югарыда саналган иң атаклы әсәрләре һәммәсе дә фаҗига-трагедияләр.

Драма әдәбиятының бу нәүгысы [төре] гәрчә хәзерге заманда үзенең әһәмиятен югалтып, хәзерге иҗтимагый тормышның әсаслары белән галякасе [бәйләнеше, мөнәсәбәте] булмаганга модадан чыккан булса да, Шекспир трагедияләре һаман да бик зур интерес белән каралуда дәвам

итәләр вә һичбер вакыт сәхнәләрдән төшмиләр. Моның сәбәбе аларның бөтен инсаният галәме өчен уртак булган кеше психологиясен тәшригъ итүче [кешенең рухи галәмен ярып күрсәтүче] әсәрләр булуыннандыр. Алар бөтен инсаннарга махсус булган мәхәббәт, көнчелек, дәрәҗә, сөю шикелле хиссиятне сәнаигъ нәфисә юллары белән тикшерәләр.

«Отелло» исә көнчелек: ирләр, хатыннар мөнәсәбәтенә тәгаллекъле [бәйле] көнләү тойгысына, шул күп кешеләрнең җан тынычлыгын бетереп, тормышын агулаучы «яшел күзле гыйфрит»кә багышланган әсәр.

Трагедиянең баш каһарманы Отелло христианлыкка чыккан мәгъри-би гарәп [мавр], үзенең хатыны Дездемонаны — «Венеция» сенаторының гүзәл кызын, хәддән тыш (чиктән тыш) ярата. Отеллоны көнчелекнең мөҗәссәме [гәүдәләнеше] итеп таный торган бик таралган бер караш бар. Ләкин бу ялгыш бер фикер. Отелло көнчелек хисенә ташкан, тәбган [ияргән] көнче бер кеше түгел. Хатыны да аның турысында: «Отелло көнче түгел ул үзе», — ди. Гайре табигый дәрәҗәдә, сукыр көнчеләргә көнләр өчен һичбер төрле реальный сәбәп, дәлилләр хаҗәт булмый. Әмма Отелло табигый бер кеше булганга, көнләвенең әсаслылыгын үзүзенә төпле дәлилләр белән исбат итмичә торып, бу хискә күз йомып бирелми. Тик явыз, хәйләкәр Яго гына, шайтани осталык белән берберсенә эләктереп төзелгән соңгы ялган фактлар белән хатынының хыянәтен исбат итеп, аны ышандырганнан соң гына, аның көнчелеге бөтен куәте белән мәйданга чыга. Хәйләкәр европалы бер катлы, саф күңелле шәрекъ угылын алдый; садәдил [эчкерсез, саф күңелле] һәм тәбган соң дәрәҗәдә яхшы кеше булган бичара гарәп тә аның кармагына эләгеп, мәгыз (акылы) үзенең пакь вөҗданлылыгы, үзенә принцип итеп алган әхлакый кагыйдәләреннән кыл кадәр читкә чыкмыйча, туптуры юл белән бара торган кеше булуы аркасында, чын күңеленнән сөйгән хатынын үтереп, үзе дә һәләк була. Дәртле, кызу канлы җәнүб кешесе булганга, Отеллоның гыйшкы да, көнчелеге дә ифрат дәрәҗәдә [чамадан тыш] куәтле булып тышка чыгалар. Ул үзенең хисләрендә һич бер төрле чик-чаманы белми. Ләкин аның көнчелеге гайре табигый бер хис түгел. Ул шәрекъ халыклары ноктаи нәзарында [карашында] мактаулы һәм ирләр өчен лазем булган бер тойгы. Шуның өчен дә без Отеллоның рухын аңлыйбыз, аны яратып чын күңелебездән кызганабыз, хәтта хатынын үтергән өчен дә без аны гаепләмибез, бәлки явызларның корбаны булганын күреп кат-кат кызганабыз гына. Менә Шекспир тарафыннан иҗат ителгән «Отелло» тибы безнең күңелебездә шундый эзләр калдыра.

Инде безнең татар сәхнәсендә бу типны беренче тапкыр уйнаган Мохтар Мутин[1] аны кирәгенчә чыгара алдымы? дигән сөальгә без: чыгарды һәм гаять муаффәкыятьле (уңышлы) вә тулы рәвештә бирә алды дип җавап бирәбез. Бөтен төр вә хәрәкәтләре, үзен тотуы, эчке сизешләре белән ул чын-чын Шекспирның бирергә теләгән Отеллосы иде. Ул аз гына да арттырып җибәрмәде, аз гына да кирәгеннән киметмәде; һәр хәрәкәт, һәр тавыш үз урынында иде. Киеме аның сокланырлык бай вә матур булганы шикелле, гримы белән дә ул чын-чын шимали африка-

лы бер гарәпне күз алдына китерә иде. Бу ел мин Мутинны әһәмиятле рольдә күргәнем юк, бәлки аның муаффәкыятьләре хакында ишетеп кенә беләдер идем.

Ләкин аның уены татар театрын татар тормышы үлчәве белән генә үлчәргә үз-үзен мәҗбүр итә алмый торган, аңар артык зур требованияләр куя торган кешеләрне дә канәгатьләндерде, һәрхәлдә бу инде өченче елларны «Әл-мансур»да уйнаган чиктән тыш пафослы Мутин түгел. Белмим ул пешеп өлгереп җиттеме? Әллә кинәт безгә могҗиза күрсәтәме? Хасыйл [нәтиҗә], бу көнгә хәтле аның артистлыгы хакындагы фикерләре теләсә ничек булсын, Отелло ролен иҗат иткәннән соң ул үзенең зур бер талантка малик артист икәнлеген һәм беренче татар трагик артисты булуын исбат итте.

Гөлсем ханым Болгарская[2] ирен керсез мәхәббәт белән сөя торган, Аллага ышангандай аңар ышана торган, дөньядагы явызлыктан бихәбәр [хәбәрсез] булган, саф күңелле Дездемонаны зур муаффәкыять белән уйнады. Бигрәк тә, ул ахыргы иң мәсьүлиятьле [җаваплы] пәрдәдә самими вә күңелләрне яулаучы иде.

Отеллодан кала иң мөһим роль булган Ягоны уйнаган Колмәмәткә[3] килсәк, ул да бу читен рольне муаффәкыятьле рәвештә башкарды. Бу чын-чын адәм сурәтендәге иблис иде. Гримы да шаблонный түгел, оригинальный сайланган. Ләкин күңел аннан, кирәк хәрәкәтендә булсын, кирәк сөйләвендә булсын, тагын да артыграк табигыйлык тели; чөнки бик табигый рәвештә уйнау белән генә бу рольның бер тарафлы һәм гайре табигыйлеген җиңәргә мөмкин. (Тормышта Яго шикелле явызлыктан гына мөрәккәб [җыелган] булган кеше гадәттә очрамый. Ничек кенә булса да кешенең рухының бер почмагында инсаният хисләре булмый калмый.) Колмәмәт «Сәйяр» труппасында күптәннән эшләп, акрынлап тәрәкъкый иткән [алга киткән] бер артист. Аның без бертуктаусыз ясалмалылыктан табигыйлеккә таба хәрәкәт итүен күрәбез. Колмәмәт шикелле истигъдадлы [сәләтле] артисттан бу кимчелекне тизлектә бөтенләй үк җиңүен көтәбез, һәрхәлдә, Колмәмәтнең бу рольны иҗат итү юлында хосусый хезмәт куеп эшләгәнлеге вә тырышканлыгы сизелә.

Кассио ролендә Айдарский[4] урынлы һәм кимчелексез иде. Дездемонаның атасы Брабанциога гына (Шамил[5]) күбрәк вә карлы, вә салмак булу зарар итмәс иде. «Дож» һәм сенаторлар шикелле картларга да бераз калынрак гәүдәле, мәхәббәтлерәк булу килешер иде төсле тоела. Камская[6] Эмилия ролендә яманнарлык түгел, башка рольләре илә караганда күп яхшы иде. Гомумән, бөтен труппа, көчләрнең кирәгенчә җитешле һәм тулы булмавына карамый, тигез һәм тырышып уйнады.

Тарихның күрсәтүе буенча бик зур серләргә төрелгән була торган сенаторларның киңәш мәҗлесенә Брабанционың гади хезмәтчеләре күп тыңлап торулары, Фабрис атарында диңгез тарафыннан караблар килгәндә халыкның коры җир ягына караулары шикелле хаталарны да мөкәммәл дияргә ярый.

Шушы постановка өчен махсус ясалган декорацияләр матур һәм җитешле. Татар сәхнәсендә мондый гүзәл постановкалар тәбрик белән каршыланырга тиеш.

«Отелло»ның тәрҗемәсенә килгәндә, бу тәрҗемә үзенең каләме

белән яхшы ук танылган Габдрахман Кәрам[7] иптәш тарафыннан кылынган. Ләкин сәхнәдә бу тәрҗемәнең аның тәҗрибәле каләменнән көтелгән дәрәҗәдә муаффәкыятьле булмавы күзгә чалынды. Тәрҗемәнең кимчелеге аның артык авырлыгындадыр. Монда Кәрам иптәш үзенең күптәнге һәм күптән ташланган дип уйланган гаебен тәкрар итә [кабатлый]. Ул да булса гарәп сүзләре вә госманлычылык белән сүиистигъмаль [урынсыз куллану]. Бик ансат татарча тәгъбирләр табарга мөмкин булган урыннарда да ул аз истигъмаль итә [кулланыла] торган әҗнәби сүзләр, тантаналы гыйбарәләр куллана. Өслүб тә урыны-урыны белән госманлы тарызында төзелгән. Шуңар күрә тәрҗемәнең теле сөйләшү теленнән ераклашкан.

Бу китап әле басылмаган. Аны төзәтергә мәйдан ачык әле. Кәрам иптәш шаяд [бәлки] күп хезмәтен кызганмаганны азын кызганмас, тәрҗемәсен, яңадан бер кат тәнкыйть күзеннән кичереп, төзәтеп чыгар дип өмет итәбез.

## Искәрмәләр

1. Мутин Мохтар Исхак улы (1886—1941), актер, режиссер. Сәхнә эшчәнлеген 1908 елда «Сәйяр» труппасында башлый, 1912—1915 елларда «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларын оештыруда катнаша. Репрессияләр чоры корбаны.

2. Болгарская Гөлсем (Мостафина Өммегөлсем) Муса кызы (1891—1968), актриса. Сәхнә эшчәнлеген 1910 елда «Сәйяр» труппасында башлый. 1922 елдан Беренче үрнәк театр артисты.

3. Колмәмәт (Азимов) Хәмит Мөхәммәт улы (1895—1942), актер. Сәхнә эшчәнлеген 1915 елда «Сәйяр» труппасында башлый. 1922 елдан Беренче үрнәк театр артисты.

4. Айдарский (Вәлитев) Газиз Исхак улы (1898—1933), актер, режиссер. 1920—1922 елларда ТАССР Мәгариф халык комиссариатында сәнгать бүлеге җитәкчесе, 1922—1924 елларда Казанда Беренче үрнәк театр артисты.

5. Шамил Касыйм Шамил улы (1892—1981), актер, режиссер, педагог. Сәхнә эшчәнлеген «Сәйяр» труппасында 1909 елда башлый. 1922 елдан Беренче үрнәк театр артисты.

6. Камская (Ильясова) Гөлсем Сәйфулла кызы (1901—1975), актриса. Сәхнә эшчәнлеген 1919 елда Казанның Кызыл Октябрь исем. татар театрында башлый.

7. Кәрам (Рәхмәтуллин) Габдрахман Хәбибулла улы (1878—1947), театр тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче.

*Басмага әзерләде:* ***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*Галимҗан Шәрәф*

# УФАДА ЯҢА ТАТАР ИМЛЯСЫ

19 декабря 1920 г. Татарское правительство декретом за № 37 утвердило первый «Алфавит и орфографию татарского языка» на основе арабской графики. В 1926 г. группа учителей татарского языка города Уфы в журнале «Белем» опубликовала проект о внесении серьезных изменений в действующий алфавит и орфографию, который состоял из 11 пунктов, подтвержденных примерами. В ответ на эту публикацию видный татарский ученый-языковед, специалист по татарскому алфавиту и орфографии Галимжан Шараф выступил со статьей «Уфада яңа татар имлясы». В статье ученый предупреждает о последствиях, к которым может привести внесение предложенных уфимскими учителями изменений, об их неоправданности, о том, что татарская орфография уже завоевала положительную оценку специалистов и общественности. По его мнению, люди не сведущие в этой области не имеют право что-либо изменять в утвержденных правительством алфавите и орфографии.

**Ключевые слова:** фонетика, орфография, орфоэпия, арабская графика, звуковой строй татарского языка, транскрипция, транслитерация, языковая реформа.

«Белем» журналының март аенда чыккан 2—3 нче саннарында, Уфада шәһәр укытучыларының җыелып, бер комиссия сайлап, тагын җыелып татар имлясын үзгәртү турында карарлар чыгаруы турында белдерелә һәм чыгарган карарлары игълан ителә. «Белем» журналы татар телендә язылган кайбер мәкаләләрендә бу карарларның кайберләрен гамәлгә дә куя башлаган. Карарлар «татар имлясындагы истисналарны бетерү» дип аталса да, монда сүз истисналар (кагыйдәгә буйсындырылмый торган моментлар) турында түгел, бәлки хәзерге урнашкан татар имлясын әсасән үзгәртү турында бара. Бу карарлар 11 пункттан гыйбарәт булып, алар түбәндәге мәсьәләләргә кайтып калалар:

1) Татар имлясындагы хәзерге 6 мәд хәрефе урынына 10 мәд хәрефе алырга;

2) «Ватык, тау, ярлы, ай» кебек сүзләрдәге мәдсез «вау», «йә» хәрефләренә мәдле «вау», «йә»ләрнекенә башка булган тагын аерым ике галәмәт арттырырга;

3) «Ат, аш, әкрн, ут, урак, өч» кебек сүзләрдә сүз башындагы һәмзәне ташларга, бу сүзләр боларча «ат, аш, әкрн, ут, урак, өч» рәвешендә язылырга тиеш була.

4) «Ы — э» авазын һәммә ишетелгән урынында, ябык иҗекләрдә дә калдырмыйча язарга: «тлсз, блмсз, бр кше» дигән сүзләр боларча «телсез, белемсез, бер кеше» рәвешендә язылырга тиеш;

5) «О — ө» (өтерле вау — *А.Ш.*) хәрефен төп сүзләрдә һәммә ишетелгән урынында язарга: «төлке, сөлге, солы, койы» кебек сүзләр боларча «төлкө, сөлгө, соло, койо» рәвешендә язылырга тиеш;

6) «Ғ» белән «г», «қ» белән «к» хәрефләрен бер үк авазның калын һәм нечкә әйтелешләрен генә күрсәтә торган галәмәтләр итеп карап, боларның һәр парына берәр генә хәреф калдырырга. Димәк «калган, килгән» сүзләрен имляда йә «қ» белән «ғ»ны гына калдырып: «қалган, қыйлган» рәвешендә язарга, йә «к» белән «г»не генә калдырып «калгән, кылгән» рәвешендә язарга тиеш була;

7) Татар имлясында «күп кабып, аштан кайтты, шомны әдәмнәр» дибрәк сөйләнгән сүзләр, сарыф берлеге әсасыннан һәм уку өчен җиңеллек ягыннан чыгып «күб кабыб, ашдан кайтды, шомлы адәмләр» рәвешендә язылалар: бу карарларда соңгы рәвештә язылуны «истисна кертү» дип карап, моның урынына «ишетелгәнчә» «күп кабып, аштан кайтты, шомны әдәмнәр» дип язарга, шулай өйрәтергә карар бирелгән.

Бердән, бу карарлар «Сәнәк» журналында басылмый, Башкортстан мәгариф халык комиссариатының җитди рәсми журналы «Белем»дә басылганга һәм кайбер пунктлары гамәлгә дә куела башлаганга, икенчедән, шундый ук тәкъдимнәрне тулы рәвештә йә бүлгәләп, әледән-әле күтәреп торучылар Казан имлячылары арасыннан да булганга, башка шәрекъ җөмһүриятләрендә дә төрле имля агымнары арасында чарпышулар барганга, без бу карарны, кыскакыска, җитди рәвештә тикшереп чыгабыз.

### Ун мәд хәрефе мәсьәләсе

Ун мәд мәсьәләсе бездә К.Насыйридан башланып 15—20 еллар тикшерү, аңлашулардан һәм кайбер кыек әдәмнәрдән соң архифка тапшырылган мәсьәлә. «Алтымы?», «унмы?» мәсьәләсе гамәли уңайлык ягыннан карап хәл ителгән мәсьәлә. Татар теленең төзелешен, гамәли уку алымы кануннарын хәтергә алганда, татарча сүзләрне анык һәм бер төрле генә язар өчен дә, укыр өчен дә алты мәд хәрефе кирәк һәм җитә. Шуңа күрә татар матбугаты моны кабул иткән, Татарстан хөкүмәте шуны декретлаштырган. Чит телләрдән кергән һәм һәммә сүзләрне төп шул телдә язылганча йә сөйләнгәнчә тәҗвидына туры китереп язу өчен исә 12 мәд дә, 15 мәд дә җитми. Хәрефләрне, имляны аерым сүзләре әҗәткә алынган һәммә телләргә туры китереп бетерү һич бер тел өчен мәҗбүри түгел. Бик күп татар сүзләрен, татар авазларын урыс, немец, француз, гарәп йә башка бер телнең гамәли имлясы һәм аның хәрефләре белән аерым галәмәтләр арттырмыйча язарга мөмкин булмау, ул телләр, ул имлялар өчен кимчелек булмаган шикелле, урыс, гарәп, француз, немец сүзләрен тәҗвидләрен саклап татар имлясы белән язып булмау, татар имлясына да гаеп түгел. «Ун мәд кирәк» дигән карарны нигезләү өчен китерелгән «татар сүзләренең калын йә нечкә укылулары сузынкы (мәд) авазларына гына карап йөрми («карап йөри» булырга тиеш. — *А.Ш.*) дигән сүз фәнни яктан ялгыш. Авазларны тикшерү өчен ясалган кораллар һәм машиналар белән тәҗрибәләр дә, гади тәҗрибәләр дә татар сүзләрендә мәд авазларының гына түгел, мәдсез авазларның да үз башына калын һәм нечкә булуларын күрсәтәләр. Телдәге һәр авазга бер хәреф булырга тиеш дигән тәкъдим буенча, төп татарча сүзләрне генә алганда да, безгә хәзерге әлифбабыздагы 31 хәрефебез урынына мәдле һәм мәдсезләре белән кимендә 60 лап төрле хәреф алырга тиеш булыр иде. Гыйльми транскрипцияләрдә һәр авазга бер хәреф алына. Ләкин моңа карап алар буенча уку да, язу да, укуязу тану да җиңелрәк түгел, бәлки авыррак. Гамәли имляларга караганда бик күп җайсызрак. Хәзерге имляга тагын 4 мәд хәрфен арттыру, бер дә кирәкмәгәнгә хәреф күбәйтү, язуны яңа галәмәтләр белән чуарлату, бөтен укучы-язучы халыкны яңа

күнегүләр ясарга ирексезләү, бабайларча әйткәндә, «бер дә кычытмаган җирне канга батырып кашу» булыр иде.

Имляда унчылык агымы татар теленең үз төзелешеннән, үз кирәгеннән килеп чыкмыйча, безгә бары урыс язуы сөремтесе белән генә килеп кергән. Гадәттә мәдәни тәэсирләр аллары, яхшы яклары белән генә түгел, артлары, начар яклары белән дә күп вакытта бергә керә баралар. Арттарак халыкларның, тышкы күренеш тәэсиренә ныграк бирелә торган кайбер группаларына, күршедәге алдынгырак халыкларның начар һәм зарарлы гореф-гадәтләре дә алдынгылык сыйфаты, мәдәниятлелек хаҗәте аслиясе булып күренә. Мәсьәләне тикшерү мәд хәрефләре турындагы урыс сөремтесенең дә, бик күп яхшы сөремтеләр арасында, шундый артяк сөремтесерәк икәнен күрсәтә. Фән академиясе һәм тел галимнәре тануы буенча, урыс телендә фонетика ягыннан мәдсез (согласный) авазлар гына калын да, нечкә дә була алалар. Мәд авазлары урысчада парлы түгел. Шуңа күрә урыс теленең үз табигатенә, гарәп теле имлясындагы йә безнең иске орхон төркләре язуындагы кебек мәдсез хәрефләрне парлы итеп алып мәдлеләрне берәрне генә алу муафыйграк булыр иде. Урысның фән академиясе тарафыннан төзелгән гыйльми имлясында бу шулай ителгән дә. Ләкин урысның төрле күптәнге тарихи сөремтеләр астында төзелгән гамәли имлясында шул ук урысның гыйльми имлясының киресе алынган: монда мәдсез хәрефләр берәр генә алынып, мәдле хәрефләр парлы итеп алынган. Урыс сүзләрендә «а, о, у» авазларының нечкәсе бөтенләй булмаса да, аерым «я, ю, ё» хәрефләре кертелгән һәм шул хәрефләргә бердән «йо, йу, йа» мәгънәсе бирелеп, сүз башында булганда бу хәрефләр бердән ике авазны күрсәтүләре «вел, трюк, взял» сүзләрендәге кебек, сүз уртасында булганда бу «ё, ю, я» хәрефләре үзләре «о, у, а» дип укылу белән бергә, үз алларында булган «т, в» кебек мәдсез авазларның нечкәлеген дә күрсәтү бурычы йөкләнгән. Бу юл «объем, конь, парь, большой» кебек сүз һәм иҗек актыгында килгән мәдсез авазлардан соң аларның калынлык, нечкәлеген күрсәтү өчен «ъ, ь» ләр куярга мәҗбүр иткән. Икешәр, өчәр мәдсез авазлар бергә юлыкканда кайда «ь» кую, куймаулар турында бик буталчык кагыйдәләр төзәргә туры килгән. Бу парлы, парсыз хәрефләрне тиешенчә алмау чыгарган җайсызлыкларга, урысчада «городской», «вода» дип язылып та гърадской, вада дип басым тәэсире белән мәдләрне бөтенләй үзгәртеп уку мәҗбүриятләре туган. Башта алынган ялгыш юл шулай итеп урысның сөйләшү телен язу теле арасында фонетика ягыннан зур аерма тудырган. Тел белән язу арасындагы аермалар буталчык һәм аларны ачып салулар халыкта урыс язуына «хөрмәтне киметәчәк» булганга, гадәттә урыс мәктәпләрендә укытыла торган имля-сарыф китапларына бу төп мәгънәләрнең берсен дә кертмәгәннәр. Хәтта «мәктәп грамматикасы» һәм «фәнни грамматика» исемендә бер үк урыс теле өчен икесе ике бер-беренә каршы әсаслардагы грамматикалар төзелгән. Фәнни грамматиканы бары тел гыйльме белгечләре җитештерә торган гали мәктәпләрдә генә укытканнар. Телнең табигате, әсасы, фонетика кануннары, имляның нигезләре кебек мәсьәләләрне күпчелеккә укы-

тыла торган мәктәп грамматикасына кертмәгәннәр. Хәзер дә әле урыс мәктәпләрендә бу күбесенчә шул хәлдә бара. Урыс имлясы фәнни яктан никадәр буталчык булмасын, укуязу ягыннан һәм тиешле ысуллар тотылганда үз халкына өйрәтү өчен артык зур гамәли җайсызлыклар ясамаганга, шул килеш барган. Революция башында ясалган урыс имля реформасын бу әсас буталчыкларга һич кагылмадылар, бары вак-төяк гамәли җиңеллекләр кертә торган төзәтмәләр кертү белән генә калдылар. Урыс имлясының үзе өчен дә җансыз һәм нигезсез булган, безнең өчен һич бер гамәли кирәге булмаган мәдләрне калын һәм нечкә парлы итеп алу юлы безнең имлябызга да керергә омтылып караган. Бу сөремте вакытында телче, имлячыларыбыз арасында үзенә кайбер яклаучылар да тапкан иде. Татар теленең авазлары фәнни рәвештә тикшерелмәгән бер дәүрдә, урыс теленең һәм имлясының фәнни яктан төзелү кануннарын тикшерергә, алар белән якыннан катнашырга әзерлеге һәм имкяны булмаган К.Насыйри өчен бу сөремтегә бирелүне гаептән санамаска мөмкин, ләкин татар теленең авазлары тикшерелгән һәм тагын да ныклабрак тикшерергә мөмкин бер дәүрдә, тәрбия техникумнарында һәм кайбер урта мәктәпләрдә дә урыс теле һәм имлясының фәнни яктан төзелеше таныштырып үтә торган бер дәүрдә, мондый үзе файдасыз, файдалылары белән турыдан-туры бәйләнмәгән сөремтеләргә бирелү урынсыз һәм гаеп саналырга тиеш.

«Вау», «йа-йә»ләрнең мәдле һәм мәдсез хәлләре.

«Тау, тай» дигәндәге мәдсез «у», «йа-йә»ләр өчен, «туган, тигән» дигәндәге мәдле «у», «йа-йә»ләргә алынган хәрефләргә башка булган, аерым хәрефләр алу-алмау мәсьәләсе дә гамәли мәсьәлә.

Фәнни тәҗрибәләр تاو (тау) — توعان (туган) сүзләрендәге «و» авазлары икәве дә авазлык (мәхрәҗләре) һәм төзелешләре ягыннан бер үк авазлар икәнен күрсәтәләр. Бу ике «و» бер-береннән бары иҗек ясау-ясамау белән генә аерылалар. «Бар, кара» фигыльләреннән эш исемнәре булган, «бару, карау» сүзләренең сарыф ягыннан төзелешен карасак, бу урында боларның берсе урынына берсе килгәнен күрәбез. Татар теле фонетикасының төп кануннарыннан берсе — сарыф үзгәрүләрдә ике иҗек ясый торган авазның бергә була алмавы кануныдыр. Бу төп канун буенча сарыф үзгәрүләрдә ике иҗек ясый торган аваз бергә килсәләр, йә икәве кушылып берсе берсен йота, йә икәвенең кушылуыннан өченче бер аваз ясала (аша, ашый) йә «сулый-сулыйсы» кебек ике арага өченче бер аваз кертелә, йә — «бару-барууы» кебек ике мәдле аваз саклана. Ләкин арага беренче аваз мәдсезләнеп тәкрар (تەكرار) кертелә, йә инде «قارا» фигыленнән ясалган кебек ике иҗек ясый торган мәдле аваздан берсе иҗек ясау көчен югалтып (җуялтып), шул ук авазның иҗек ясамый торганына (мәдлесенә) «قاراو» әйләнә. («Безнең мәктәп сарыфларында» бу мәсьәләләрне төп тел кануннарыннан чыкмый төрле ясалма кагыйдәләр белән генә аңлатырга тырышылган). Тел гыйлемендә мондый бер мәдле авазның икенче мәдле аваз янына килү сәбәпле берсенең иҗек ясау хасиятен югалтуыннан хасил булган ярты мәд авазларына дифтонг диләр. Мондый дифтонглар күп европа телләрендә дә бар. Аваз ягыннан бер булганга гадәттә аларда да мондый дифтонглардагы иҗек ясалмый торган мәд авазлары-

на ярым галәмәтләр йөртмиләр.

Дөрес, урысларда «мой» кебек сүзләрдә дә языла торган «и» дән үзгәртелгән һәм «ярты гласный» дип аталып йөртелгән аерым «й» бар. Ләкин урысларда бердән күп авазларда «и» һәм «й»ләрнең авазлыгы безнеке кебек бер түгел. Аннан бигрәк урысларның көндәлек имлясында «возьми» сүзендәге «и» белән «слова мои» сүзендәге «ий» авазларына икәвенә дә шул ук «и» хәрефе алынган. Шуның аркасында аерым «й» хәрефе алмаганда мәгънә һәм сөйләнеш ягыннан бер-беренә башка булган «мои, мой» сүзләрен ачык укырга мөмкинлек калмаган. Урысларда элеккедән «мои» дигәнне татар имлясында алынган әсас буенча «моии» дип язылу кереп киткән булса, гамәли имляда аларда да аерым «й» алмаска мөмкин булыр иде. Бер халыкка урнашкан, кагыйдәләшкән булганга, урыслар бу «йи» мәсьәләсен шулай ук «йо, йу, йа» дифтонглары урынына иҗек язуы әсасында булган «ё, ю, я»ларын саклыйлар һәм бер авазның иҗек ясый һәм ясамый торган төрләренә аерым хәрефләр алганда, татарчада, сирәк булса да, очрый торган «кырт кисте» «пылт итте» кебек сүзләрдә «л,р» авазларының да иҗек ясый торган чаклары була. «крт, плт» сүзләренең «кырт, пылт» булмавы, бу сүзләрне гади рәвештә әйткәндә фәнни тикшерүләр «ы, э» мәхрәҗенең бөтенләй ясалмавын күрсәтәләр. (Әйтелештә мәхрәҗе булмаган сүздә «ы, э» авазы да була алмый). Татар телендә иҗек ясамый торган «вау, йа, йә»ләрнең иҗек ясый торган авазлар алдыннан йә артыннан гына килү кануннарын һәм гомуми уку агымы кануннарын хәтергә алганда, татар имлясы төзелешендә иҗек ясый һәм ясамый торган «ۏ-ۑ»ләргә аерым-аерым хәрефләр алуның гамәли кирәге юк. Без укыганда да, язганда да моңа ихтыяҗ сизмибез. «Ысулы саутия»нең бик искергән балталама төрләре белән бармаганда моның укыту, язу таныту өчен дә кирәклеге юк. Фәнни транскрипцияләр мәсьәләсе исә гамәли имляга мөнәсәбәтсез аерым бер мәсьәлә.

## Һәмзә мәсьәләсе

«Маэмай, мәэмә, мәсьәлә, мәсьүл» сүзләрендәге һәмзә (ئـ) авазының Татарчада «әтәч, ат, ит, эт, ут», сүзләренең башында мәд авазлары алдында фонетика ягыннан караганда булуы-булмавы турында фәнни мөзакәрә ясарга мөмкин. татарчада аерым алынган сүзләрнең башында һәмзәнең барлыгы фәнни яктан дәлилләр белән аныкланган тәкъдирдә дә, ул анык һәмзәнең дә гарәпчә йә грекчадагы кебек гамәли имляда аерым хәреф белән күрсәтелүе, йә нимесчәдәге кебек фәнни яктан бар дип табылганда да бары гыйльми имляда гына күрсәтелеп, көндәлек имляда күрсәтелмәскә тиешлеге турында сүз булу мөмкин. Ләкин бу аңлашуларда да, урыслар язмый, йә гарәпләр яза, дип карамыйча, татар теленең һәм имлясының үз төзелеше һәм үз көндәлек уңайлыгы ягыннан карарга мәҗбүр булачакбыз. Бу аңлашулар нинди нәтиҗә генә бирмәсеннәр һәр хәлдә, «аш, ат, ак, ал, ил» кебек сүзләр «аш, ат, ак, ал, ил» (сүз башында һәмзә куелмаса. — *А.Ш.*) рәвешендә язылса, боларны «эш, эт, ук, эл, ил» (сузык хәреф алдына һәмзә хәрефе куеп — *А.Ш.*) дип укудан күпчелек котылып бетмәгән бер дәүрдә мондый «реформа»ны «истисна бетерү»не карарлаштыру урынсыз.

**Ябык иҗекләрдә «ы, э» мәсьәләсе**

«Ы-э» хәрефенең беренче иҗекләрдә һәм һәммә ябык иҗекләрдә, язуда күрсәтелмәве, татар теленең төзелеш кануннарын хәтергә алганда, фәнгә, фонетикага хыйлаф диярлек бер эш түгел. Гамәли яктан караганда «тлсз, блмсз, бр кше» дигән җөмләне шул хәлендә укуы да, язуы да матбагада хәреф җыю өчен дә «телсез, белемсез, бер кеше» рәвешендәге имляга караганда җиңелрәк «ы-э»нең кайда язылуы, кайда төшерелеп калдыруы һәр бер теләгән кеше аңларлык ике юллык бер кагыйдәгә кереп беткән. «Ы-э» авазы татар телендә иң күп кабатлана торган аваз. Бер үк текстны хәзерге имлядагыча, беренче һәм ябык иҗекләрдә «ы-э» төшереп, һәм Уфа комиссиясе карарынча төшермичә хәреф җыйдырып икәвен чагыштырып карасак, без соңгысында бөтен текстның беренчесенә караганда 9—10 процент кадәр озынырак чыгуын, шул чамада урын күбрәк алуын күрербез. Тәҗрибәләр безнең бу кагыйдә аркасында урын алу ягыннан иткән файдабызның, сүз башында бөтен мәдләр алдына куя торган һәмзәләребезнең алган урыннарын бер ярым мәртәбә каплаганын күрсәтәләр. Бу ике юллык кагыйдәгә балаларны өйрәтү, бигрәк тә күнектерү укытучыдан үз урынында аерым әһәмият биреп китүне, берничә сәгать, бәлки артык вакыт бирүне мәҗбүр итә икән, бу күнегү сәгатьләре, бер өйрәнгәч билгеле процентка язу, уку вакытын кыскартып бару, укырга ала торган һәр китабын шул ук процентка арзанайту, укый торган гәзитендә материал арттыру формаларында гомер буена дивидент (табыш) биреп торуы, бу кагыйдәнең гомердә бер була торган өйрәнү дәүрендәге берничә сәгать артык вакыт алуына борчылмаска мәҗбүр итә. Гомумән мәктәп тормыш өчен булып, аның бөтен вазыйфасы баланың киләчәк тормышын җиңеләйтү, уңайлатуга кайтып кала. Өйрәтүе җиңелрәк булсын дип хисап, җәбер, һәндәсәне ватып булмаган кебек, язу танытудагы бик вак җиңеллекләр өчен имляны да ватып, гомерлек тормыш йә бөтен язу таныган кешеләр өчен җайсызрак хәлгә куярга туры килми. Бу турыда укытучы һәм тәрбия белгечләребезнең бурычы боларны тормыш өчен авырлатуга калкынмыйча, бар кагыйдәләр нигезендә урнашкан имляны балалар һәм үзләре өчен җиңелерәк өйрәнү — өйрәтү юлларын эзләнү һәм тотудадыр.

**«О — ө» мәсьәләсе**

Төрек-татар телләрендәге «о — ө» авазының кайбер хасиятләре бар. Ул аваз сүзнең беренче иҗегендә булмаса, башка иҗекләрендә һич очрамый. Инде сүзнең беренче иҗегендә булса, бу «о — ө» шул сүздәге үзеннән соң килгән һәммә авазларның төсен берникадәр үзгәртә, аларның ишетелүләренә (акустикасына) «о — ө» сөремтесе бирә. Әйтелеше кыска, авазлык (мәхрәҗ) ягыннан төзелеше зәгыйфь булган «ы — э» авазында бу сөремте башка авазларга караганда ныгырак күренә. «Алп», башм (алып, башым) сүзләрендәге «ып-ым» сарфый ялгаулары, «тотп, котм» сүзләрендә «тотоп, котом» рәвешендәрәк сөйләнүе шушы сөремте аркасында. Бу сөремте «о-ө»гә якын иҗекләрдә көчлерәк, ерак киткән саен кими бара. Сөремтенең көче кимүгә ике арага нинди мәдсез хәрефләр керүе дә тәэсир итә. Бу сөремтенең

сәбәбе безнең ирен әйләнәсендәге итсә (мышца)ларның төзелеше һәм аларның «о-ө» авазын әйткәндәге куелышындадыр. Бу сөремте тигезсез һәм төрле булганга, гамәли имляда бу сөремтене күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсендә түбәндәге ике юлның берсен генә тотарга мөмкин, йә беренче иҗектә «о-ө» булганда аның артыннан килгән һәммә «ы-э» авазларын «о-ө»гә әйләнә дип карап, бу урыннарда «ы-э» урынына «о-ө» хәрефе язу; йә «о-ө» хәрефен беренче иҗектә генә язып, башка иҗекләрдә һәммәсендә «ы-э» язу. Соңгы юл сарфый берлек әсасын саклаганга, татар гамәли имлясында шул юл тотылган. Шул юл белән татар имлясында «онтдрды, өмтсзлк, төбсзлк» рәвешендә язылган сүзләр беренче юл белән «онотдордо, өмөтсөзлөк, төбсөзлөк» рәвешендә язылырга тиеш (болай язу крәшн имлясында, урыс мөстәшрикларының төрк-татар телләре өчен төзелгән «фәнни» транскрипцияләрендә, әзәрбайҗаннарның латин әсасындагы имляларында алынган). Сөремтенең төрле сүзләрдә тигезсез булуы, фонетика ягыннан бу юлның һәр икәве белән файдаланырга юл куя. Ләкин сарыф берлеге әсасы гамәли имляда татар имлясында алынган юлны алга куя. Төрле төрек телләрендә бу сөремтенең төрле юлларда булуы, мәсәлән, татарчадагы «у» урынында «о» авазы булган телләрдә бу аваздан соң да шундый ук сөремтенең булуы, төрле төрек телләре имляларының якынлыгын саклау өчен дә бу сөремтенең гамәли имляларда күрсәтелмәвен алга сөрә.

Уфа карарларына килсәк, анда «о-ө»нең беренче иҗектә генә язылу кагыйдәсе бозылып, төп сүзнең һәр бер ишетелгән иҗегендә язылыр, бары ялгауларда гына күпчелеккә каралыр, диелә. Ләкин карарда төп сүз белән ялгауны ничек аеруны күрсәтмиләр. Уку-язу массага керсен өчен имля кагыйдәләре һәр кем җиңел аңларлык, тиз өйрәнерлек һәм бер төрле рәвештә язарлык булырга тиеш. «Озн, борн, бөтн, төтн, өзк, төзк, бозк» сүзләренең «озак, бармак, бөтәтмәк, төтәмәк, өзмәк, бозмак» сүзләре белән бер төптән булуын, хәтта «болн, болт» сүзләренең «болак, була, бу» сүзләре белән бер төптән булу ихтималын хәтергә алганда, мондый сүзләрнең төбе белән ялгауын аерыр өчен бер тел галиме кадәр белгеч булырга кирәклеге күренеп тора. Уфа комиссиясе бу карарларда: «төрле, төрлечә йөрдекеннән, йөртелә» рәвешендә язылган сүзләр белән бер рәттән үк «төзөргә, бөтөн, борон» сүзләре очрауы нәрсә ялгау, нәрсә төп икәнен, яңа имляны төзүче һәм аны доклад ясап кабул иттерүче комиссия үзе дә аерып бетерә алмаганын һәм бу аеру өчен ныклы бер нигезләре булмаганын күрсәтә.

### «Ғ-г, ҡ-к» мәсьәләсе

Татар имлясында калынлы-нечкәле дип карарлык өч пар: «а-ә, ғ-г, ҡ-к» хәрефләре бар. Ләкин «а, ғ, ҡ»ларның, «ә, г, к» ләрдән аермасы «булды» сүзендәге калын «б, у, л, д, ы» авазларының «бүлде» дигәндәге нечкә «б, ү, л, д, е» авазларының аермасы рәвешендә түгел. «Булды-бүлде» сүзләрендәге һәммә аерым авазларның төп авазлыклары (мәхрәҗләре): б, у-ү, ы-э ләрдә иреннәрнең ачылу-йомылу дәрәҗәсе «л, д»ләрдә тел очының алгы аңкауга тию урыны һәм тию рәвеше калыннарында да, нечкәләрендә дә бер үк. Боларның мәдле һәм мәдсезләренең барында да калыннарының нечкәләреннән аермасы бары авазга һәм

сүзгә калынлык һәм нечкәлек бирә торган телнең урта бер кыйсеменең нечкә сүзләрдә алгарак килеп, калын сүзләрдә арткарак китүендә генә. Тел уртасының бу алга йә артка таба хәрәкәте, авыз эче күләмен зурайтып, кечерәйтеп авазның калын йә нечкә ишетелүенә сәбәпче булган яңгыравык (резинатор)ның күләмен үзгәртә. Без физикадан бер зур, бер кечкенә шар алып, икәвенә дә тигез зурлыкта тишекләр ясап, икәвен дә ирен алдына китереп, өреп карасак, зур шарны өргәндә калын тавыш, кечкенә шарны өргәндә нечкә тавыш чыкканны күрәбез. «Булдыбүлде» сүзләрендәге аерым мәдле һәм мәдсез калын авазларның нечкә төрләреннән аермасы төбе шул яңгыравык зурлыгы аермаларында. «А, қ, ғ»ның, «ә, к, г»ләрдән төп аермасы яңгыравыкта түгел, боларның аермасы бер береннән авазлыклары да башка булуында. Фәнни тәҗрибәләр татарчадагы «у-ү, о-ө, ы-э» авазларының һәр парында иреннәрнең бер-берсеннән ераклык-якынлыклары бер рәвештә калган кебек, болардан һәр парның ачык, ябык, басымлы, басымсыз иҗекләрдәге әйтелеш дәвамы (озынлык-кыскалыгы) да бер тигез. «А-ә» авазларында исә болар өчен төп авазлык булган иреннәрнең берберенә якынлык, ераклыклары башка-башка булган кебек, боларның әйтелеш дәвамнары да төрлечә. «Ә» үзенең әйтелеш дәвамы ягыннан татарчада «ы-э»ләр белән бер тигез. «Ә»дә иреннәрнең «а»га караганда якыная һәм җәелә төшүе дә «ә» авазын «и»гә якынлата. Башка байтак төрек телләрендә: «кәрәк, кәл, әке, бәш» рәвешендә сөйләнгән сүзләрдә Идел буе татарчасында «кирәк, кил, ике, биш» рәвешендә «ә»нең «и»гә әйләнүенә бу авазларның кайбер якынлыклары юл куйган. «Қ, ғ»ларның да аңкаудагы авазлыклары «к, г» авазлыкларыннан башка, алардан арттарак. Бу дүрт аваздан һәр кайсының: «гәрәбә, гармун, багана, гарәп, калым, калам, калушкәүеш» кебек сүзләрдә калыннары да, нечкәләре дә аерым-аерым булганлыклары күренә. Бу сүзләрне «г, к»не имлядан чыгарып: «ғәрәбә, ғармун, қалуш» дип язуга йә «қ, ғ»ны имлядан чыгарып: «бағана, гәрәп, калам-кәләм» рәвешендә язуга нә фәнни, нә гамәли бер әсас та юк. Уфа комиссиясенең бу карары да файдасыз сөремте белән эшләнгән. Фәнгә хилаф һәм гамәлгә җайсыз бер уатма ясаудан гыйбарәт.

### Имлядагы сарыф моментлары

Татар имлясында «таб, күб, китде, ашдан, таңдан» кебек сүзләрдә «п, т, н» кебек ишетелгән авазлар урынына «б, д» язылуы «табн, күбесе, килде, алдан, яздан» кебек сүзләргә ияртелеп сарыф берлеген саклау өчен ясалган. Гамәли имляда сарыф әсасында кирәкле җирләрендә алуның уку агымын тизләтү, телнең сарфын өйрәтү-өйрәнү өчен һәм төрле якын шивәләрне берләштерү өчен уңайлыклары бар. Урыс һәм Европа халыклары гамәли имлясында да шуңар күрә сарыф берлеге әсасына киң урын бирелгән. Имляның киң, аңлаешлы кагыйдәгә каратылган, уку-язу өйрәтү өчен зур авырлык китерми, әдәби телнең имля нигезләрен бозмый һәм матбугатта вә халык арасында җитәрлек урнашканнарны вату өчен дә нә гыйльми, нә гамәли әсаслар юк.

### Мәсьәләнең куелышы

Инде мәсьәләнең куелу формасы вә тактика ягына килик. Башкортстанда 1925 елны «Башкорд им-

ляһы» дип югарыдагы әсасларда ук тәкъдимнәр белән бер китапчык чыгарганнар икән. Бу китапчык күбрәк мөзакәрә рәвешендә басылганга, бигрәк тә китапчыкларыннан аңлашылганча, алар «башкорд теленең имляһы» татар имлясы белән санашмаска мөмкин һәм тиеш, дип караганга, без алар кузгаткан мәсьәләнең мөзакәрәсенә катнашмый калдык. Ләкин соңгы карарлар шул ук Башкортстанның Уфа каласында булса да, татар имлясын әсасән үзгәртү турында булганга, без бу карарларга туктамый китә алмыйбыз. Татарстан, Казахстан вә башка милли совет җөмһүрият вә өлкәләренең төзелү әсасларыннан берсе, бу милләтнең зур бер кыйсме торган һәм үзе күпчелек тоткан бер даирәне алып, шунда киң халык массасының көндәлек тормышына һәм мәдәниятенә бәйләнгән мәсьәләләр өчен автонум бер идарә төзеп, шул милләтнең бу даирәгә кергән һәм кермәгән кисәкләре өчен мәдәният мәсьәләләрендә турыдан йә кыеклап юлбашчылык итү, таралган көчләрен шунда җыеп нәфис сәнгать, матбугат, әдәбият, тел, сәяси-иҗтимагый, фәнни мәсьәләләрнең шул телдә эшләнүен тәэмин итү, гомумән артта калган мәдәнияте киңәеп, бәллүрләнеп (кристалланып) җитмәгән халыклар өчен, шул тел һәм шул халыкның яхшы якка булган хосусиятләре даирәсендә мәдәниятләрен һәм мәгарифенә бәйләнгән мәсьәлә булганлыктан, мәдәни бәллүрләнүнең төп нигезләреннәндер. Башкортстан кебек татарлар азчылык милләт санала торган бер өлкәдә, йә Сарытау, Пенза, Нижгород кебек бер губернада биш кеше җыелып, комиссия ясап кайбер шәһәр учителләрен җыеп татар имлясының әсасларын үзгәртү турында карарлар чыгарту, бигрәк тә шуларны съездларда һәм төп милли җөмһүриятнең шундый эшләр өчен ясалган учреждениеләре белән хәбәрләшмичә, матбугат һәм мәктәптә гамәлгә куя башлау башбаштаклык һәм мәдәни дисциплинасызлык дип кенә атала ала. Билгеле, һәр җирдә мөзакәрә юлы белән тар даирәдә башлау тәҗрибәләре рәвешендә һәр нәрсәне эшләргә мөмкин. Ләкин мондый тиешле тикшерүсез, шартсыз карарлар тәҗрибә рәвешендә генә булмаган гамәлгә куюлар булмаска тиеш. Юк исә төрле төрек телләренең дә бер бере матбугатыннан файдалануны җиңеләйтү өчен имляларын мөмкин кадәр якынайту мәсьәләләре алда торган бер вакытта, мондый карар һәм гамәлгә куюлар белән без төрле губерна һәм өлкәләрдә бер үк татар телендә язылган һәм басылган нәрсәләрне дә укый һәм аңлата алмау хәленә килербез.

Мәсьәлә белән гомумән таныш булмаганнар, мәсьәләнең эшләнүенә катышмыйча үзләренә эшләнгән нәрсәләргә тавыш бирү бурычын гына алырга тиешләр. Итек ясар өчен итек кия белү генә җитми, итекче булу да кирәк. Имля-язу мәсьәләләрендә һәркем әзерләнми хәл итәргә керешергә тиеш түгел: юк исә урыс һәм азәрбайҗан матбугатындагы мәкаләләрендә «өч, оч, уч, үч» сүзләре бар да бер төрле « اوچ » рәвешендә языла» дип язган Шамил Усманов хәленә төшәргә мөмкин.

Кайбер имлячыларның «янгы» (ут) чыккан кебек, күб үлчәп, сөйләп, күб уйлап тормыйча гарәп әсасындагы язуны ничек булса алай тизрәк «ислах» итәргә, нәтиҗә ягы белән, латинның хәрфен алмасак, һич булмаса, имлясын алырга кирәк, юк исә латин керә, дип кур-

кытып, кабык кагучыларга, андый янгын булмаганын, ут дип күрсәтелгән нәрсә мираж гына булуын әйтеп, мәсьәләләрнең кызулыксыз, кабык кагусыз, үзләренең салмак юллары белән барырга тиешлеген белдерәбез. Хәзерге татар имлясы, «әлифчы, өчмәдче, садтыйчы» гарәп имлясы сөремтесе белән «һәмзәсез, ун мәдче, йче» урыс имлясы сөремтеләренең ун еллар буенча көрәшләре, татар теленең хосусиятләреннән чыгып эшләнгән тикшерүләр, бу турыдагы матбугатта, съезд, киңәшмә һәм комиссияләрдә килеп чыккан фикерләрне хисапка алып һәм шуларның сөземтә (нәтиҗәсе) булып чыккан, моннан дүрт-биш ел элек ныклап дикретләштерелгән бер имля. Бу имля, бөтен төзелеше, кагыйдәләре, китап бите белән бер ярым биткә кереп бетә торган һәм әлифба өйрәткәндә үк төшендереп бетерергә мөмкин булган сөйләшкә (фонетиклыкка) якын булган бер имля. Аңа кадәр 15 еллар буенча безнең имля мәсьәләләре белән чуалуыбыз бездә электән һәр кем бер төрле яза торган нykланган бер имляның булмавы, һәр бер нык нигезле мәдәният өчен моның төп кирәкләрдән булуыдыр. Миллионлап укый-яза белүчесе булган бер халык арасында, ата-бабадан килгән беренче яратылыш һәм төрле сөремтеләр нәтиҗәсе булган имля буталчыклыгы (хаос) эчендә, хәзерге татар имлясы кебек җиңел, садә бер имляны да тәмам гамнәштереп бетерү вазифасы 4—5 ел эчендә генә эшләнеп бетә торган вазифа түгел. Хәзер бөтен татар матбугатының һәм татар халык мәктәпләренең 80—90 проценты, түбән совет мөәссәсәләрендә татар телен ныклап гамәлгә куючы татар эшчеләренең 70—75 проценты шушы имля белән бара, йә шуның белән барырга тырыша. Имля мәсьәләсендә безнең хәзерге дәүрдәге бурычыбыз, яңа мөгезләр чыгару булмаенча, матбугат, мәктәп һәм мөәссәсәләрдә имля дисциплинасын 100 процентка җиткерү, һәм киң укучы гаммәнең күнегүләрен шул юлга салып бетерү вазифасыдыр. Билгеле, безнең имляда әле ныклап кагыйдәгә алынып бетмәгән ялгауларның кайсын кушып, кайсын аерым язу, чит телләрдән кергән сүзләрнең татарчада язылышын ныклап бер юлга кую, тыныш тамгалары йөртелешен билгеләп бетерү кебек мәсьәләләр бар. Бу мәсьәләләр — урнашкан әсасларны бозмыйча, салмак рәвештә, хәлле якын кизүдәге мәсьәләләребездәндер.

Гомумән алганда, имля мәсьәләсен бездә инде җитәрлек бәллүрләшкән бер мәсьәлә итеп карарга һәм якын дәүрдә төп әһәмиятле хәреф ислаһы, әдәби телдәге истилах вә гыйбарәләрне бер калыпка салу мәсьәләләрен бәллүрләштерүгә таба юнәлдерергә тиешбез. Билгеле, болардан бик күп әһәмиятлерәк һәм нигезлерәк булган татар киң гаммәсен иктисади, иҗтимагый яклардан күтәрүне тизләндерү мәсьәләләре бар. Бу мәсьәләләр башка маузуглар булганга без монда аларга кагылмыйбыз.

*Мәгариф. 1926. № 5. 46—57 битләр*

*Басмага әзерләде:* ***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*гомуми лингвистика бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре*

# 2014 ел: КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

*М.З. Зәкиев*

## ТӨРКИЛӘРНЕҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ ИСКЕШӘҺӘРДӘН КАЗАНГА КҮЧТЕ

2014 елның 18 мартында Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми совет үткәрде. Татар телен саклау, үстерү мәсьәләләре турында сөйләштек. Сүз җитди булганлыктан, совет утырышы соң гына тәмамланды. Өйгә кайтып, тамак туйдырып, йокларга ятарга җыенып йөргәндә, телефон шалтырады.

— Бу Төркиянең Эскишеһир *(Искешәһәр)* мэриеннән сезгә мөрәҗәгать итәбез. Төрки гуманитар фәннәренә иң кыйммәтле өлеш керткән галим буларак, сезгә Эскишеһир губернаторы бүләк тапшырырга тиеш, шул тантанага килеп җитүегезне сорыйбыз. Билет алынган, иртәгә, ягъни 19 мартта, иртәнге 4 сәгать 20 минутта Казаннан Истанбулга самолет оча, сез шуңа барып утырыгыз да Төркиягә килегез. Сезне Истанбулда каршы алып, Эскишеһиргә китереп урнаштырырлар, — диде төрек кызы Бабашева Жале.

Мин, йокларга ятып тормастан, әзерләнеп, төнге сәгать 1 дә такси белән аэропортка киттем. Иртәнге 8 дә (аларча 7 дә) мин Истанбулда идем инде.

Искешәһәргә барып җитеп, бер санаторийга урнашкач, кичен безне шәһәрнең иң зур концерт залына «Төркиләрнең бердәмлеге» тантанасына алып килделәр. Җир шарында төркиләр 300 миллион, алар 30 өлкәдә яшиләр, барлык өлкәләрдән дә кунаклар бар, диделәр. Үзара танышып, аралашып алгач, барлык төрки өлкәләрдән килгән артистларның, музыка, бию, җыр коллективларының искитмәле югары дәрәҗәдә оештырылган концертын да хозурланып карадык.

20 мартта 30 өлкәдән килгән күренекле затларны университетның актлар залына алып килделәр. Университет галимнәре — иске танышлар белән очраштык. Шушы актлар залында мин күптән түгел ясаган докладны искә төшерделәр. Мин анда Казан һәм Кырым татарларының монгол-татарлар дәвамы түгеллеге, үз илләрендә күп мең еллар буе яшәп килгән төрки кабиләләр кушылмасы икәнлеге турында сөйләгән идем. Искешәһәр кешеләре татар проблемасы белән кызыксына күрәсең, университет галимнәре хәтерендә минем фикерләр дөрес сакланган.

Искешәһәрдә Казан татарлары да, Кырым татарлары да бик күп. Алар бирегә XIX гасырның соңгы чирегендә күпләп килгәннәр. Казан татарлары Искешәһәрдән ерак түгел авылларда да бар. Мин үзем андагы Османия исемле татар авылында берничә мәртәбә булдым.

Кырым татарлары безнең эрага кадәр үк Кырымда яшәгән таерлар, киммерлар, скифлар, аслар, аланнар, һуннар (сөннәр), хазарлар, болгарлар, мишәрләр (мачар, маҗар) һәм кыпчакларның үзара керешүеннән

туганнар. Моны Кырымның татар галиме Мамет Севдияр исбатлап биргән [Севдияр, б. 539].

Казан татарлары сөннәр (һуннар), аслар, ассөннәр (усуньнар), болгарлар, суаслар (елга буе аслары), борваслар (умартачы аслар), суарлар, кыпчакларның бергә оешуы нәтиҗәсендә безнең эрага кадәр үк барлыкка килгәннәр [Закиев, с. 503 — 507].

Төрле кабиләләрнең Кырым татары яки Казан татары булып оешуына аларның ислам динен кабул итеп, бер дин тотулары да уңай тәэсир иткән. Ләкин Кырым татарлары да, Казан татарлары да XIX гасыр ахырында татар атамасын кабул иткәннәр. Менә шул атамадан чыгып, бөтен дөньядагы тарих дәреслекләрендә хәзерге Кырым һәм Казан татарларын монгол-татар яулары калдыгы дип аңлатмакчы булалар.

21 мартта Искешәһәрнең иң зур тамашалар залында 2014 елда төркиләрнең мәдәни башкаласын Искешәһәрдән Казанга күчерү тантанасы булды. ТҮРКСКОЙ оешмасының бу турыдагы карары игълан ителгәч, Татарстан мәдәният министры бу вазыйфаны кабул итеп алды.

ТҮРКСОЙ ул барлык төрки телле халыкларның мәдәниятен һәм сәнгатен саклау һәм үстерүгә хезмәт итә торган Халыкара оешма. Ул 1993 елның 12 июлендә Алматы шәһәрендә төзелә һәм «Түрк культур вә сәнгатьләренең уртак (ортак) йөнәтиме (идарәсе)» дип исемләнә, аның аббревиатурасы — ТҮРКСОЙ.

Казан шәһәрен 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан итү уңае белән мин укучыларны Казан турындагы төп яңа мәгълүматлар белән таныштырмакчы булдым.

Иң элек Казан сүзенең барлыкка килүе турында берничә сүз. Казан сүзе аш пешерә торган казан сүзе белән туры килә, шуңа күрә шәһәр исемен аш пешерә торган казан сүзе белән бәйләгәннәр. Аш пешерә торган казанны су буенда юганда, ул елгага төшеп киткән, шуңа күрә башта елга Казан исемен алган, соңрак шул Казан елгасы буена утырган шәһәр дә Казан дип атала башлаган имеш.

Казан шәһәре исеменең барлыкка килүен бу легенда белән бәйләү XX гасыр урталарына кадәр яшәп килә. 60 нчы елларда Иске Казан территориясенә барып, аның төрле яктан таулар (ярлар) белән әйләндереп алынганлыгын һәм аларның аш пешерә торган казанга охшаган булуын күреп, кайбер галимнәр Иске Казан атамасын да менә шул аш пешерү казаны сүзеннән алынган дип расларга тырыштылар. Бу тагын бер фантазиягә юл ачты: Казан Кремле дә тауда утыра, ул тау каплап куелган казанга охшаган, шуңа күрә мондагы шәһәр дә Казан дип аталган, дигән фикер әйтелә башлады. Менә шул легенданы мәңгеләштерү теләге белән, газета-журнал редакцияләре йорты янына — Казанка ярына, өстенә аш пешерә торган Казан утыртып, бер никахлашу йорты да төзеп куйдылар.

Казан шәһәре исемен аш пешерү казаны атамасы белән тиңләүгә каршы килеп, танылган топонимист Г.Ф. Саттаров Казан атамасының башта елга исеме булуын һәм аның казыган сүзеннән килүен язып чыкты. Кыпчак телләрендәге казыган фигыле огуз телләрендә казан дип [г] авазыннан башка әйтелә. Казан сүзе елганың су казыган урынын атый, ди ул [Саттаров, с. 41]. Үземнең бер мәкаләмдә мин дә Г. Саттаровның бу фикере белән килешкән идем, ләкин соңрак бу фикернең дөрес була ал-

мавын язып чыктым: шәһәргә исем бирүчеләр аның янындагы елганың төбен тикшереп, анда казыган урын булу-булмавын күреп тормаганнар, күрә дә алмаганнар.

Казан сүзе кеше исеме булган, соңрак ул авылга-шәһәргә исем итеп кушылган, дигән фикер әйтүчеләр дә булды. Чыннан да Казан-Газан исемле затлар тарихта күп теркәлгәннәр, ләкин, Казан топонимы кеше исеменнән алынган, дигән фикер исбат ителмәгән.

Казан сүзе этнонимнан, ягъни халык атамасыннан, килә, дигән фикерне беренче булып Йосыпов әйтә [Юсупов, с. 229], ә азәрбайҗан галиме Г.А. Гейбуллаев «Азәрбайҗанда бер болгар кабиләсенең казан дигән этнонимы да булган» дип яза [Гейбуллаев, с. 36]. Ләкин бу ике автор да үз фикерләрен исбатлау белән шөгыльләнмиләр: Казан сүзенең нинди мәгънә белдерүен, кайдан килүен әйтмиләр.

Татар-төрки тарихы һәм Казан шәһәре тарихы белән шөгыльләнү барышында, мин дә Казан топонимы халык исеменнән килә, дигән фикергә килдем.

Русларның бик борынгы чордан алып 1560 елга кадәр вакыт аралыгы вакыйгаларын теркәгән Львов елъязмасында хәзерге Казан урнашкан урындагы шәһәрне Кусян дип, ә аның халкын кусяне дип атыйлар, диелгән. Бу сүзне А.Х. Халиков һәм Л.С. Шавохин Казан атамасының беренче чыгыш варианты дип таныйлар, ул, куся/кудя/кузя тамырыннан ясалган, диләр, ул борынгы Собекуля топонимында да бар, диләр [Халиков, Шавохин, с. 298—318].

Кусян атамасын Казан сүзенең чувашча — Хузан, удмуртча — Ку зон, марича Озан булуыннан чыгып, мин бу сүзне ку һәм сян өлешләренә бүлеп тикшердем. Соңгы сян өлеше төркичә сөн (һөн/хун) этнонимының русча әйтелеше. Рус кешесенең [ө] авазын [йә] дип әйтүе бик табигый.

Хәзерге татарчада ку ‘агарып кипкән’ мәгънәсен бирә. Кусян/кусөн ‘ак йөзле сөн’ дигәнне белдерә. Ку тамыры тарихи яктан төркичә ко формасында да әйтелә, шуның нәтиҗәсендә кусян сүзеннән Косан сүзе барлыкка килгән. Бу шәһәрне татар халкы бүген дә Косан дип әйтә, Казан дип яза, чөнки ике сузык арасында [с] авазы үзенең яңгырау парына [з] га әйләнә.

Бу Урта Иделдәге Казан шәһәре һәрчак шулай аталганмы, әллә аның башка исемнәре дә булганмы?

Косан атамасы ныгып киткәнче, бу шәһәр башка исемнәрне дә йөрткән. Тюркология фәнендә кусаннарны усунь һәм тохарлар белән тиңләп йөртү гадәте булган [Бернштам, с. 41—47]. Ләкин А.Н. Бернштам, европоцентристик юнәлеш кешесе буларак, бу халыкларны иранлылар дип уйлый. Юк, тохар — ул дагар/тауар ‘тау кешеләре’ дигән төрки сүз. Усунь ул ас+сөн кушылмасының үзгәргән варианты ас+сюн дигәндә соңгы иҗектәге [ю] авазы беренче [а] ның [у] дип әйтелүенә сәбәп була, биредә гап-гади кире ассимиляция күренеше генә бар. Кушан сүзе исә Кусөн/Кусан сүзенең фонетик варианты гына.

Урта Азиядә кунганнарның эфталит дигән төркемнәрен борынгы чорда ук «белые хунны» дип атап йөрткәннәр. Усунь/ассөн сүзенең кусөн сүзе белән параллель кулланылуы, Кусян шәһәренә нигез салуда, сөннәр генә түгел, аслар да катнашкан, дигән фикер тудыра.

Ас кабиләләре дә, сөннәр кебек үк, Евразиядәге төп төрки кабиләләрнең берсе булганнар. Азия ата-

масы да анда аслар күп яшәгәнлектән барлыкка килгән.

Бу кабиләләр барлык төрки халыкларның дип әйтерлек күп элгәрләреннән берсе булганнар, бигрәк тә төркмәннәрнең, үзбәкләрнең, казакъларның, касакъларның: Асхабад/Ашхабад ‘аслар җыелып яши торган урын’, үзбәктәге борынгы Хорезм һуар-ас-ым өлешләреннән тора; казакъның борынгы башкаласы Ас-яс шәһәре була, атаклы Ясәви шул шәһәрдә туып үскән, Кусян тирәсендә суас ‘елга аслары’, бортас ‘бал җыючы аслар’ күпләп яшәгәннәр.

Батый хан монголлар башкаласыннан өч халыкны туздырып ташларга боерык ала: болгарларны, асларны һәм русларны. Аслар — шул ук Косан шәһәре халкы, ул чорда аны Аслы дип тә атаганнар. Бу фикернең дөреслеген тагын шул раслый: руслар Казан ханлыгын яулап алгач, монда халык санын алу үткәрәләр һәм Казан тирәсе халкы үзен суас ‘елга аслары’ дип яздыра. Марилар хәзерге татарны бүген дә әле суас/сюас дип атауларында дәвам итәләр, ә чувашларны суасламари, ‘суаслашкан мари’ дип йөртәләр.

Батый хан Аслы шәһәрен (Косанны) җир белән тигезләп үтә. Бу шәһәр яңадан торгызылгач, аның Аслы исеме түгел, Косан исеме яңадан кайтарыла.

Аслы һәм Косан исемнәре шәһәргә ныклапябышмаган чорда, чит ил сәяхәтчеләре бу шәһәрне крепостъ-кирмән дип кенә атыйлар. Венециялеләр Франциск һәм Доминиг Пициганиләрнең 1367 елда төзегән картасында Кирмән шәһәре Иделнең сул ягында Болгар шәһәреннән ике мәртәбә зуррак итеп ясалган. 1375 елда ясалган Каталон атласы картасында Казан шәһәре шулай ук Болгардан зуррак итеп төшерелгән, һәм аңа Кострома исеме бирелгән. Итальян телендә ул шулай ук ‘крепость’ дигән сүз. XIII гасыр уртасында Кирмән шәһәрендә тәңкәләр сугылган. Бу факт Казан крепостенең Болгарга караганда иртәрәк салынуы турында сөйли.

Косан/Кусан дигән шәһәрләр, Идел буенда гына түгел, башка регионнарда да төзелгәннәр. Алар бигрәк тә Урта Азиядә күп булганнар, чөнки Идел — Уралдагы һәм Урта Азиядәге кусаннарның үзара аралашуы өчен уңайлы су юлы да булган: Урал, Идел, Каспий. Шунысы игътибарга лаек, Урта Азиядәге кусаннар да ак йөзле (блондин) булганнар. Моны зур галим Г.Е. Грум-Гржимайло гаҗәпләнеп язып калдырган [Грум-Гржимайло, с. 342]. Ак йөзле раса — ул төньяк кинлекләре расасы, көньякта алар әкренләп туткыллыга әйләнерләр иде. Шуңа күрә, Урта Азия кусаннары кайчандыр Идел — Уралдан килгәндер, дияргә нигез бар.

Урта Азиядә кусан сүзе кушан дип кабул ителгән, һәм аларны европоцентристлар фарсы телендә сөйләшүче иранлылар дип аңлатырга тырышканнар. Ләкин кушаннар Фирганә янында безнең эра башында ук Касан шәһәрен төзегәннәр, аның янындагы елганы Касансай дип атаганнар. Бу шәһәр борынгы чорда ук төрки ханнарның ял итү шәһәре булган, анда хәзер дә төркиләр (үзбәкләр) яшиләр.

Кушаннар турында гаҗәеп күп әдәбият язылган. Аларда кушаннарның исеме дә төрлечә бирелә: Кусан, Косан, Казан, Кушан, Кошан, Хушан һ.б.

Кушаннар безнең эрага кадәр I гасырда Урта Азиядә бик көчле дәүләт төзегәннәр, моның үзәге башта Арал

тирәсендә булган, соңрак алар А. Македонский төзегән Грек-Бактрия дәүләтен үз кулларына алганнар, Македонский китергән грекларны дәүләт башыннан төшереп, Бактрия дигән төрки дәүләтен төзегәннәр (Бактрия = баг+лы/баг-ты арлар дәүләте —фарсылар түгел, төркиләр дәүләте). Бу дәүләт Кушан дәүләте исемендә безнең эраның I—II гасырларында Урта Азиядән Һиндстанга кадәр булган җирләрне үз эченә алган бөек империягә әверелә, аңа борынгы Хорезм да буйсына.

Кусан ‘ак сөннәр’ этнонимы Кушан империясендә күп төрле топонимнарга нигез булган: Кашан — Ирандагы шәһәр, Әфганстандагы һәм Төркмәнстандагы елга, Кучан — Ирандагы борынгы шәһәрчек, гарәпләр аны Хушан дип йөрткәннәр, Касан — Фирганә янында кушаннар салган шәһәр. Кушан империясе Идел — Уралны да үз эченә алгандыр, дигән фикергә килергә була, чөнки Кама буенда да Кашан шәһәре була.

Безнең үзебезнең тарих фәнендә Казан шәһәрен болгарлар салган, ул Болгар шәһәре булган, дигән фикер өстенлек ала. Бу дөреслеккә туры килми. Бик борынгы чорда ук Казан тирәсендә урта диалектта сөйләүчеләр, ә Болгар тирәсендә мишәр диалектында сөйләүчеләр яшәгәннәр. Бу диалектлар вәкилләре арасында бик борынгыдан килә торган көндәшлек булган, ул хәзер дә шулай дәвам итә.

VI—VII гасырларда ук би-бай кабиләләре Көнчыгыш Европада (Кама елгасының югары агымы регионнарын да шунда кертеп) Биарм (минем Би-ар-ым — бай кешеләрем) дигән бөек ил төзиләр. Рус чыганакларында ул Биармия дип, Скандинавия язмаларында Биармланд дип атала. Менә шул бөек илнең башкаласы Биләр шәһәре була. Бу фикергә шикләнмәскә кирәк, чөнки Биләр кебек бөтен Евразиядә иң олы, иң бай шәһәрне кечкенә ил төзи алмый, аны төзегән ил бик зур булырга тиеш.

Менә шул Биләрдә аксубай (изге чишмә байлары) белән бергә болгарлар (мишәрләр) дә әйдәп баручылар булалар. Шул Биләрдән көч алып, болгарлар Батый хан басып алучыларын өч мәртәбә — 1223, 1224 һәм 1232 елларда тар-мар итеп куып җибәрәләр. Шуңа күрә Батый хан Биләрне җир белән тигезләп үтә, аны яңадан торгызырга мөмкинлек тә бирми. Болгар шәһәре салынгач та Алтын Урда ханнары аны берничә мәртәбә җимерәләр. Болгар Алтын Урда ханы тарафыннан бик нык туздырылгач, болгарлар үз башкалаларын Казанга күчерәләр һәм Казанны Яңа Болгар (Булгар аль Джадид) дип атый башлыйлар. Ләкин Казан кешеләре (урта диалект вәкилләре) шәһәрне мишәр-болгарларга тулысынча бирергә теләмиләр, аңа Яңа Болгар исемен бирдермиләр, Казан исемен саклап калалар. Ул гына да түгел, монда төзелгән дәүләтне дә Болгар ханлыгы дип түгел, Казан ханлыгы дип атыйлар. Рус яулары чорында да Болгар иле Казан ханлыгы дип йөртелә. Руслар бу ил халкын касаны (кусяне), соңрак казанцы исеме белән атыйлар.

Шулай итеп Казан ул болгарлар-мишәрләр шәһәре түгел, ә косаннар һәм аслар салган шәһәр.

Бу мәкаләдә тагын бер мәсьәләне ачыклап үтик. Ул — косаннарның Идел буенда яшәү тарихы.

«Казанская история» елъязмасының кайбер нөсхәләрендә, Казан шәһәре 1177 елда төзелгән, дигән хәбәр бар. Шуңа ияреп А.Х. Халиков 1977 елда Казанга 800 ел була,

дип язды, аны үзенчә исбатларга да тырышты.

Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Р.М. Мусин А.Х. Халиковка һәм Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘһТИ) җитәкчелегенә ышанып, партиянең Үзәк Комитеты белән килештермичә, Казанның 800 еллык юбилеенә бөтен республиканы әзерләде. Вакыты килеп җиткәч, бу юбилейны үткәрергә Үзәк Комитет рөхсәт бирмәде, чөнки рус тарихчылары Казанның яшен Мәскәү яшеннән дә олырак итеп күрәселәре килмәде.

17 ел үткәч, ягъни 1994 елда Казан шәһәре мэры К.Ш. Исхаков ТФА президенты М.Х. Хәсәновтан һәм ТӘһТИ директоры буларак миннән Казанның 1177 елда төзелгәнлеген Мәскәү тарихчылары алдында исбатлауны сорады. ФАсе президенты М.Х. Хәсәнов та ТӘһТИ алдында шундый бурычны куйды. Нәкъ менә шушы сорау Казан шәһәренең яше турындагы мәсьәләне яңадан өйрәнүгә сәбәп булды.

Бу сорауларга тизрәк җавап әзерләү өчен, мин бүлек мөдирләренә Казан тарихы турындагы материалларны тагын бер мәртәбә өйрәнеп чыгарга һәм Казан 1177 елда төзелгән, дигән фикерне расларлык материаллар табарга куштым. Үзем дә бу мәсьәләләрне тагын бер мәртәбә тирәнтен өйрәнеп ачыкладым. Утырышка тагын җыелдык, анда, Казанның төзелү вакытын аның авыл буларак төзелү чорыннан башларгамы, әллә аның шәһәр буларак үсү чорыннан (анда беренче таш крепость салыну вакытыннан) башларгамы, дигән мәсьәләне карадык. Казанның төзелә башлау чорын анда таш крепость салу вакыты белән билгеләргә дигән карар кабул ителде.

Тагын бер утырышта бүлек мөдирләрен: П.Н. Старостинны, С.Х. Алишевны, Ф.Ш. Хуҗинны тыңладык, болар барысы да, Мәскәү галимнәренә Казанның 800 еллыгын исбатлап булачак дип, иске фактларны ныгыттылар, яңа фактлар да китерделәр.

Мин үзем, тел фактларыннан халык тарихын язу эшен башкарып йөрүче буларак, Казан шәһәренең исеме Кусян/Косан (ак сөннәр) исеменнән килүне сәбәп итеп алып, Казанның төзелүенә 800 ел гына түгел, күбрәк икәнен исбатларга тырыштым. Ләкин тарихчылар, тел фактлары белән эш итмәгән кешеләр буларак, минем дәлилләрне игътибарга лаек дип тапмадылар. Мин үзем дә косаннарның Казан Кремле калкулыгында безнең эрага кадәр үк яшәгән булуларын аңлатып җиткерә алмаганмындыр.

Күпчелек тавыш белән Югары оешмаларга Казан 1177 елда төзелгән, аның хәзер 800 еллыгын билгеләү вакыты үтте инде, бары 825 еллыгын (иң якын юбилей елы 825 кенә була ала) 2002 елда үткәрүгә әзерлек башларга кирәк, дигән тәкъдим кабул ителде.

Әгәр дә мин, директор буларак, ТӘһТИ дирекциясенең менә шул карарын югары оешмаларга рәсми рәвештә тапшырган булсам, бәлки 2002 елда Казанның 825 еллыгын үткәрерләр иде дә, шуның белән тынычланган булырлар иде. Ләкин мин, лингвистик һәм башка традицион чыганакларны анализлап төрки һәм болгар-татарларның тарихын язган белгеч буларак, дирекциянең бу карары белән килешмәдем, Татарстанның һәм Казанның җитәкчеләренә бу карарны формалаштырып җибәрмәдем, карарның чынбарлыкка туры килмәвен, Казанның яше мәсьәләсе буенча үземнең дә мах-

сус шөгыльләнергә теләгем барлыгын әйттем, Казан 1177 елда түгел, ә күпкә иртәрәк салынган, аны исбатлавы авыр булмаячак, дидем.

Казанга 1177 елда нигез салынган, дигән фикерне галимнәр тагын да дәлиллерәк итеп исбатлар, дип көтеп торган җитәкчеләр минем хәбәр белән дә килештеләр, ләкин тикшерү нәтиҗәләрен озакка суздыраска киңәш бирделәр.

Казан 1177 елдан күпкә иртәрәк төзелгән, дигән фикер белән ТӘһТИ археологлары һәм тарихчылары килешмәгәч, бу эшкә мин Казан дәүләт университеты археологы Әзһәр Мөхәммәдиевне җәлеп иттем. Ул үзенең — археологик, мин — лингвистик материалларны алга куеп сөйләшкәч, без шундый фикергә килдек: хәзерге Кремль территориясендә беренче торак пунктлары безнең эрага кадәр VIII—VI гасырларда ук барлыкка килгән, Казанның авыл буларак салынуына 2700—2000 елдан да ким түгел. Ләкин Казанның 800 еллыгын да кабул итмәгән Мәскәү тарихчылары каршына 2500 яки 2000 еллык мәсьәләсе белән чыгу безгә реаль булып тоелмады, шуңа күрә Казанга шәһәр буларак кайчан нигез салынды икән, ягъни анда беренче таш крепость кайчан төзелде икән, дигән сорауга җавап эзли башладык. Казанның тарихка кергән беренче исеме дә юкка гына крепость-кирмән (Кострома) булмагандыр. Бераз уйлагач, Әзһәр Мөхәммәдиев: «Казан Кремле территориясендә таш крепостьнең нигезен мин үзем казып карадым, ул X—XI гасырлар тирәсендә салынган булырга тиеш», — диде. Тагын да тикшерә торгач, бу крепостьнең X гасыр ахырында салынуын исбатлап булыр, дигән фикергә килдек. Менә шушы эзләнүләрдән чыгып, без, Казан — шәһәр буларак X—XI гасырлар аралыгында салынган, аңа шәһәр буларак 1000 ел тула, дигән фикерне Республика һәм шәһәр җитәкчеләренә җиткерергә кирәк, дип таптык. 1000 еллык уе белән чыксак, бу датаны исбатлау өчен, Президент та, шәһәр башлыгы да бөтен мөмкинлекләрне тудырырлар, чөнки үзе җитәкче булганда, меңьеллыкны үткәрү — ул тарихи вакыйга булачак, дип, без моның психологик ягын да уйладык.

1995 елның 18 октябрендә Ә. Мөхәммәдиев Казан дәүләт университетының тарих факультеты семинарында 1000 еллык идеясе турында чыгыш ясады. Мин, ТӘһТИ директоры буларак, президентыбыз М.Ш. Шәймиевне «Казанга 1000 ел» дигән фикер белән шатландырдым. Минем бу хәбәрне президент күтәреп алды, шәһәр мэры К.Ш. Исхаковка да шушы хактагы дәлилләрне тыңларга кушты. 1000 еллык барлык инстанциядә уңай кабул ителде, тик миңа, моны нигезләүне тизләтергә кирәк, дигән күрсәтмә бирелде.

Казанның 1000 еллыгын ачу ТӘһТИгә беркетелеп калсын әле дип, мин шәһәр мэры К.Ш. Исхаков исеменә Казанның 1000 еллыгын ачуыбыз турында, директор буларак, үз исемемнән хат яздым. Хатның Институттан шәһәр мэрына тапшыру көне — 1997 елның 16 гыйнвары (чыгыш № 17344/1256/14). Бу хат Казан шәһәренең 1000 еллыгын әзерләү бүлеге архивында әле дә саклана. Мин ул хатта 1000 еллыкны дәлилләүче фактлар китерәм дә, шундый нәтиҗә ясыйм: «Таким образом, при желании можно было бы научно достоверно отнести время возникновения города Казани к концу X в. и на стыке XX—XXI столетий празд-

новать его 1000-летие» (М.З. Закиев).

Шулай итеп Казан шәһәренә 1000 ел дигән фактлар Тел, әдәбият һәм тарих институтында барлыкка килде. Бу информация җитәкчеләргә, галимнәргә һәм халыкка да җиткерелде. 1000 еллыкны рус галимнәрен дә, чит ил галимнәрен дә ышанырлык итеп раслау Тарих институтында башкарылды. Бу эш белән Миркасыйм Госманов җитәкчелек итте.

Казан турындагы төрле фикерләр минем «Казань основана косанами — белыми хуннами» дигән брошюрамда русча тулырак яктыртылганнар.

## Әдәбият


*Бернштам А.Н.* К вопросу об усунь=кушан и тохарах // Советская этнография, 1947. № 3. С. 41—47.

*Гейбуллаев Г.А.* Топонимия Азербайджана. Баку, 1986.

*Грум-Гржимайло Г.Е.* Белокурая раса в средней Азии. СПб., 1908.

*Закиев М.З.* История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие), М., 2008. 560 с.

*Саттаров Г.Ф.* Происхождение полисонима «Казань» // Советская тюркология, 1985. № 5. С. 34—41.

*Севдияр Мамет.* Этюды об этногенезе крымских татар. Нью-Йорк, 1997. 545 с.

*Халиков А.Х., Шавохин Л.С.* Древнейшая Казань // Древняя Казань глазами современников и историков. Казань, 1996. С. 298 — 350.

*Юсупов Г.В.* Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья, Казань, 1971. С. 217 — 231.



***Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы,***
*филология фәннәре докторы, академик,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге җитәкчесе*

# ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ: Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай

«Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы. 2014» программасы кысаларында уздырыла торган мөһим чаралар эстафетасы 13—17 майда Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтына тапшырылды. «Төрки дөньяның күренекле мәгърифәтчеләре: Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» («Türk dünyasini aydinlatanlar: Mehmet Akif Ersoy ve Gabdulla Tukai») дигән халыкара симпозиум бу ел тарихына иң әһәмиятле фәнни вакыйга булып өстәләчәк.

Симпозиум төрки дөньяның танылган мәгърифәтчеләре тарафыннан өйрәнү һәм аларны киң катлау укучыларга тәкъдим итү максаты белән оештырылды. Галимнәр игътибары үзгенә бөтен төрки дөньяга мәгълүм шагыйрьләр Мехмет Акиф Эрсой белән Габдулла Тукайның күпкырлы эшчәнлеге алынды. Төрекләр Госманлы империясенең бөек шагыйре, «Азатлык маршы» (Төркия гимны) авторы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, ислам мәгърифәтчесе (Коръәнне тәрҗемә иткән) Мехмет Акиф Эрсой (1873—1936) иҗаты буенча зур күләмле материал тәкъдим иттеләр. Шунысы игътибарга лаек, бу симпозиумны уздыру идеясен Мехмет Акиф Эрсой исемендәге Философия һәм сәнгать фонды (фондның рәисе — журналист, язучы Мехмет Кемаль Чефчигузели) һәм Казан университетының татар һәм көнчыгыш әдәбиятларын өйрәнеп тикшерү, әдәби һәм мәдәни бәйләнышлар, шушы юнәлештә эшләргә тиешле кадрлар әзерләү мәсьәләләре белән шөгыльләнүчеләр элитасы тупланган Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты күтәреп чыккан иде.

Төркиянең Әнкарә шәһәрендә 1984 елда нигезләнгән бу фонд быел үзенең 30 еллыгын билгеләп үтә. Шуңа бәйле рәвештә анда төрки халыкларның мәдәният, сәнгать һәм әдәбият проблемаларына багышлап күптөрле чаралар оештырыла. «Төрки дөньяның күренекле мәгърифәтчеләре» дигән халыкара симпозиумнар уздыруның да дистә елдан артык чорны иңләгән тарихы бар. Ул Төркиядә генә түгел, башка илләрдә дә — аерым алганда Новопазар (Сербия), Приштин һәм Призрен (Косово), Сарай-Босан (Босногерцек), Каһирә (Мисыр), Алма-Ата (Казакъстан), Бакуда (Азәрбайҗан) үткәрелде, бу илләрнең бөек мәгърифәтчеләренә багышландылар.

Быел Казанда уздырылган симпозиумда төрекләр ягыннан Мехмет Акиф Эрсой исемендәге Философия һәм сәнгать фонды вәкилләре һәм җитәкчеләреннән Фонд рәисе Мехмет Кемаль Чефчигузели (Истанбул), күренекле рәссам Шерхан Чефчигузели (Истанбул), Фондның генераль секретаре, Төркия радиотелевидение компаниясе (ТРТ) идарәсе әгъзасы Мостафа Каракайа (Әнкарә), Фонд әгъзасы Аслан Кочукйолдыз (Әнкарә), Фонд идарәсе әгъзасы Мехмет Акиф Эрбаш (Әнкарә), Фонд әгъзасы Мостафа Полат, Фонд идарәсе әгъзасы язучы Мехмет Четин (Әнкарә) һ.б. катнаштылар.

Быел уздырылган чараның масштаблылыгын төрки дөньяның танылган югары уку йортларыннан симпозиум эшендә катнашырга дип

Казанга махсус килгән галимнәр билгели. Төркия университетлары (Әнкарә, Истанбул, Мәрмәрә, Фратск, Айдын) галимнәренең чыгышлары күренекле якташлары Мехмет Акиф Эрсойның киңкырлы фәнни тикшеренүләренә багышланган иде, алар шулай ук тел, әдәбият һәм мәдәният өлкәсендә татар-төрек багланышларына да шактый киң тукталдылар. Симпозиум эшендә Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Кыргызстан галимнәре кызыклы гына чыгышлар ясадылар.

Симпозиумда Татарстан, Башкортстан, Мәскәү галимнәре дә катнаштылар. Татарстанлылар тәкъдим иткән докладларда татар халкының бөек улы Габдулла Тукайның һәм аның замандашларының киңкырлы эшләнлеге белән бәйле яңа эзләнүләр яктыртылды, һәм алар төрек коллегаларыбызда зур кызыксыну уяттылар. Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэддин Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Гатаулла Баязитов кебек татар халкының күренекле улларына багышланган чыгышлар төрки дөнья мәгърифәтчеләре турындагы мәгълүматларны яңа ачышлар белән баеттылар.

Симпозиум кысаларында КФУ Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтының Г. Тукай үзәгендә Мехмет Акиф Эрсойның тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган, шулай ук төрки дөньяның танылган башка мәгърифәтчеләре портретлары куелган күргәзмәләр эшләде. Татар язучыларының XIX гасырда Төркиядә һәм Европаның башка илләрендә басылып, Госманлы дәүләтенең күренекле коллекционеры, Мехмет Акиф Эрсой исемендәге Философия һәм сәнгать фонды идарәсе әгъзасы Руйан Сойданның (Истанбул) шәхси архивында сакланган 30 лап китапны һәм күргәзмәгә куелган экспонатларны шушы югары уку йортына бүләк итеп бирделәр. Килгән кунаклар күңелендә Болгар тарихи-архитектура тыюлыгында һәм Ак Мәчеттә, Казан Кремлендә, Г. Тукай музеенда булу онытылмаслык тәэсир калдырды.

Мондый киң күләмле фәнни форум уздыру (ул массакүләм мәгълүмат чараларында да зур кызыксыну уятты) алга таба да бергәләп эзләнүләргә бер адым булып тора, фән һәм мәдәният өлкәсендә үзара хезмәттәшлекне үстерү перспективасына юл ача.

***Ф.С. Сәйфуллина,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ МАТДИ БУЛМАГАН МӘДӘНИ МИРАСЫН САКЛАУ ТУРЫНДА

«Матди булмаган мәдәни мирас» төшенчәсе фәнни әйләнешкә соңгы елларда гына керде. Беренче тапкыр әлеге термин 1989 елда ЮНЕСКО тарафыннан Смитсон институты белән берлектә оештырылган фәнни-гамәли конференциядә телгә алына (Каргин А.С., Костина А.В. Сохранение нематериального культурного наследия народов РФ как приоритет культурной политики России в XXI веке // Культурная политика. 2008. № 3. С. 60). 2003 елда ЮНЕСКОның генераль конференциясендә кабул ителгән Халыкара конвенциядә «матди булмаган мәдәни мирас» төшенчәсенә билгеләмә бирелә, һәм ул халыкның, гасырлар дәвамында тупланып, төрле формаларда һәм гамәлләрдә чагылыш тапкан рухи һәм гамәли тәҗрибәсе буларак аңлана. Матди булмаган мәдәни мирас формалары буларак тел, мифология, йола мәдәнияте, музыка, бию сәнгате, халык авыз иҗаты, музыка уен кораллары, халык костюмы, һөнәрчелек белән бәйле җитештерү технологияләре һ.б. аңлана (Международная конвенция об охране нематериального культурного наследия, 17 октября 2003 г., Париж).

Галимнәр тарафыннан еллар дәвамында телгә алынган матди булмаган мәдәни мирасны саклау мәсьәләсе XXI гасырда киң җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Россия Федерациясенең кайбер регионнарында һәм чит илләрдә матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм торгызу өлкәсендә бүгенге көндә берникадәр тәҗрибә тупланган. Татарстан Республикасында да бу юнәлештә эш алып барыла, республикабыз территориясендә яшәүче җирле халыкларның традицион мәдәниятен саклауга зур игътибар бирелә. Шуңа да төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасына багышланган Халыкара конференциянең Казанда узуы очраклы хәл түгел.

Мәдәният елы һәм «Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы. 2014» программасы кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Халыкара төрки мәдәният оешмасы «ТҮРКСОЙ» ярдәмендә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге 16—19 июльдә Казан шәһәрендә «Саклау объекты буларак төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы» конференциясен үткәрде.

Конференция эшендә фәнни үзәк галимнәре, югары уку йортлары укытучылары, мәдәни үзәк һәм иҗат йортлары җитәкчеләре, төрки дәүләтләр (Төркия, Азәрбайҗан, Казакъстан) һәм Россия Федерациясе регионнары (Удмуртия, Чувашия, Алтай, Тыва, Башкортстан Республикалары, Свердловск, Әстерхан, Новосибирск, Киров, Чиләбе, Төмән, Белгород, Самара өлкәләре) вәкилләре катнашты. Конференция эше биш секциядә алып барылды: «Матди булмаган мәдәни мирасны саклауның актуаль мәсьәләләре», «Төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы: тел мохитен саклау мәсьәләсе», «Төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы: ачыклау, саклау һәм өйрәнү», «Төрки халыкларның этник тарихы һәм традицион мәдәнияте».

Конференцияне Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Нигъмәтуллина Гүзәл Азат

кызы ачты. Конференциянең пленар утырышында чит илләрдән һәм өлкәләрдән килгән галимнәр, дәүләт эшлеклеләре үзләренең чыгышларында матди булмаган мәдәни мирасны дәүләт күләмендә саклау һәм өйрәнү мәсьәләсенең куелышына тукталдылар. Россия халык иҗаты йорты генераль директоры, сәнгать фәннәре кандидаты Пуртова Тамара Валентиновна (Мәскәү) үзенең «Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау һәм популярлаштыруның кайбер аспектлары» дип аталган чыгышында Россия Федерациясендә бу өлкәдә тупланган тәҗрибә, «2009—2015 елларда Россия Федерациясе халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклау һәм үстерү концепциясе»нең әһәмияте, аның эчтәлеге, бүгенге көндә концепция нигезендә башкарылган гамәлләрнең нәтиҗәләре белән уртаклашты. Россия халык иҗаты йорты әлеге концепция нигезендә хәзерге вакытта Россия халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы объектларының электрон каталогын төзи һәм Интернет челтәренә урнаштыра. Тамара Валентиновна регионнарны бу өлкәдәге эшне активлаштырырга чакырды. Яшар Шамил углы Гусейнли (Азәрбайҗан Республикасының Мәдәният һәм туризм министрлыгының матди булмаган мәдәни мирасны саклау бүлеге мөдире) Азәрбайҗан Республикасында бу өлкәдә алып барылган эш юнәлешләре хакында сөйләде. Бүгенге көндә Азәрбайҗан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектларының реестры төзелә, мәдәният өлкәсенә караган барлык оешмалар да мәдәни мирасны саклау һәм үстерү инфраструктурасына кереп, бер юнәлештә эш алып барыла. «Хоомей» халыкара фәнни үзәге директоры, сәнгать фәннәре докторы Кыргыс Зоя Кыргысовна тува халкының традицион мәдәнияте, аның бүгенге халәте, тува халкының «тамак төбе белән җырлау» («горловое пение») традициясенең үзенчә-лекләре хакында сүз алып барды. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрова «Татарстан Респуб-ликасында матди булмаган мәдәни мирасны саклау мәсьәләләре: проблемалар һәм перспективалар» дип аталган чыгышында Республика күләмендә бу өлкәдә алып барылган эшчәнлек юнәлешләрен барлады. Фәнзилә Хәким кызы матди булмаган мәдәни мирасны саклау мәсьәләсенең гаять катлаулы булуына басым ясап, аның чишелешендә дәүләт структуралары, фәнни, урта һәм югары белем бирү, мәдәният оешмаларының вазыйфалары билгеләнмәвен әйтеп узды.

Секцияләр барышында конференциядә катнашучы кунаклар тарафыннан матди булмаган мәдәни мирасны дәүләт куләмендә саклау мәсьәләсе хакында сүз алып барылды, матди булмаган мәдәни мирас объектларын туплау һәм фиксацияләү принциплары барланды, төрки халыкларның традицион мәдәниятен өйрәнү һәм системалаштыру проблемалары ачыкланды һәм, матди булмаган мәдәни мирасның бер формасы буларак, тел мәсьәләләре турында фикер алышу булды.

***Л.Х. Дәүләтшина,***
*филология фәннәре кандидаты*

## РИСАЛӘИ-ГАЗИЗӘ

Мәгърифәтче язучы Таҗетдин Ялчыголның (1768—1838) татар китабы, ниһаять, тулысынча диярлек, хәзерге язуыбызда (кириллицада) нәшер ителде (Ялчыгол Т. Рисаләи Газизә. Казан: Хозур, 2014. 496 б.). Аны бастыру өчен әзерләүгә профессор Хатыйп Миңнегулов алынды: ул бу китапның аерым өлешләрен берничә дистә ел буе әкренләп дөньяга чыгара килде.

Китапның әзерләүче тарафыннан язылган кереш өлешендә әйтелгәнчә, әсәрнең тулы атамасы *«Рисаләи Газизә: шәрхе Сөбател-гаҗизин»* ягъни «Газизәгә баглы рисалә: Сөбател-гаҗизин китабына шәрех». «Сөбател-гаҗизин» исә (бу китап татарлар арасында популяр булган) «гаҗизләрнең рухы ныклыгы» мәгънәсендәге дини шигъри әсәр. Аның авторы — Урта Азиядә яшәгән (нәселе буенча Әстерхан нугае) Аллаһияр суфи. Автор ошбу әсәрен тәүдә фарсыча зур күләмле (12 мең бәйтлек ягъни ике баганалап бастырган тәкъдирдә 250 сәхифәлек) итеп язган булган. Шуннан соң якын-яраннарының таләбе буенча кыскартыбрак төркичәгә (иске үзбәк теленә) күчергән. Ләкин ул бу телдә язылышта гади татар укучысы өчен авыр аңлашылган. Һәм Ялчыголның китап яраткан сөекле кызы Газизә әтисеннән ошбу әсәрне халыкчан татар әдәби телендә аңлатып бәян итүен үтенгән.

Т. Ялчыгол «Сөбәтел-гаҗизин»нең һәрбер ике юллыгына диярлек тукталып, сүзләрне аңлатып кына калмый, «Сүз башы»нда Аллаһияр турында киңәйтелгән мәгълүмат бирә. Шулай итеп, бу китапта ике әсәр — «Сөбател-гаҗизин» тексты һәм Т. Ялчыголның аңа язган киң күләмле шәрехе бирелә. Китап башламында Т. Ялчыголның үзе язган хикәясе бар, ахырда, эпилог итеп, шигырьләре китерелгән.

Яңа чыккан басманың мөкатдәмәсендә *(керешендә)* Х. Миңнегулов Т. Ялчыголның үзе һәм аның китаплары хакында тәфсилле мәгълүмат бирә. Т. Ялчыгол үз заманы өчен шактый актив автор булган, бүтән авторларның китапларына бәяннамәләр язган. Татар мәдәнияте өчен аның иң зур кыйммәткә ия хезмәте — «Рисаләи-Газизә»не чын татарча язуы. Аңарга кадәр үк асылда саф татарча диярлек язган Мәүлә Колый, Батырша кебек мөәллифләр *(китап язучылар)* булган, әмма күләме буенча Т. Ялчыгол әсәре элгәрләрен күпкә узган.

Татарча дигәннән, моны ачыклау фарыз: Ялчыгол телендә *бән* — мин, *варды* — барды, *дөшендә* — төшендә, *ирде* — иде, *итдеке* — иткән, кылган кебек берничә сүз һәм **-быз**//**-без** кушымчасының *-мыз*//*-мез* варианты киң кулланыла. Ул сүзләр аның әсәрләре телендә дә булып, аңардан соң озак кына еллар кулланылганнар да. Боларны «халык аңламагандыр» яисә «халык аңламасын өчен язылгандыр» дип бәяләү дөрес үк булмас иде. Ни өчен дисәң, уйлап караганда, ул сүзләрнең заманындагы китаби телдә «экологик» урыны булган. Еш кына алар омонимиядән качу һәм телдәге төгәллек чарасы буларак кулланылган. Мәсәлән, **дөш** дип язу бу сүзне икенче мәгънәдәге

**төш** сүзеннән ачык аерган; *-дыкы//-деке* кушымчасы «халык телендәге» *-ган//-гән, -нан//-нән* кушымчасын ике мәгънәле (үткән заман хикәя фигыль кушымчасы һәм сыйфат фигыль кушымчасы) булудан коткарган. Китаби телдәге *-мыз//-мез **(кызымыз, үземез** һ.б.)* логик яктан отышлы — төрләнештә мантыйксыз *-м → -б* күчешеннән ***(беләм, беләбез)*** һәм омонимик форматлыктан коткара: *укучыбыз* «без укучы» — *укучымыз* «безнең укучы» һ.б. Гомумән, язма телнең сөйләм теленнән аерылуы закончалык-лы һәм мотлак кирәкле шәй булган. Инде «халыкка аңлашылмаган» сүзләргә килгәндә, хәзерге әдәби телебездә дә рус теленнән һәм рус теле аша Европа телләреннән алынган бик үк аңлашылып бетми торган термин сүзләр азмы әллә? Куллану ешлыгы җәһәтеннән караганда да Т. Ялчыгол телендә саф татарча яңгырашлар, формалар һәм лексемалар зур өстенлек тәшкил итәләр. «Туган тел» мәсьәләсе гади генә түгел. Т. Ялчыголга замандаш рус әдәби (Сумароков, Рычков һ.б.) телендә дә хәзерге рус телендә кулланылмаган сүзләр күп кенә. Аңа карап, руслардан беркем дә «XVIII гасыр теле — рус теле түгел» дип игълан итми.

Бу темага тукталуның сәбәбе шунда: кайбер башкорт әдипләре һәм телчеләре «XX гасырга кадәр татар әдәби теле булмаган» дип язгалыйлар. Юк инде, әфәнделәр, Т. Ялчыгол теле — фонетик, грамматик һәм лексик җәһәтләрдән дә, нигездә, татарча. Анда татарча фразеология һәм морфология өстенлек итә, тик татар телендә генә булган сүзләр, тәгъбирләр бар.

Х. Миңнегулов кайбер башкорт филологларының Т. Ялчыголны үзләштерүгә тырышуларын бик әдәптакт белән генә кире кага. «Гәрчә Таҗетдинның әтисе башкорт булса да, — ди ул, — Таҗетдин үзе һичкайчан башкортча язмаган, үзен «башкорт Ялчыгол углы» дип атамаган һәм «башкортмын» дип игълан итмәгән».

Х. Миңнегулов зур эш башкарган, әлбәттә. Ләкин ул үзе үк әйткәнчә, монда тагын күп кенә эш башкарасы бар әле. Һәм китап үзе дә, Х. Миңнегуловның баш мәкаләсе вә тексты да «тәнкыйтькә мохтаҗ».

Иң мөһиме — китап азагында аның мөндәриҗе *(эчтәлеге)* күрсәтелмәгән. Моны берничек тә аклап булмый билгеле.

Х. Миңнегулов «Рисаләи-Газизә» текстына үз сүзләрен кушып җибәргәли. Нәтиҗәдә, кайбер очракларда Ялчыгол сүземе, Миңнегулов сүземе икәнлеген белү мөхаль *(мөмкин түгел)*. Х. Миңнегулов язып киткән *көнчыгыш* (**шәрекъ** диясе урынга, к. б. 80), *күчерелмә мәгънә* (б. 390), *метафора* (б. 393), *рифма* (б. 131, 163 һ.б.), *синоним* (б. 191), *сүзтезмә*, *синтаксис* (б. 109) кебек тәгъбирләрне Т. Ялчыгол, мөгаен, кулланмагандыр. Ялчыгол текстын үзгәрешсез бирә барып, кайбер сүзләренең аңлатмасын астөшермәдә бирү юлын сайларга кирәк иде.

Транскрипциядә дә төгәлсезлекләр шактый. Х. Миңнегулов татар норматив сүзлекләрендә инде кабул ителгән язылышларны да үзенчә язып киткәли. Һәм шигырьдә иҗекләр саны (Аллаһияр суфи 11 иҗекле шигырь белән язган), ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашуы да искә алынмаган.

*Ничек кем тотды туфан дәшт, тагы (дала һәм тауны)* — **10 иҗек**,

*Вәләкин булмады һәүлә Нух аягы* (б. 48), — **12 иҗек!**

*Дөресе: Ничек кем тотды туфан дәшт-ү-тагый,* —**11 иҗек,**

*Вәләкин булмады һүл Нух аягы.* — **11 иҗек!**

Монда «юеш» мәгънәсендәге сүз формасы вә яңгырашы да *һәүлә* түгел, — *һүл*.

Татар телендә инде *челлә* дип кабул ителгән сүз, ни өчендер, *чәллә* дип язылган (б. 49). Транскрипциядә төп текстта булмаган *ы—е* авазлары өстәлеп китә:

*Балык карынында бер сахибе-кәрамәт* — **13 иҗек!**
дип язылган, ә дөресе:

*Балык карнында сахиби-кәрамәт* ... — **11 иҗек!**

Х. Миңнегулов даими рәвештә ике юллык шигырьне **бәет** дип яза (б. 42, 72, 74, 243, 313 һ.б.). Хәлбуки татар әдәби телендә **бәйт** — ике юллык шигырь берәмлеге, ә **бәет** — фольклор жанры. Бу сүзләрне аерырга кирәклеген күренекле галим һәм әдип Нил Юзиев 1950 нче елларда ук махсус язып чыккан иде. Аларның чыганагы бер — гарәпчә бәйт, ләкин бер алынма сүздән ике, хәтта өч һ.б. сүз ясалу сүзләр тарихында еш очрый. Татар телендә андыйлар аеруча күп. Һәм гарәп фольклорында безнең бәеткә охшаш жанр да юк бугай — ул бездә барлыкка килгән.

Х. Миңнегулов иске телдән хәзерге язмага күчергәндә оригиналдагы өч төрле грамматик аффиксны бер төрле бирә: татарча өченче зат тартык кушымчасы *-е* не дә, фарсыча изафә кушымчасы *-и* не дә, угыз төркемендәге төркиләрдә кулланылучы төшем килеш кушымчасы *-ый//й* не дә бер үк *-е* белән транскрипцияли.

*Имәс мәүҗуд аның дик гәүһәре пак* (б. 66) [*аның гәүһәре пакьме?* Хәлбуки сүз берәүнең гәүһәре турында түгел, ә ул үзе гәүһәргә тиңләштерелә.]

*Дәлил улдыр ки, киде таҗе ләүләк.*

Дөресе:

*Имәс мәүҗүд аныңдик гәүһәрипакь*

*Дәлил улдыр ки, киде таҗиләүләк* [пәйгамбәрлек билгесе]; чагыштыру кушымчасы **-дик** (хәзерге татарчасы *-дай//дәй, -тай//тәй*) төп сүзгә кушып языла икәнлеген дә әйтеп узыйк.

*Ирер ул гадел, әй,* ***фәрзәнде адәм*** (б. 90) *[фәрзәнде — баласы адәмме?]*

Кирәк иде:

*Ирер ул гадел, и, фәрзәнд**и** — адәм [адәм баласы].*

*Алардан соңра һичкем җаларыга,*

*Йитешмәс бәлки* ***хаке паларига****.* (б. 115).

Кирәк иде:

*Алардан соңра һичкем җайларига [урыннарына]*

*Йитешмәс, бәлки, хак**и**-пайларига [аяк тузаннарына] һ.б.*

Төрекчә, угызча -ый//и (гомумтөрки *-ный//ни*, татарча *-ны//не*) — төшем килеш кушымчасы. Аны *-ый//и* дип бирү, минемчә, хәерлерәк булыр иде.

*Ничек кем тотты туфан дәшттагы...* (б. 48)

Дөресрәге: *Ничек кем тотты туфан дәшт-ү-тагый* ... булыр.

Кайбер урыннарда транскрипция ясаучының татар әдәби телендәге сүзләрне мәгънә ягыннан урынлы кулланмавы да чагылып китә. Әйтик: *бер дәм* «бер тын, бер тапкыр» урынына *бердәм* (б. 137); *хәвез* урынына *хоуз* дип, *мис* урынына *мәс* дип (б. 157, 248) һ.б. *Җиймә* (ашама) дигән сүзне *җыйма* дип яза, ягъни (сүзлекләрдә аерым бирелеп килгән) җи-ү «ашау, ашалдыру» һәм җый-у «өлешләрне берләштерү» сүзләрен бутый. Хәлбуки алар төптән аерылалар: борынгы төрки

тел сүзлекләрендә үк *җыю* («собирать») сүзенең тамыры *йыг-* дип, ә *җию* «ашау» сүзенең тамыры *йә-* дип күрсәтелә. Әмма *җыю* һәм *җию* сүзләрен буташтыру электән килә. Аңа К. Тинчурин да игътибар иткән һәм ул аларның аермасын күрсәтеп, *син җиләк җыярсың, ә мин җиярмен* дигән шаян сүзне бер пьесасында китерә.

Күп кенә урыннарда *бизар* «зар эчендә» урынына *бизәр* дип язылган (мәсәлән, б. 379).

433 биттә *гөнаһсаз* «гөнаһ кылучы» диясе урында капма-каршы мәгънәдәге *гөнаһсыз* сүзе язылган.

Иске текстлар белән эш итүче татар әдипләре һәрдаим иске (гомум-төрки) *үч-ү* «сүнү» урынына *очу* дип язып киләләр. Мәсәлән, әлеге текстта да *янып торган ут очып* ... диелә (б. 299).

Китапта транскрипцияләнгән Ялчыгол шигырьләре текстында да хаталар булырга мөмкин, чөнки аларда ябык һәм ачык иҗекләр, рифмалар бозылып кына тора. Ләкин бу мәсьәләдә Х. Миңнегуловны гаепләп булмый. Чөнки бик искечә язылган шигырьләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую махсус тикшеренүдән соң гына була ала. Мәсәлән:

*Мөселман гакыйлә балигъ ир инсан —*

*Имамәт тарты будыр,* ***әй*** *мөселман*

дигән юлларны минем тыныш билгеләрне куеп,

*Мөселман, гакыйлы балигъ, ир инсан —*

*Имамәт шарты будыр, и, мөселман,*

дип язасы килә. Ләкин бу да дөрес булырмы икән әле?

Х. Миңлегулов «Рисаләи-Газизә»-нең вариантлылыгы турында яза. Чынлап та, миндәге Т. Гайни-Лабити әзерләгән вариантта Х. Миңнегуловта булмаган пассажлар бар шикелле. Шулай ук иң соңгы басмада Муса г-м турында бер эпизод сөйләнелсә, Т. Гайни-Лабити хикәяләрендә икенчесе китерелә...

Гомумән, «Рисаләи-Газизә» берничә авторның — татар шәкертләре, маҗаралы хикәятләр белән мавыккан муллалар һ.б. тарафыннан язылган хикмәтле хәлләр һәм изге затлар, пәйгамбәрләр һәм әүлияләр, Алланың каһәре вә рәхмәте һ.б.лар турында язылган җыентык булып күз алдына килә башлый. «Рисаләи-Газизә» коллектив дини-әфсанәви антология шикелле. Әмма, андый тәкъдирдә дә, Т. Ялчыгол хезмәтенең әһәмияте кимеми, чөнки бу эшне ул башлаган, аны бүтәннәр дәвам иткәннәр булып чыга.

***Әхмәтьянов Рифкать Газизьян улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ: УДМУРТИЯ ТАТАРЛАРЫ

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлегенең зур бер тармагы — татарлар яши торган төрле төбәкләргә махсус чыгып, җирле халыкның рухи һәм матди мирасын һәрьяклап өйрәнү. Институт оешканнан алып, 75 ел буена шушы юнәлештә туктаусыз эш алып барыла. Фәнни экспедицияләрне оештыру халыкныкын халыкка кире кайтару максаты белән тыгыз бәйле. Халыктан җыелган мирасның үз вакытында тарихка кертелүе, теркәлгән материаллар нигезендә өр-яңа фәнни хезмәтләр язылу, бер яктан, фән өчен зур казаныш булса, икенче яктан, шушы тере хәзинәнең, басма сүзгә әверелеп, китап булып чыгуы халыкның үзе өчен гаять тансык. Татарларның китапка хөрмәт белән каравы уку-язуга мөкиббән, китапка хирыс халык булуларыннан килә, шуңа да язуга теркәлгән сүзнең теге йә бу төбәк татарының үз авызыннан, йә үзе турында булуын күрүе, үзенә турыдан-туры кагылышлы китапны кулына алуы — халкыбыз вәкилләре өчен зур вакыйга.

Халыктан тупланган байлыкны фәнни-популяр әйләнешкә кертүнең соңгы елларда оптималь ысулы булдырылды. Комплекслы фәнни экспедиция нәтиҗәләре, 2010 елдан башлап, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле аерым серия булып дөнья күрә. Бу — фән алгарышы өчен дә, шушы эшнең башында торган Институт өчен дә, галимнәр белән әңгәмәдә катнашып, фактик материал туплануга үзенең зур өлешен керткән информантлар өчен дә бик күркәм күренеш. «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә аерым төбәкләргә багышлап китаплар чыгару идеясе озак еллар дәвамында туплана килгән материалларның күплеге һәм соңгы елларда оештырылган комплекслы экспедицияләр вакытында шушы җирлеккә хас өр-яңа мәгълүматлар өстәлә тору, аларны билгеле бер форматка җыйнау ихтыяҗыннан да килә.

Әлеге сериядә чыгарылып, яңа гына табадан төшкән китап «Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» дип атала (Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан: ТӘһСИ, 2013. 384 б.). Исеменнән үк аңлашылганча, китап Удмуртия Республикасында гомер итүче милләттәшләребезгә багышланган. Нигездә бу китап Удмуртиянең татарлар яши торган авылларына 2012 елда Институт оештырган комплекслы фәнни экспедиция нәтиҗәсе буларак дөнья күрде. Биредә Удмуртия татарларының көнкүреше, гореф-гадәт, йолалары, тел үзенчәлекләре, фольклоры урын алган. Җыентык халык белән аралашкан галимнәрнең, аспирантларның борынгы ташъязмалар, нәсел шәҗәрәләре, төбәк тарихы, халык авыз иҗаты, биредә яшәгән күренекле шәхесләр, җыргамоңга, хикмәтле сүзгә маһир, шәмаилләр язу яисә матур корылмалар төзү эшен белгән кешеләр һәм җирле осталар теккән, чиккән, тукыган кул эшләре һ.б. турындагы язмаларын берләштерә. Күренекле галимнәр белән бергә яшь галимнәрнең әлеге мөһим эштә катнашулары игътибарны җәлеп итә. Удмуртиядә яшәүче татарларның рухи тормышыннан бер сәхифә булган әлеге китап, һичшиксез, үз укучысын табар, андагы язмалар фәнни һәм фәнни-популяр

җәһәттән киң даирәдә зур кызыксыну уятыр, дигән ышаныч бар.

Әйткәнебезчә, халкыбыз вәкилләре яши торган төбәкләргә уздырылган экспедицияләрдә тупланган байлыкны китап итеп бастырып чыгару эшендә монысы беренчесе түгел, соңгы елларда бу гамәл Институт тарафыннан традицион рәвештә башкарыла килә.

2009 елда Татарстанның Актаныш районына үткәрелгән комплекслы фәнни экспедиция нәтиҗәсе буларак, «Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш» (2010) дигән китап дөнья күргән иде. Әлеге китап — югарыда аталган сериядә чыгарылганнарының тәүгесе. Китап, Актаныш төбәгенең күренекле нәселләре һәм авыллары тарихын, татар теленең, фольклорының шушы төбәккә һәм заманга хас үзенчәлекләрен, халык талантларының матди һәм рухи иҗат өлгеләрен яктырткан басма буларак, киң катлау укучыларда кызыксыну тудырды. Җыентыкка татар шәҗәрәләренә, эпиграфик һәм археографик эзләнүләргә, авыллар тарихына, сөйләм, йола, көнкүреш үзенчәлекләренә, традицион һөнәрчелек һәм декоратив-гамәли сәнгатенә, поэтик һәм музыкаль фольклорына багышланган мәкаләләр кертелгән.

Экспедиция материалларын китап итеп чыгару эшендә 2011 ел аеруча нәтиҗәле булып, Институт бу елда шушы юнәлештә берьюлы ике төбәккә багышланган ике китап чыгаруга иреште. Китапларның берсе «Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород», икенчесе исә «Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас» дигән исем белән басылды. Боларда шушы төбәкләрнең үзенчәлекләрен чагылдырган лингвистик, топонимик, ономастик материаллар, халык музыкасы, фольклоры, сәнгате үрнәкләре, шәҗәрәләр, кульязма мирас һәм ташъязмалар, традицион кәсепләр турындагы мәкаләләр урын алган. Китапларның һәр икесе бай, мавыктыргыч эчтәлекле булуы белән үзенә тарта.

Мари Эл Республикасында көн күрүче милләттәшләребез тормышкөнкүрешен өйрәнү максаты белән 2011 елда уздырылган комплекслы экспедиция материаллары да, башкалары кебек үк, соңгы елларда гамәлгә куелган махсус сериядә «Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге» исемле аерым китап булып басылды. Китап авторлары арасында Институтның күренекле галимнәре белән бергә фән дөньясына яңа аяк баскан белгечләр дә бар. Мәкалә авторлары тарафыннан Бәрәңге районында яшәүче татарларның рухи дөньясына төрле юнәлештә күзәтү ясалган.

Шул рәвешчә, әлеге сериядә инде биш китап — Түбән Новгород, Апас, Мари Эл (Бәрәңге), Актаныш, Удмуртия татарларына багышланган җыентыклар — дөнья күреп өлгерде, Татарстанның Чүпрәле, Кукмара, Мамадыш районнары, Пермь краеның Барда районына, Әстерхан өлкәсенә оештырылган фәнни экспедиция материаллары аерым китап итеп басмага әзерләнде. Омск, Самара өлкәсендә халыктан җыеп алынган тел һәм мәдәният, авыз иҗаты, сәнгате һ.б. үрнәкләргә этрафлы күзәтү-анализ ясауны күздә тоткан китаплар шулай ук үз чиратын көтә.

Бу китапларның чыгуы Институт галимнәре экспедициядән туплап алып кайткан барлык материалларны да шуларга сыйдырып бетергән, җыйналган хәзинәләр тиешенчә тик-

шерелеп, анализланган, соңгы ноктасы инде куелган, дигән чикләү куймый. Экспедиция вакытында халыктан алынган материаллар фәнни максатларда башка чыганакларда да кулланылачак әлбәттә. Галимнәрнең халык белән аралашудан хасил булган фикерләрен, табышларын әлеге сериядә китап итеп әзерләп чыгара тору материалларны беренчел куллану буларак кыйммәт.

Халык арасында булу, халык белән аралашу, тел, фольклор, музыка һәм рәсем сәнгате, археография һ. б. өлкәләргә караган җәүһәрләр белән турыдан-туры танышу — Институт оешканнан алып бүгенге көнгәчә тотрыксыз алып барыла торган әһәмиятле эш юнәлеше, дигән идек. Чыннан да, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә чыккан һәм чыгып килә торган китаплар — тере формада халыкта яши торган тиңсез байлыкны туплаган һәм рухи кыйммәтләрне фәнни-популярлаштырып характерлау-анализлауга корылган тарихи сәхифә. Күп гасырлык тормыш тәҗрибәсен, зирәк акыл, тапкыр фикерләрне үзенә сыйдырган милли-мәдәни мирасыбыз үрнәкләре берсе дә белгечләр игътибарыннан читтә калмаган, китапка теркәлгән, бәя алган. 1940—1950 нче елларда ук атаклы Хәмит ага Ярми кебек галимнәребез иңләп алып барган игелекле гамәл бүген киң колач, яңа көч белән дәвам итә, алай гына да түгел, экспедиция материалларын махсус сериядә китап итеп әзерләп чыгару халык җәүһәрләрен халыкка кире кайтару эшенең заман таләбенә ярашлы итеп тәкъдим ителгән яңа бер дулкыны дип тә бәяләнергә хаклыдыр.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре кандидаты*

# Т.Н. КРИВОШЕЕВА. СКУЛЬПТУРА ТАТАРСТАНА: ИСТОКИ, СТАНОВЛЕНИЕ, ТРАДИЦИИ

Татарстанның тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгате тарихы белән кызыксыну соңгы елларда аеруча активлашып китте. Кызганыч, хәзерге заманның сынлы сәнгате үзенчәлекләре, аның алдагы эволюциясе проблемалары кайбер сәбәпләр аркасында әлегә кадәр билгечләр игътибарыннан читтә кала бирде. Сәнгать фәннәре кандидаты Т.Н. Кривошееваның кызыклы һәм яңача тикшеренүләре бу бушлыкны тутыруда уңышлы гына адым булып тора (Кривошеева Т. Н. Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. Казань: Отечество, 2013. 256 с.). Кандидатлык диссертациясе нигезендә эшләнгән бу китапны (фәнни җитәкчесе — Р.Р.Солтанова) тасвирый сәнгатьнең аерылгысыз өлеше булган скульптураның үсеш юлларын ачыклауда беренче омтылыш дип бәяләргә дә мөмкин. Автор бу төр сәнгатьнең башлангычы татарларның Урта гасырларда яшәгән бабаларына ук барып тоташуын тойган, аның алга таба үсешен ачыклаган һәм шул җирлектә күтәрелгән Татарстан скульптурасының XIX—XX гасырлардан бүгенгә кадәр дәвердәге үзенчәлеген тотып ала белгән. Татарстанда сынлы сәнгать формалашуын анализлауны Т.Н. Кривошеева Урта гасырның башлангыч чорыннан ук — борынгы төркиләрнең һәм кыпчакларның таш сыннарыннан, монголлар явына хәтле дәвердәге идел Болгарстаны гамәли сәнгате предметларыннан, Алтын Урда һәм яңа идеяләргә, сәнгатьчә образлар тудыруга хирыс осталарга бай Казан ханлыгы заманындагы ташка уелган бизәклардән, каберташларыннан башлый. Автор борынгы сәнгатьнең стилистик үзенчәлеген, аның рухының бүгенге татар рәссамнары иҗатындагы чагылышын бик нигезле итеп дәлилли. Бу аеруча безнең скульпторларыбызның яратып иҗат иткән геройлары — Шүрәле образында һәм башка фантастик персонажларда ачык күренә.

Аңлашыла ки, скульптура сәнгате буш җирдән күтәрелеп чыкмаган. Мин бу өлкәдә тикшеренүчеләр игътибарын аның ерак тамырларына — б.э.к. I меңьеллыкта яшәгән күчмә кабиләләр (скифлар, төркиләрнең борынгы бабалары, һуннар) заманына ук юнәлтәсем килә. Шул чакта ук гамәли сәнгатьтә агачны, ташны уеп бизәкләү, зооморф һәм антропоморфка нигезләнгән сурәтләр (алар кайчакта гадәттән тыш зурлыкта булганнар) тудыру әһәмиятле урын алып торган. Ә борынгы төрки сыннар, Евразия далаларындагы кыпчаклардан калган таш һәйкәлләр — чын скульптура әсәрләре. Алар сәнгать билгечләреннән аеруча җитди якын килүне таләп итә.

Т.Н. Кривошеева китабында XVIII—XX гасыр сынлы сәнгате тирән һәм киңкырлы итеп яктыртылган. Бу хезмәтендә автор күптөрле чыганакларга — ТР милли музее, ТР сынлы сәнгать дәүләт музееның Фәнни архивы, «Казан» миллимәдәни үзәге тупланмаларына таяна. Чиркәү скульптурасына кагылышлы бүлекләрдәге Аркатово (Питрәч районы), Олы Кабан (Лаеш районы) авылларындагы һәм өяз шәһәре Зөядәге Троицк чиркәүләре турында аеруча кызыксынып укыйсың.

Соңгырак дәверләрдәге скульптура үсеше үзенчәлекләре ае-

рым осталарның иҗади мисаллары үрнәгендә яктыртыла. Әйтик, татарлардан беренче профессиональ скульптор, Дәүләт Эрмитажының талантлы рәссам-реставраторы Мирзаҗан Байкиев, Император сәнгать академиясендә белем алган, Казан сәнгать мәктәбенең скульптура бүлегенә нигез салган Прокопий Дзюбанов, шушы ук мәктәпнең күренекле вәкилләре Василий Богатырев, Яков Кац, Григорий Козлов һ.б. турында тирән мәгълүмат бирелгән. Россиянең күренекле рәссамнарыннан саналган Николай Фешинның иҗади портреты аның сынлы сәнгать өлкәсендәге казанышларына анализ белән тулыландырылган. Т.Н. Кривошеева фикеренчә, Фешин тарафыннан иҗат ителгән татар малае Салаватулла милли портрет мәктәбе формалаша башлауны белдерә, бу юнәлеш Бакый Урманче һәм XX йөзьеллыкның башка татар скульпторлары иҗатында үсеш ала.

Китапта Татарстандагы заманча сынлы сәнгатьне фәнни яктан өйрәнеп тикшерүгә шактый зур урын бирелгән. Станок һәм монументаль скульптураның тематикасы һәм жанрлары үзенчәлеген билгеләп һәм аның алдагы үсеш тенденцияләрен ачыклап, Т.Н. Кривошеева киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш скульпторлар Вәсил Маликов, Илдар Ханов, Асия Миңнуллина хезмәтләренә мөрәҗәгать итә. Авторның бүгенге татар скульптурасындагы вазгыятьне дөньякүләм сәнгать үсеше процессы яссылыгында күз алдына китерергә омтылуы да игътибарга лаек. Ул аны, татар халкының тарих тудырган мәдәнияте һәм этнопсихологик үзенчәлекләреннән чыгып, рәссамнарның мәҗүси һәм ислам мәдәнияте архетиплары белән кызыксынуы көчәя баруга китереп тоташтыра.

Китапны уку һәм андагы бай иллюстратив материаллар белән танышу укучыда Татарстанда скульптура үсеше этаплары турында гына түгел, ә гасырлардан килгән традицияләрне дәвам итүче бүгенге сәнгать тәҗрибәсе хакында да тулы күзаллау уятачак.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы*

# ИҖТИМАГЫЙ-ФӘННИ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**2014 елның 21—22 мартында** Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты делегациясе Башкортстанның Стәрлетамак районында булып кайтты. Сәфәр дәвамында галимнәр берничә чарада катнаштылар. Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы үткәргән «XXI гасыр төрки филологиясе: проблемалары һәм перспективалары» исемле Россиякүләм фәнни-практик конференциядә чыгышлар ясалды. Ауыргазы районы, Солтанморат авылында Г. Ибраһимовка багышланган чаралар үткәрелде, Ауыргазы районы администрациясе тарафыннан Институтка Г. Ибраһимов исемендәге премия тапшырылды. Курманай урта мәктәбендә исә галимнәр балаларга аларның танылган якташлары тюрколог галим Г.Х. Алпаров һәм тарих фәннәре докторы, профессор М.К. Мөхәррәмов турында лекцияләр сөйләделәр.

**2014 елның 22 апрелендә** Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтында танылган татар тарихчысы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Н. Әхмәровнең тууына 150 ел тулуга багышланган регионара фәнни-гамәли конференция булып узды. Чара Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзеге тарафыннан оештырылган иде. Конференция барышында Г. Әхмәровның татар халкы барлыкка килү мәсьәләсенә карашлары, аның мөгаллимлек эшчәнлеге, вакытлы басмаларда дөнья күргән мәкаләләре, иҗтимагый эшчәнлеге һәм башкаларга игътибар бирелде.

**2014 елның 29 апрелендә** Казанда «Милли һәм гомумкешелек кыйммәтләр системасында фольклор» дип исемләнгән халыкара конференция булып узды. Әлеге чара күренекле фольклорчы галим Хәмит Ярминең тууына 110 ел, ә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына 75 ел тулуга багышланды. Конференциянең тематикасы шактый киң булып, үз кысаларына Х. Ярминең мирасын барлау һәм өйрәнү, татар фольклоры фәне, гомумән фольклористиканың бүгене шартларда торышын күзәтүгә багышланган иде. Конференция эшендә, Төркия (Адыяман), Казакъстан (Алматы), Үзбәкстаннан (Ташкент, Нукус) килгән кунаклар белән бергә, Россиянең төрле төбәкләреннән дә галимнәр катнашты.

**29 апрельдә** Ижау шәһәренең Халыклар дуслыгы йортында Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнгән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» җыентыгын тәкъдим итү булды. Әлеге хезмәт Институт тарафыннан Удмуртиягә оештырылган экспедиция материалларына нигезләнеп әзерләнде. Хезмәт Институтта чыгып килә торган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясенең бишенче китабы булды. Презентация Удмуртия татарлары автономиясе белән берлектә оештырылды.

**30 апрельдә** Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә

«Төрек әдәби мирасының татар рухи дөньясындагы роле» темасына халыкара дәрәҗәдәге түгәрәк өстәл үткәрелде.

**16 майда** Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында яшь галимнәр һәм аспирантларның традицион «XXI гасыр фәне: филология һәм сәнгать белеме мәсьәләләре» исемле фәнни-практик конференциясе булып узды.

**23—26 майда** Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты делегациясе фән эшләре буенча директор урынбасары О.Р. Хисамов җитәкчелегендә Казакъстанның Алматы шәһәренә эшлекле сәфәр кылды. Галимнәр М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институты, А. Байтурсынов исем. Тел белеме институты, Әл-Фараби исем. Казакъ дәүләт университеты коллективлары белән очрашып, алардагы эш тәҗрибәсе белән таныштылар. Үзара сөйләшүләр нәтиҗәсе буларак, ике яклы килешүләр төзелде.

**2014 елның 27—29 маенда** Казан университеты профессоры, ТР ФА академигы М.Г. Госмановның (1934—2010) 80 еллыгына багышланган «Төрки-мөселман дөньясы: бердәмлек, мирас һәм өйрәнү перспективалары» дип исемләнгән халыкара фәнни конференция булып узды. Ул Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Россия тарих җәмгыяте, Россия көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыяте, «Җыен» Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм өйрәнү җәмгыяте тарафыннан әзерләнгән иде. Конференциянең пленар һәм секцион утырышларында, түгәрәк өстәл артында Алтын Урда һәм аның мирасы, төрки-татар цивилизациясе, тарихта шәхес, Шәрекъ чыганакчылыгы мәсьәләләре, Россиядә шәрекъ археографиясе, китап традициясе һәм татар әдәбияты, татар дини фикере һәм Россиядә мөселман дини институтлары, мәдәни мирас һәм татар халкының милли-мәдәни үзәкләре темаларына караган күптөрле чыгышлар тыңланды.

**21 июнь — 4 июль** көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Омск һәм Самара өлкәләрендә комплекслы фәнни экспедициядә булып кайттылар. Фәнни экспедиция әлеге өлкәләрдә яшәгән татарларның рухи һәм мәдәни мирасын өйрәнү максаты белән оештырылган иде.

**2014 елның 29 июненнән 18 июленә кадәр** «Казан Кремле» музей-тыюлыгында скульптура буен-ча «Таш моңы» дип исемләнгән Халыкара симпозиум булды. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Россия һәм Татарстан рәссамнары берлеге тарафыннан оештырылган әлеге чара 2014 елда «Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасы кысаларында уздырылды.. Аның эшендә Төркия, Азәрбайҗан, Украинадан, Башкор-

тостан, Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән осталар катнашты. Симпозиум барышында өйрәнчекләр ролендә яшь скульпторлар, В. Суриков исемендәге институтның Казан филиалы студентлары катнашты. Проект барышында шулай ук Н. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесында «Бүгенге скульптураның үсеш проблемалары» темасына түгәрәк өстәл сөйләшүе дә үткәрелде.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2014. № 2

Бизәлеш авторы
*Э. Башарова*

Басарга кул куелды: 11.09.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ К-11

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында
нәшер ителде